| 1 | в Бурбаре Дауд из Кандагара, он из детей имама Джафара | сначала в Бурбаре – Дауд шейх дервиш газиз, из потомков Джагфар Садыйка был | АСТАНА ВАРВАРИНСКАЯ. Адрес: Тюменская область, Ярковский район, д. Варвара |

| № | Из текста «Рукописи Катанова» | Из текста «Грамоты хранителя Юрумской Астаны» | Современный адрес |
|---|---|---|---|
| 2 | в Искере почтенный шейх Айкани; там-же перед Искером шейх Бирий; шейх Назар; шейх Шерпети… | второй – шейхи в Эзгаре: один из них Назир, брат его Шариф шейх, лежат у ног своих старших братьев. | АСТАНА ИСКЕРСКАЯ. Адрес: Тюменская область, Тобольский район, с. Преображенка. |
| 3 | шейх Мусса в Кучя-Ялане, был из детей имама Малика | в Кужайлане Уба овраге лежит Муса шейх газиз, потомок имам Халида | АСТАНА ЕПАНЧИНСКАЯ. Адрес: Тюменская область, Вагайский р-н, с. Загваздино. |
| 4 | на холмах есть господин шейх Юсуф, был из внуков имама Абу-Юсуфа | в Кулларах могила хазрата Юсуфа шейха газиза, был из потомков имама Абуйусуфа | АСТАНА КУЛАРОВСКАЯ. Адрес: Тюменская область, Вагайский район, д. Куларово. |
| 5 | внутри Вагая есть почтенный господин Касим-шейх, был из детей имама Ахмеда | в Вагае в местности Атбаш могила Касим шейха, был из потомков Ахмеда | АСТАНА КОБЯКСКАЯ. Адрес: Тюменская область, Вагайский район, д. Кобякская. |
| 6 | на Баише господин Хаким шейх, был из детей имама Шафии | в Баише могила Хаким шейха газиза. Меккинские мужавиры говорили, кто посещает могилу Хаким хазрата, тот получит уважение паломника в Мекку. | АСТАНА БАИШЕВСКАЯ. Адрес: Тюменская область, Вагайский район, д. Баишевская. |
| 7 | у устья Ишима, именно в селении Большой Буран мавзолей шейха Бигач-ата, | в местности Приишинья Улуг Буран могила Бикач ата шейха газиза, он был из потомков Мавляна Джалялитдина | АСТАНА ТЮРМИТЯКСКАЯ. Адрес: Омская область, Усть-Ишимский район, д. Тюрмитяки. |
| 8 | …с левой стороны шейх Дервиш-Алий | в Субра могила дервиша Гали шейха | АСТАНА СУПРИНСКАЯ. Адрес: Тюменская область, Вагайский р-н, д. Луговое. |
| 9 | в Увате шейх Турсун-Алий | в Увеке могила Турсун Гали шейха | АСТАНА МАЛОУВАТСКАЯ. Адрес: Тюменская область, Вагайский район, д. Малый Уват. |

| № | Из текста «Рукописи Катанова» | Из текста «Грамоты хранителя Юрумской Астаны» | Современный адрес |
|---|---|---|---|
| 10 | у реки Вагая на Юруме шейх Девлет-Алий, все четверо – сыновья одного отца… | в Юруме Давлет Гали шейха (могила), все трое от одного отца сыновья, из потомков шейха Абульхасана | АСТАНА ЮРУМСКАЯ. Адрес: Тюменская область, Аромашевский район, с. Аромашево. |
| 11 | в Вагае почтенный старец шейх Баграм | в Вагае могила Бахрам Гали шейха, из потомков Хусаен ата | АСТАНА ВТОРОВАГАЙСКАЯ Адрес: Тюменская область, Вагайский район, с. Второвагай. |
| 12 | у озера Лючюк почтенный Науф | в Наджик Куле (Лячек) – Суфа шейх | АСТАНА ТАХТАГУЛЬСКАЯ. Адрес: Тюменская область, Тобольский район, д. Тахтагул. |
| 13 | в Атяле почтенный Аляф, они родные братья, были из детей султана Баязида | в местности Ат ял Тубул - Зай могила Голук шейха газиза | АСТАНА НОВОАТЬЯЛОВСКАЯ. Адрес: Тюменская область, Ялуторовский район, с. Новоатьялово. |
| 14 | в Бекятуне господин шейх Мир-Кямал | в Бикатине – Миркамал шейх, из потомков Бахти ата. Шейх Султан, потомок Баязид Бустами | АСТАНА БЕГЕТИНСКАЯ. Адрес: Тюменская область, Вагайский район, д. Бегетино. |
| 15 | в селении Каш шейх Абду-ль-Азиз | В ауле Каш Габдельгазиз шейх Канджибарди (Ханпослал) шейх оба сыновья одного отца, потомки Хобби хаджи | АСТАНА КАШАУЛЬСКАЯ. Адрес: Тюменская область, Ялуторовский район, с. Аслана. |
| 16 | в Эрум-джине почтенный шейх Дауд, из внуков имама Гусейна | из Армиджана – Удкантар шейх – оба сыновья одного отца Из потомков имама Хусаена… | АСТАНА АРЕМЗЯНСКАЯ. Адрес: Тюменская область, Тобольский район, с. Нижние Аремзяны. |
| 17 | в Карбине шейх Омар-Алий | в Карбинах Гумар шейх, из потомков Гумер аль-Фарука… | АСТАНА КАРБИНСКАЯ. Адрес: Тюменская область, Уватский район, д. Карбино. |

| № | Из текста «Рукописи Катанова» | Из текста «Грамоты хранителя Юрумской Астаны» | Современный адрес |
|---|---|---|---|
| 18 | в Иш-Тамале Акыл-биби | в Иштигальде Гакыйл Биби, Хадича Биби – дочери Аллакул ахуна. | АСТАНА ИШТАМАНСКАЯ. Адрес: Тюменская область, Тобольский район, д. Иштаманы. |
| 19 | в Канн-Чубари шейх Абдуль-Менаф, оба родные братья, были из детей мудрого Сулеймана | | АСТАНА КОНЧЕНБУРГСКАЯ Адрес: Тюменская область, Нижнетавдинский район, д. Конченбург. |
| 20 | в Карагае Ходжай – шейх, они – родные братья, были из детей Бахти-ата | | АСТАНА КАРАГАЙСКАЯ Адрес: Тюменская область, Вагайский район, с. Большой Карагай. |
| 21 | в Тебенди шейх Анджетан, был из внуков шейха ба-Мачин | | АСТАНА ТЕБЕНДИНСКАЯ. Адрес: Омская область, Усть-Ишимский район, д. Тебендя. |
| 22 | на возвышенной стороне селения Карагай, у Красного Яра, на местности Оба-Бактари, в селении Кюмюшли шейх Кепеш-Алий… | | АСТАНА ЕЛАНСКАЯ. Адрес: Тюменская область, Вагайский район, д. Елань (тат. Кюмюшлэ). |
| 23 | шейх Муслиху-д-дин из Керама, с двумя дочерьми… старшая Салиха-биби, она пала в овраге, называемом Чарбий, у селения Саургач.. | | АСТАНА САУРГАЧИНСКАЯ Адрес: Омская область, Усть-Ишимский район, д. Саургачи. |
| 24 | младшая Афифа-биби, она пала в овраге Агут выходящем из Вагая… | | АСТАНА ВЕРШИНСКАЯ 1. Адрес: Тюменская область, Вагайский район, д. Вершины |



*Остатки сруба и декоративных элементов на Иртышатской астане.*

Все выявленные нами памятники местным населением признаются не просто как святые места, а именно в качестве их отдельной категории – астана. То есть имеется четкое разделение святых мест сибирских татар на доисламские природные или легендарные и могилы первых исламских миссионеров. На большинстве мавзолеев практикуется периодическое восстановление традиционных сооружений. Те астана, на которых не сохранились деревянные 4-х, 6-ти или 8-ми угольные срубы, имеют ориентиры в виде холма, мыса, высокого берега или огромного дерева, часто высаженного на могиле согласно древней традиции сибирских татар.

Сопоставив все данные из собранных материалов, мы предполагаем, что миссионеры после соединения в Средней Орде (территория нынешнего Казахстана) с Шейбани-ханом вышли к р. Ишим и двигались вдоль нее (возможно, и непосредственно водным путем) на север. Пройдя степную и лесостепную зоны нынешней Тюменской области, миссионеры вышли в лесной зоне к левому берегу Иртыша (Усть-Ишимский район Омской обл.). В текстах говорится, что у берегов Иртыша шейхи «учинили великое сражение за веру». А как же бассейн реки Ишим? Ведь это были исконные территории предков сибирских татар. В текстах о Приишимье говорится: «Там имели кочевья: народ Хотан, также народы Ногай и Кара-Кыпчак… – всё это были татары, поклонявшиеся куклам». Тем не менее, в рукописях информации о сражениях на р. Ишим нет. Это подтверждается и отсутствием астана в бассейне р. Ишим (не считая ее устья). Однозначных объяснений этому нет. Возможно, к приходу данной группы миссионеров население лесостепной зоны бассейна р. Ишим уже было мусульманами, либо оно добровольно приняло ислам, или же им было известно о предстоящем походе миссионеров, и они «…бежали и построили свои дома за Иртышом. Некоторые в Хотайскую (китайскую – Р.Р.) сторону…» [Рахимов: 2005. С. 178–191].

Первые астана на пути следования миссионеров появляются на Иртыше близ устья р. Ишим. Это у современного селения Большой Буран

(Тюрмитяки) Усть-Ишимского района Омской области. Выйдя к Иртышу, миссионеры двигались в основном в северо-западном направлении, что подтверждается наличием мавзолеев у селений Большая Тебендя, Саургачи, Малая Бича Усть-Ишимского района Омской области и далее на запад по Иртышу (Вагайский и Тобольский районы Тюменской области). Вверх по течению Иртыша они продвинулись на незначительное расстояние – около 85 км (Кипколлары и Кускун Тевризского района Омской области). Вниз же по Иртышу (на протяжении около 1100–1200 км от устья Ишима до селения Цингалы Ханты-Мансийского района ХМАО) и далее по его притокам нами выявлено и изучено 77 мавзолеев.



*Малоуватская астана.*

Путь мусульманских подвижников неслучайно проходил по водным артериям – население Сибири издревле селилось по берегам рек и озер. Водоёмы не только обеспечивали людей питанием, но и служили транспортными путями. Дороги, соединяющие селения, также прокладывались вдоль рек. Постепенно спускаясь по Иртышу, миссионеры попадали в его притоки, поднимались по ним и продвигались вглубь региона.

Когда водный путь кончался, до отдаленных поселений предков сибирских татар «шейхи» с завидным упорством добирались по труднопроходимым лесам и болотам. Неслучайно, некоторые мавзолеи находятся среди болот в 30–40 км от рек и, зачастую, к ним ведут лишь пешие тропы. Если считать расстояние от Иртыша, как основного пути продвижения миссионеров, то до самых южных мавзолеев (окрестности нынешнего Ялуторовска) по прямой линии будет около 300 км, а если проложить предполагаемый маршрут по руслам рек Тобола и Туры, получится 600–700 км. Отметив расположение мавзолеев на карте, получим условный четырехугольник площадью более 3000 кв. км: его северо-восточный угол будет у селения Кускун Тевризского района Омской области, северо-западный – у селения Цингалы ХМАО, юго-западный – у оз. Андреевское в окрестностях Тюмени и юго-восточный – у с. Аромашево Тюменской области. Данный условный квадрат располагается в пределах двух зональных областей: лесостепной и лесной с подтаежной и южно-таежной подзонами с разнообразными природными комплексами со множеством, крупных и малых рек, озер, болот и лесов.

Большинство астана расположены на берегах рек или в непосредственной близости к пойме. На берегу Ишима – 2, Иртыша – 35, Тобола – 13, Вагая – 4, Агитки (правый приток Вагая) – 6, Туры (левый приток Тобола) – 3. Вдали от рек находятся 14 мавзолеев, большинство из них расположены на берегах озер, лежащих в труднодоступных болотисто-лесных массивах подтаежной зоны.



*Аллагуловская астана. Тюменская обл.*

По местонахождению мавзолеи можно разделить на четыре категории: 1) в черте поселений; 2) на кладбищах; 3) вблизи поселений; 4) вдали от поселений. Из 77 выявленных и паспортизированных нами астана в черте деревень и сел находятся 11; на кладбищах – 18; в лесу, в поле и на болотах в пределах 2/3 км от населенных пунктов (в т.ч., ныне нежилых) – 23; вдали от поселений – 25. При этом необходимо учитывать, что некоторые астана категории 1 и 2 являются относительно поздними перезахоронениями.

По каким критериям выбирались места для устройства астана? Вероятно, на выбор места влияло множество факторов: иногда это происходило в процессе военных столкновений, маршей. Возможно, в некоторых случаях смерть настигала шейхов в местах со сложными ландшафтными условиями (болота, тайга), что затрудняло перемещение покойного. Но можно с уверенностью говорить, что во всех случаях мавзолеи располагаются на сухих возвышенных местах, даже если находятся на берегах болотистых озер. В большинстве же случаев мавзолеи устанавливались по тем же принципам, что и кладбища. Возможно, на выбор места влияло и традиционное представление древних тюрков о ландшафтной модели мира, в которой равнинная часть – это территория для жизни и деятельности человека, а все что выше (горы, холмы, высокий берег) или ниже ее (река, озеро, болото) имеет своих хозяев. Берег реки, озера или край леса являлись границей человеческого и других миров. Все выделяющиеся над общим ландшафтом объекты (холм, овраг, лес, река, озеро) выделялись не только как ориентиры на местности, но и как маркеры территорий, где живут духи-хозяева мест. Возможно поэтому именно в таких «пограничных» местах устраивались кладбища и отдельные мавзолеи.

Таким образом, документальные источники в виде грамот хранителей астана, народные легенды и сама локализация выявленных мавзолеев, а также публикации путешественников, историков и картографов XVII – XX вв. свидетельствуют в пользу реальности похода мусульманских миссионеров, позволяют реконструировать предполагаемый маршрут экспедиции, а также рассмотреть ландшафтную приуроченность мавзолеев к природным объектам.

**Источники и литература**


1. Архив письменных источников Тобольского государственного историко-архитектурного музея-заповедника № 61. Кп. 12890.
2. Ремезов С.У. Хореографическая чертежная книга. 1697–1711 гг. Л. 107.
3. Катанов Н.Ф. О религиозных войнах учеников шейха Багаутдина против иноверцев Западной Сибири. // Ежегодник Тобольского губернского музея. Вып. XIV. Тобольск, 1905. С. 1–28.
4. Рахимов Р.Х. Грамота хранителя Юрумской Астаны (новый источник об исламизации Сибири). // Ежегодник Тюменского областного краеведческого музея «Земля Тюменская». Выпуск 18. Тюмень, 2005. С. 178–191.
5. Рахимов Р.Х. Астана в истории сибирских татар: мавзолеи первых исламских миссионеров как памятники историко-культурного наследия. Тюмень, 2006.
6. Алексеев Н.А. Ранние формы религии тюркоязычных народов Сибири. Новосибирск, 1980.

# ФӘННИ-ПОПУЛЯР ЯЗМАЛАРДА ТӨБӘК ТАРИХЫ

# КРАЕВЕДЕНИЕ В НАУЧНО-ПОПУЛЯРНЫХ ПУБЛИКАЦИЯХ

*Фәүзия Бәйрәмова*

## «БУТАН» БӘЕТЕ – ТАТАР ЯЗМЫШЫ...

Себердә татарларның төрлесен очратырга була – Урал тауларыннан Алтай краена кадәр, таралып, үз туган туфракларында себер татарлары яши, әмма аннан ары алар юк, Новосибирски өлкәсендә бараба һәм чат татарларының соңгы авыллары... Ә Сахалинда, Ерак Көнчыгышта, Камчатка-Магаданнарда, Байкал буйларында, хәтта Себер саналган Красноярски краенда да себер татарлары түгел, кайчандыр язмыш шушы якларга китереп ташлаган казан татарларының нәселләре яшәп ята... Аларның тарихы аз өйрәнелгән. Югыйсә, һәрберсе турында китап язарлык тетрәндергеч язмышлы татарлар яши бит монда! Тел галимнәре моңа кадәр урыннарга чыгып, гел себер татарларын өйрәнделәр, тарихчылар да шул юлдан китте. Себергә сөргеннәргә сөрелгән, Транссиб тимер юл төзелешенә килгән, патша заманында Столыпин реформасы буенча чарасыздан туган җирләреннән шунда күчәргә мәҗбүр булган, совет заманында комсомол төзелешендә катнашкан, эшкә барып урнашкан һәм нәселе дә анда яшәп калган дистә меңләгән татар, аларның язмышы турында милләт белми диярлек. Мин үзем дә соңгы унбиш-егерме елымны себер татарларына багышладым, алар турында тарихи романнар, дистәләгән китап яздым. Бары тик «Сахалин утравы һәм татарлар» (2014), «Котыпта татар тормышы» (2015) китапларым һәм «Ерак Көнчыгышта татарлар» тарихи хезмәтем (2016) Салехардтан Сахалин-Владивостокларга кадәр таралган Идел-Урал татарлары турында урыннарга барып, өйрәнеп язган хезмәтләр иде...

Ә менә Красноярски крае миннән дә, Казан галимнәре игътибарыннан да гел читтә кала килде. Югыйсә, биредә 1926 елда гына да 71 татар авылы булган, шуның утыз икесе хәзер дә бар. Биредә себер татарлары яшәмәгәч, монда татар авыллары ничек барлыкка килгән соң? Болар барысы да диярлек, 1906–1911 елларда, Столыпин реформасы сәбәпле, Идел-Уралдан Себергә күчкән һәм шунда тамыр җибәргән, авыллар бу-

лып оешкан милләттәшләребез. Ул елларда безнең як татарлары хәзерге Красноярски төбәгендә иллегә якын авылга нигез салалар. Бу тирәдә бары тик Шулдат һәм хәзер Кемерово өлкәсенә кергән Серебряково авыллары гына алар килгәнче була, боларына нигезне Пенза төбәгеннән килгән мишәрләр сала. Дөрес, кара урманнардагы бу татар авыллары турында «Татарстан – яңа гасыр» телевидениесе тапшырулар әзерләде, Казан хәбәрчеләре бераз язды. Әмма алар да сөргенгә сөрелгән татарлар темасын әйләнебрәк уздылар...

Мин үзем Красноярски краена барырга, сөргенгә сөрелгән татарлар язмышын өйрәнергә озак еллар җыендым, әмма гел җай чыкмады. Аннан дөньяда шушы чир башланды һәм бетәсе дә күренми. Шуңа күрә 2021 елның көзендә тәвәккәлләп, Красноярски якларына чыгып киттем, аның да төньягында урнашкан Енисейски шәһәренә. Һәм мин өйрәнә торган тема да шактый ерак чорга – XIX гасырның икенче яртысына карый. Енисейски шәһәре – заманында Көнчыгыш Себернең башкаласы булган, аңа 1619 елда, хәрби острог буларак нигез салынган. Татарларның биредә XVIII гасырдан яшәүләре билгеле, берәүләре чирүле хезмәтендә булса, икенчеләре монда сөргенгә сөрелгән. Заманында әби-бабалары көчләп чукындырылганнан соң, аларның нәсел дәвамчылары рөхсәтсез ислам диненә кайтканга күрә, 1867 елны Казан губернасының Свияжски өязеннән 45 татар Турухан краена сөргенгә сөрелә. Хатыннары артларыннан җәяү китә... Алар менә шушы Енисейски шәһәрендә очрашып, полиция һәм хәрбиләр күзәтүе астында сөрген тормышларын башлыйлар... Һәм мин бирегә аларның нәсел дәвамчыларын эзләп, Себер архивларында бу хакта нидер табасыма өметләнеп килдем.

Әлбәттә, моннан 150 еллар элек булган хәлләрне монда инде хәтерләмиләр, дин өчен сөрелгән татарлардан ядкәр булып таш мәчет һәм мөселман зираты гына калган. Әмма татар зиратындагы 1919 елга кадәр булган гарәп язулы борынгы кабер ташлары совет заманында юк ителгән. Патша заманында сөргенгә сөрелгән татарлар турында җирле архивта һәм музейда да берни юк. Шулай да, шәһәр китапханәсендә һәм төбәк тарихын өйрәнү музее фондларында, урыс халкының туган якны өйрәнүчеләре хезмәтләрендә ул чорлар турында шактый мәгълүмат таптым. Шулай ук Красноярски краеның дәүләт архивында да ул вакытларда төбәктә яшәгән мөселманнар турында саллы чыганаклар саклануын ачыкладым, хәзер аларны өйрәнү дәвам итә... Һәм болар хакында аерым язмам булыр әле, ин ша Аллаһ!

Себер хәтле Себергә, бигрәк тә аның иң ерак төбәге булган Красноярски якларына килгәч, үз темаңны гына өйрәнеп утырмыйсың, татарлар турында барысын да беләсе килә. Енисейски шәһәрендә дә мин патша

заманындагы сөрген белән генә кызыксынып калмадым, Сталин чорында Себергә сөрелгән татарлар тарихын да өйрәндем. Унҗиде мең кешелек кечкенә генә шәһәрдә биш йөзләп татар яши, аларның бер өлеше патша заманында сөрелгәннәрнең нәселе булса, бер өлеше – Столыпин заманында ихтыяри-мәҗбүри күчүчеләр, калганнары – узган гасырның утызынчы елларында Идел-Уралдан сөрелгәннәрнең нәсел дәвамчылары. Менә алар, әби-бабалары, ата-аналары, туганнары сөйләп калдырган буенча бик күп нәрсәләрне хәтерлиләр! Җан тетрәткеч бу тарихны өйрәнүче, барлаучы, теркәп калдыручылар гына юк...

Енисейски шәһәрендә мин бер нәсел белән таныштым, алар – 1930 елларда Татарстанның Югары Тәкәнеш авылыннан салкын Себергә сөрелгән Мөхәммәтхаҗи Әхсәновның оныклары.



*Мөхәммәтхаҗи Әхсәнов.*

Рауза һәм Галия үзләре Енисейскида туганнар, ә аларга кадәр аталарына һәм бабайларына Себердә каторжан юлын үтәргә туры килгән. Мөхәммәтхаҗиның атасы Әхсән авылында мулла була, улы исә, дини гыйлем алу белән бергә, сәүдә белән дә шөгыльләнә, кибет тота. Оныкларының әйтүе буенча, ул авылда мулла була, хаҗ кылгач, исеменә хаҗи атамасы да өстәлә. Инкыйлабтан соң Мөхәммәтхаҗи сәүдә эшләрен туктатырга мәҗбүр була, мәчетләр дә ябыла, әмма бу аны барыбер сөргенгә сөрелүдән коткарып калмый. Яхшы кирпеч йорты һәм күп мал-туары булган өчен, башта аны гаиләсе белән өеннән мунчага куып чыгаралар, аннан барысын да сөргенгә сөрәләр. Мөхәммәтхаҗиның беренче хатыныннан туган улы Шакирны, гаиләсе белән, Магнитогорскига сөрәләр. Бу вакытта Мөхәммәтхаҗи инде алтмышны узган була, ә төпчек кызы Мөэминәгә нибары бер яшь тулып узган. Аның беренче ике хатыны, ишле балаларын калдырып, үлеп китәләр һәм ата кеше сөргенгә өченче хатыны Хәсбикамал белән кузгала...

Кешеләр белән дыңгычлап тутырылган товар вагонында сабый уллары Хәмит үлә, аны Красноярскида подвалга ыргытылган мәетләр арасыннан эзләп табып, ата-анасы төнлә ка-



*Мөхәммәтхаҗи бабайның төпчек кызы Мөэминә.*

ча-поса барак тирәсенә күмә. Яңа гына кул арасына керә башлаган Мирзанәгыйм белән Сәитзадәне, үсмер балалары Хәбир белән Хәкимне, биш яшьлек Сәхипҗамалны, бер яшьлек Мөэминәне, аларның ата-аналарын кышкы поезд Кытай чигендәге Бутан дигән котсыз җиргә илтеп ташлый. Торырга урын юк, исән каласың килсә, җир куышы казып керәсең, чөнки кышкы баракларны төзеп өлгермәгәннәр. Һәм ил өчен алтын эзлисең, алтын юдырасың. Алга таба алар шушында яшәргә яки үләргә тиеш булалар...



*Мөхәммәтхаҗи бабайның балалары:*
*Хәбир, Шакир, Хәким, Мөэминә.*

Мин бу Бутан дигән җирне картадан да, интернеттан да эзләп таптым, ул хәзерге Забайкалье краеның Сретенски районындагы ташландык алтын базлары урыны икән. Ул чагында Ерак Көнчыгыш крае (Дальне-Восточный край) дип аталган һәм анда 1930 елның җәендә генә дә 4243 гаилә (21609 кеше) сөрелгән, шулардан 1614 гаилә – Татарстаннан, 1561 гаилә – Башкортстаннан, 307 гаилә – Урта Иделдән, 314 гаилә – Себердән. Һәр гаиләдә кимендә 7–8 бала һәм һәр төбәктән сөрелүчеләрнең күпчелеге татарлар була. Бу бәхетсезләргә Югары Тәкәнеш авылыннан Мөхәммәтхаҗи Әхсәнов гаиләсе дә килеп кушыла.

Әйе, бәхетсезләр... Чөнки ашарга юк, кешеләр ачтан үлә башлый, күпләр катып-өшеп үлә. Монда кышын салкыннар 40–50 градуска җитә, ә җәйләрен көйдергеч эссе, самум җиле, чебен-черки... Тоткыннарга медицина ярдәме күрсәтелми, халыкны, бигрәк тә балаларны тиф, скарлатина, кызамык кыра. Болар хакында хәтта «кулаклар»ны махсус тикшерергә килгән ОГПУ комиссиясе дә танырга мәҗбүр була:

**«Сводка ПП ОГПУ по Дальне-Восточному краю о положении «вселенных в ДВК кулаков». 4 июля 1930 г.**

В приисках Бутан и Лужанка кулаки живут в землянках, т.к. строительство зимних бараков еще не закончено. Люди живут в землянках с двойными нарами и на чердаках. … В силу такой скученности, мы отмечаем огромный рост инфекционных заболеваний (корь, скарлатина, тиф) и смертности. Организация раздачи продуктов безобразная, в силу чего выселенные простаивают в очередях по 7–10 часов. Катастрофическое положение создалось с довольствием нетрудоспособного контингента, которого имеется всего 88 семей – 472 человека, в составе которых нет ни одного трудоспособного, и 21 семья – 208 человек, имеющая по одному работнику. В составе этих же семей имеется 29 семей, которые совершенно не обеспечены продовольствием, а поэтому обречены на голодовку» (https://istmat.info/node/51993).

Идел-Уралдан сөрелгән гаиләләрнең саннарыннан күренгәнчә, биредә күпчелек тоткыннар татарлар булган. Бу хәл шул чор документларында да ачык чагыла. Әйтик, шул ук ОГПУның белешмәсеннән күренгәнчә, татарларга хәтта медицина ярдәме дә күрсәтергә теләмәгәннәр, аларны кыйнау очраклары да булган:

«Отношение к кулакам со стороны отдельных лиц технического и административного приискового персонала носят ненормальный характер. Имеется грубость и даже рукоприкладство, так например: 31/У на прииске Лужайка смотритель ГРИГОРЬЕВ за неисполненное выселенным ХАЛИУЛИНЫМ (татарин) приказание, которого последний не понял[,] – избил ХАЛИУЛИНА. Случаи грубого отношения к кулакам отмечены также со стороны медперсонала. Такие явления, как нанесение оскорблений при осмотре, заявления о том, что «мы вас татар вообще лечить не намерены», отказы в медпомощи и т.д. – имеют довольно распространенный характер. Между русскими, татарами и чувашами остро развит национальный антагонизм. Бывшие крупные торговцы, муллы, татарские учителя устраиваются обособленно. Остальная часть выселенных относится к ним враждебно. Категорически отказываются с ними жить вместе, предпочитая селиться на чердаках и под открытым небом» (https://istmat.info/node/51993).

Адәм баласы чыдамаслык шушындый шартларда – ачлыкта, зәмһәрир салкында, кыйналып, кара төнгә хәтле эшләп, ничек исән калырга мөмкин? Берсеннән-берсе кечкенә алты бала белән?! Заманында Мәккә-Мәдинәләрдә булып, хаҗ кылган, намаз-ниязлы Мөхәмммәтхаҗи бабай Аллаһ ярдәме белән үзе дә, гаиләсе дә Бутанда исән кала. Үзләренең Себергә сөрелү тарихын, Бутанда күргәннәрен ул бәет-мөнәҗәт рәвешендә туган авылына язып җибәрә. Мөхәмммәтхаҗи Әхсәновның бу бәетен, аның уллары Габделхәбир белән Габделхәким 1963 елда авылга кайткач, Юга-

ры Тәкәнештәге туганнарыннан Енисейскига алып киләләр. Бу вакытта инде Мөхәммәтхаҗи бабай үлгән була, бәет-мөнәҗәт аның улларыннан кызларына, оныкларына күчә. Һәм, әлбәттә, мин дә аны Себердән алып кайттым һәм сезгә тәкъдим итәм:

**«Бутан» бәете**

*«Сабан туе көннәрендә*
*Без йөрибез шатланып,*
*Начальник килде атка атланып.*
*Әйттеләр безгә – китәргә сезгә,*
*Әзерләнегез төнге сәгать бергә.*
*Булды сәгать бер, хәзерләндек без,*
*Туган илләрдән чыгып киттек без.*
*Атлар җигелде, халык җыелды,*
*Өйдән чыкканда яшьләр коелды.*
*Без бәхетсезләрне Себергә озаталар,*
*Авылдан чыкканда калдылар карап.*
*Авылдан чыкканда карадым каерылып,*
*Туган илкәем калды аерылып.*
*Бар туганнарым карап калдылар,*
*Кайсы берләре озата бардылар.*
*Җиттек заводка, яптылар бер йортка,*
*Безне озаталар ялкынсыз утка.*
*Бер атнадан соң илттеләр поездга,*
*Ике чиләк су бирделәр юлга.*
*Вагонга яптылар, бикләп алдылар,*
*Туганкайларым карап калдылар.*
*Җиттек Бутанга, ямьсез бер тауга,*
*Үзе урманлык, күренми бер карга.*
*Өйләре ямьсез, сулары тәмсез,*
*Безләр йөрибез Бутанда хәлсез.*
*Безнең Бутанның таулары биек,*
*Безләр йөрибез Бутанда көеп.*
*Үзебез тоткында, төннәр юк монда,*
*Ипиләргә ач, акча юк кулда.*
*Карап калдылар безне кешеләр,*
*Себер киттек без бәхетсез кешеләр.*
*Болынлыкта печән чабалар,*
*Һич гөнаһысыз сабый балалар.*
*Тормыш начар, һәркем күрсә, качар,*
*Тәрәзә ватык, йоклыйбыз катып.*
*Безнең Бутанда алтын юалар,*
*Авылга барсак, ябып куялар.*
*Карлыгач илә сайрый сандугач,*
*Туганнар, җыларсыз, моны укыгач.*
*Моны яздым мин 9 нчы мартта,*
*Кошлар да очмый безнең бу якта.*
*Хуш, туганнарым, исән булыгыз,*
*Кауша алмасак, бәхил булыгыз.*
*Каты агамы сезнең суыгыз,*
*Намаз артыннан дога кылыгыз.*
*Бардым урманга җиләкләр пешкәч,*
*Өзелә үзәкләр исләргә төшкәч...»*

Бутанга алтын бетә башлагач һәм күпләп үлү сәбәпле эшләргә кеше калмагач, могҗиза белән исән калган тоткыннарны, шул исәптән Мөхәммәтхаҗи карт гаиләсен дә башка урынга күчерәләр. Бабайның Магнитогорскидагы оныклары әйтүе буенча, бу – хәзерге Красноярски краеның төньягындагы Северо-Енисейски тирәсе була. Монда патша заманыннан бирле алтын чыгаралар, әле аның хәзер дә беткәне юк, илдәге алтынның чиреге шунда табыла. Енисейскида яшәүче нәсел дәвамчылары фикеренчә, аларны бу шәһәр аша Шайтанка дигән җиргә озатканнар, рәсми документларда ул Ларионовка дип атала. Анда илдән сөрелгән тоткын-

нар яшәгән. Әмма Шайтанкага барып урнашканчы Мөхәммәтхаҗи карт гаиләсе зур кайгылар кичерә...

Мөхәммәтхаҗи бабайның Енисейскидагы оныкчыгы Фәрит Хәйруллинның әйтүенчә, тоткыннарны бер приискадан икенчесенә күчергәндә, аларны бик нык тенти торган булганнар. Алтын комын яшермәгәннәрме дип, күлмәк якаларына кадәр кисеп караганнар, өс-башларын, мендәрюрганнарын ярганнар. Гөнаһ шомлыгына каршы, Мөхәммәтхаҗи карттан да шикләнәләр, аны төрмәгә алып китәләр, кышкы салкында урамга алып чыгып, яланөс чишендереп, алтынын кайда яшергәнен әйттерергә тырышалар. Бабай тәмам өшеп, катып үлә башлагач, кул селтәп, төрмә ишегалдыннан урамга куып чыгаралар. Анда аны хатыны Хәсбикамал каршы ала, Аллаһ рәхмәте белән исән калган ирен җан җылысы белән җылыта...

Ә менә уллары Сәитзадәне коткара алмый алар. Үсмер малайны, ялган азык-төлек карточкасы ясауда гаепләп, төрмәгә утырталар һәм шунда кыйнап үтерәләр. Моны башкаларга сабак булсын өчен эшлиләр. 1933 елдан Әхсәновлар гаиләсе Шайтанкада яши башлый, монда да ирекле булып түгел, тоткын булып, чөнки гел күзәтү астында булалар, авылдан бер җиргә китә алмыйлар, һәр кичне комендатурада теркәлү үтәргә тиеш булалар. Шайтанка – Енисейскидан йөз чакрымнар еракта, кара урман уртасында, Шайтан суы буендагы тоткыннар авылы, монда урысы-татары бергә яшәгән. Башта Мөхәммәтхаҗи карт гаиләсе дә салкын, ташландык баракта яши, аннан соң гына үз өйләрен салып чыгалар. Кулы эш белгән татар карты колхозда яхшы исәптә була, уллары белән бергә кирпечен дә суга, ашлык киптергечне дә төзеп куя, колхоз умарталыгын да ул оештыра. Әмма ничә еллар җир куышларында, салкын баракларда яшәү тагы ике баласының гомерен өзә – Мирзанәгыйм белән Сәхипҗамал сөяк туберкулезыннан үләләр. 1938 елны авылның барлык ир-атларын диярлек Енисейскига алып китәләр һәм халык дошманы дип, атып үтерәләр, аларның күпчелеге татарлар була. Мөхәммәтхаҗи картны һәм аның улларын Аллаһы Тәгалә саклап кала. Ул арада сугыш башлана, сөргенгә сөрелгәннәрне башта сугышка алмыйлар, алар ышанычсыз элементлар булып санала. Әмма 1942 елны Мөхәммәтҗан картның Габделхәбир һәм Габделхәким исемле улларын да сугышка алалар. Бабай аларның исән калуларын сорап, һәр намазыннан соң Аллаһка ялварып дога кыла, шөкер, уллары сугыштан исән-имин әйләнеп кайталар... Алга таба тормыш авырлыгын алар үз җилкәләренә алалар һәм инде тоткын булып түгел, сугышта җиңеп кайтучылар булып саналалар.

Әйе, сугыштан соң тоткыннарга бераз ирек килә, комендатура бетерелә, кешеләргә башка урынга күчеп китәргә мөмкинлек бирелә. Һәм авыл тарала башлый, кемдер туган якларына кайтып китә, кемдер шәһәргә барып урна-

ша. Ташландык авылда бернинди киләчәге булмаган 17 яшьлек Мөэминә дә, әти-әнисенең фатихасы белән, олы юлга кузгала. Алдан ук килешү буенча, ул этисенең беренче хатыннан туган олы улы Шакир абыйсы янына барырга ниятли, аны да теге елларда гаиләсе белән Магнитогорскига сөргән булалар. Әмма кулында бер тиен акчаң булмаган килеш Себер урманнарыннан Урал итәкләренә хәтле ничек барып җитәргә? Бу гаять авыр мәсьәләне болай хәл итәләр – Мөэминәгә бирнәгә дип әзерләнгән сыер була, кыз балага шуны тоттырып, ерак юлга чыгарып җибәрәләр. Бу яз көне була, ә Енисейскига кадәр йөз чакрым! Сыерын җитәкләп, җәяүләп юлга чыккан Мөэминә Себер елгаларының тулып аккан чагына туры килә, Тыя елгасын ул сыеры белән бергә йөзеп чыга, чак кына батмыйча кала. Көч-хәл белән Енисейскига килеп җитеп, сыерын шунда базарда сатып, Магнитогорскига билет ала. Анда исә аны туганнары, язмышы көтеп тора... Биредә Мөэминә үзенең булачак ирен очрата, алар гаилә корып, өч бала тәрбияләп үстерәләр. Әтисе Енисейскида картаеп үлгәч, Мөэминә әнисен дә үз янына алдыра, хәзер аларның икесенең дә каберләре Магнитогорски шәһәренең татар зиратында...

Инде тагы сугыштан соңгы елларга, Шайтанка авылына кайтыйк. Әйткәнебезчә, коллык богаулары өзелгәч, авыл таралып бетә, биредән соңгы кешеләр булып Мөхәммәтхаҗи карт гаиләсе кузгала. Оныкларының хәтерләвенчә, бу хәл 1951 елның ноябрендә, салкын кыш кергәнче, әмма кар төшкәч була. Ат чанасына үгез җигеп, шунда бар булган йорт кирәк-яракларын төяп, сыер, сарыкларны куалап, җәяүләп озын юлга – Енисейски тарафына кузгалалар. Бераз баргач, сарыклар авыл ягына карап кирегә чаба башлыйлар, ирләр алар артыннан йөгерә. Сарыкларны куып алып килгәндә, үгез туарылган, чанадагы печәнне ашап тора торган була... Карт ата-анасын һәм энесе Хәкимне, хатыны һәм яшь баласы белән сөрген авылыннан олы уллары Хәбир алып чыгып китә. Ул гаиләсе белән Ялан дигән җирдә яшәп, умарталыкта эшли торган була. 1958 елда Хәбир Енисейски шәһәрендә йорт салып чыга, Мөхәммәтхаҗи бабай белән Хәсбикамал әби алар белән яши. Бер елдан бабай бакыйлыкка күчә, Аллаһ аңа озын гомер бирә – сөргендә дә намазын, уразасын калдырмаган татар карты, Себердә үз өендә, якыннары янында, 90 яшендә мәңгелеккә күзләрен йома... Кабере – Енисейскиның мөселман-татар зиратында, мин анда да булып, рухына дога кылдым. Мөхәммәтхаҗи бабайның үзеннән соң иманлы балалары, намазлы нәселе, догачылары кала, үзе белән бергә бөтен сөрген юлын үткән Коръәне, бик күп дини китаплары кала. Һәм үзәкләрне өзгән «Бутан» бәете кала...

«Хуш, туганнарым, исән булыгыз,
Кауша алмасак, бәхил булыгыз.
Каты агамы сезнең суыгыз,
Намаз артыннан дога кылыгыз.

Бардым урманга җиләкләр пешкәч,
Өзелә үзәкләр исләргә төшкәч…»

Әйе, бөтен Рәсәе – татар каберлеге...

Кытай чикләреннән Урал итәкләренә кадәр татар сөякләре сибелгән...

Билгеле һәм билгесез каберлекләр...

Тәкәнештән бер итәк бала белән Себергә сөрелгән Мөхәммәтхаҗи Әхсәновның сабый улы Хәмит Красноярскида ятып кала, кабере билгесез. Сәитзадәне төрмәдә кыйнап үтерәләр, кабере билгесез. Мирзанәгыймне Шайтанкадан Енисейскига больницага озаталар, ул шунда җан бирә, кабере билгесез. Гүзәл кыз Сәхибҗамал Шайтанка авылында сөякләре череп үлә, хәзер инде ул тоткыннар авылы үзе дә юк, аңа юл да юк. Мөхәммәтҗан карт һәм аның уллары Габделхәбир белән Габделхәким Енисейски татар зиратында яталар, хатыны Хәсбикамал белән төпчек кызы Мөэминә, олы улы Шакир Магнитогорскида, оныклар-онықчыклар дөнья буйлап таралган. Югары Тәкәнештә дә Мөхәммәтхаҗи Әхсәновның ир туганнары Муллахмәт белән Колләхмәтнең нәселе яшәргә тиеш, әмма алар белән элемтә өзелгән инде...



*Мөхәммәтхаҗи Әхсәновтан калган дини китаплар.*

Енисейски шәһәрендә һәр ике гаиләнең берсендә – менә шундый аянычлы язмыш, сөрген тамгасы сугылган тарих. Аларның илдән куылган бабайлары Себердә алтын базларында эшләсәләр дә, нәселләренә алтын түгел, алтыннан да кыйммәт мирас калдырганнар. Үзләре белән сөргенгә бары тик дини китапларын гына яшереп алып килгән татарлар бүген дә шуның белән яшиләр, һәр йортта, һәр гаиләдә каторжан бабайлардан калган Коръән – иң кадерле мирас. Шулай ук Енисейскиның татар зиратының элеккеге намаз йортында да сандык-сандык борынгы дини һәм мәдәни китаплар, көндәлекләр саклана. Шәһәрнең «Туган тел» татар мәдәни үзәге һәм мөселман оешмасы Енисейскида милли музей булдырып, бу китапларны да шунда куярга җыена. Бу бик яхшы эш булыр иде, әмма Казан галимнәре дә бирегә килеп, бу кадерле ядкәрләрне өйрәнсеннәр иде. Шулай ук заманында Себергә сөргенгә сөрелгән Идел-Урал татарлары буенча аерым проект төзеп, фәнни эзләнүләр алып барылса, яхшы булыр иде. Алар да бит милләтнең аерылгысыз бер өлеше, хаксызга рәнҗетелгән, яраланган, әмма нинди шартларда да кеше булып, мөселман-татар булып калган затлы өлеше!

*А.Г. Ахунов*

# ТАТАР ДӘҮЛӘТЛӘРЕ КУЛЛАНГАН СӘҮДӘ АКВАТОРИЯСЕ

***Аннотация:*** *Укучыга тәкъдим ителгән мәкалә урта гасырда оештырылган татар дәүләтләре сәүдәгәре кулланган елга – «тартан» сәүдә юллары системасын өйрәнүгә багышлана. Авторның эзләнү максаты – татар сәүдәгәрләре кулланган су юлларын, аларның атамаларын һәм борынгы «волок»ларның иске атамаларын ачыклау. Мөмкин булган очракта, җирле топонимнар, риваятьләр аша аларның урыннарын билгеләү. Шулай ук Идел, Дона һәм Обь елгалары бассейннарында барлыкка килгән дәүләтләрнең нигезләнүе, географик урнашуы, сәясәте турында үзенчәлекле аңлатмалар бирелә. Дәүләт-ара чикләрне билгеләүдә елга бассейннары роле дә ассызыклана. Шулай ук топонимика проблемалары да кузгатыла. Автор, бүгенге көндә инде татарлар торып калмаган, әмма заманында Алтын Урда дәүләте территориясенә кергән барлык төбәкләрдә дә, җир-су атамалары килеп чыгышын ачыклаганда татар теле читтә калмаска тиеш дип саный. Мисал өчен кайбер гидронимнарның мәгънәләре татар теле аша аңлатыла. Мәкаләдә аерым атамаларның бүгенге һәм тарихи атамалары параллель кулланыла. Кадими белемнәрдән «җир кендеге», «казык уртасы» кебек онытылып торган төшенчәләр яңадан кулланышка кертелә.*

***Терәк сүзләр:*** *сәүдә, су юлы, «тартан», «тартарчы», «волок», су көймәсе йөреше, йөзгеч, җир кендеге, казык уртасы, болак, лиман, расиф, Ателькуза, сәүдә факториясе.*

## Кереш сүз

Сүз башы итеп «тартан» яки урыс телендәге «волок» сүзләренә аңлатма биреп китәрбез. Шунсы кызганыч, «Татар теле аңлатмалы сүзлеге»нә «тартан» сүзе кертелми калган. Моның сәбәбе гади һәм аңлашыла. Берничә гасыр буе барган Болгар – Суздаль, Казан – Мәскәү сугышларының төп сәбәбе – сәүдә юлларын кулга төшерү өчен булган дисәк, хата булмас. Казан ханлыгы яулап алыну белән мәскәүлеләр тарафыннан татарларны сәүдә эшеннән тулысынча читләштерү сәясәте алга сөрелгән. Колонизация вакытында ук стратегик әһәмияте булган су юлларын, кичү, күпер, «волок»ларны беренче чиратта кулга төшергәннәр. Шул урыннарда тоташы белән яңа урыс авыллары нигезләнгән дисәк, хата булмас. Яңа кануннар буенча, татар кешесенә шәһәрләрдә яшәү, сәүдә су юлларына биш чакрымнан да якын арада авыллар нигезләү һәм сәүдә

кәсебе катгый тыелырга тиеш була. Бары тик ике йөз елдан соң гына, Рәсәй империясе өчен кискен ихтыяҗы туганга, мөселман илләре белән сәүдә итүдә арадашчылар буларак, татарларны сәүдә эшенә җәлеп итү башлана. Нәтиҗәдә, халкыбыз эчендә яңадан сәүдәгәрләр катламы пәйда була. Шактый тукталып торган булса да, урта гасырларда кулланылган су юлларында яңадан татар сәүдәгәрләре идарә иткән йөзгечләр пәйда булган. Онытыла башлаган төрки телдәге кайбер сәүдә терминнарын яңадан искә төшерергә туры килгән. Шул исәптән бер елга бассейныннан икенчесенә сәүдә корабларын күчерә торган урын атамасы да. Урыс телендә ул «волок» дип аталган. Интернет-ресурсларны файдаланып, «волок» сүзенә бихисап күп аңлатма таптык. Мөһимрәк, тулырак аңлатма бирелгән кайбер тасфирламаларны оригинал телендә китерүе дөрес булыр дидек:

*«Волок» – «участок между двумя судоходными реками, через который в старину перетаскивали судно для продолжения пути».*

*«Волок» – «участок водного пути (сухопутье). Низкие водоразделы между верховьями судоходных рек, по которым в старину «волочили» судна и грузы из одной реки в другую, из одного бассейна в другой».*

*«Волок» – «участок суши, обычно с переволоком, между двумя озёрами или реками, через который тащили суда – «волоком».*

*«Волок» – «это дорога через водораздел и связанные с ней поселения, одиночные или образующие гнездо».*

*«Волок» – «обобщенное название для участков перехода с одной речной системы на другую».*

*«Способы перехода судов через «волоки»: 1) волочили по мелководью, 2) несли на руках, 3) катили на бревнах. В качестве тягловой силы использовались люди («бурлаки), лошади и олени, колёсами служили торцевые части брёвен (роспили)»* (төрле интернет-ресурслардан). Димәк, корабларны икенче елга үзәненә күчерү эше субүләр сыртларда башкарылган. Төрле бассейннарга караган елгалар бер-берсенә бик якынлашкан урында, арада булган күлләрне, сулы чокырларны, сазлыкларны файдаланып, йөзгечләрне бер елгадан икенчесенә тартып күчергәннәр. Йөзгечләр җиңел булган очракта – махсус арбаларга салып, авыр булса – ватылмас өчен агач «чаналарга» утыртып, бүрәнәләр өстеннән шудыру юлы белән, күчерелгән. «Телебездә бу төшенчә ничек яңгыраган соң?» – дигән сорауны алга куеп шактый эзләнергә туры килде. Аңлатмалы сүзлектә «волок» сүзенең мәгънәсенә якын булган «ТАРТАРЧЫ» сүзе бар [Татар теленең: 1981. Б.45]. Элгәре, нефть чыгару промысельләрендә, пар, электр двигательләре кергәнче, механизмнар ат көче, йә күмәк кешеләр көче белән хәрәкәткә китерелгән. Элекке бурлаклар сыман, туры мәгънәсендә дирбияләргә җигелеп, хезмәт салучы кешене «тартарчы» дигәннәр. Ә менә

төрки телле халыклардан долганнар телендә бар икән андый сүз. Элек «тахынар» сүзе белән долганнар «волок»ны атаганын ачыкладык. Аурупа мосафирлары тарафыннан язылган хезмәтләрдә теркәлгән һәм бүгенге тарихчыларга табышмак төсле тоелган «тартарис тагурис» халкын без тартаннарда артельләргә оешып кораб-көймәләрне бер елга үзәненнән икенчесенә сөйрәп-тарттырып күчерүче сословие кешеләрен атаганнар дибез. Эзләнә торгач, татар каласы «Тартаннлы» атамасыннан чыгып, без «волок» сүзенең татарча тәрҗемәсенә тап булдык. Мәкаләдә «волок» сүзе урынына артабан чын татар телендәге атамасын – «тартан» сүзен кулланырбыз.

## Сәүдә юллары турында

Сәүдә юллары дәүләт өчен әһәмиятле булса да, башкаланы провинция-төбәкләр белән «бәйләүче» «ара юллары» мөһимрәк булган. Шулай да дәүләтнең үсешен, икътисади яшәешен сәүдә тәэмин иткән дисәк, хата булмас. Сәүдә юллары «географиясе» дәүләтара чикләрне генә билгеләп калмый, еш кына яңа дәүләтләр барлыкка килүгә дә сәбәп булган. Күрше яшәгән дәүләтләрнең үзара нинди мөнәсәбәттә яшәвен дә билгеләгән! Беренчедән, сәүдә бәйләнеше күрше дәүләтләр белән дустанә, тату яшәүгә, аралашып яшәүгә булышлык итсә, икенчедән, сәүдә юлларына үзе генә хуҗа булу теләге тарткалашу, сугышлар чыгуга этәргеч тә биргән. Икенче төрле әйткәндә, сәүдә юллары «низаг алмасына» да әверелгән! Сәүдә юлларын урта гасырларда ике төргә бүлгәннәр: 1) җәяүләп, атлар, үгезләр, дөяләр, ишәк-качырлар, боланнар, этләр җигелгән арба-чаналарда уза торган коры җир юллары; 2) су чыганаклары буйлап төрле йөзгечләрдә йөзеп бара торган су юллары. Гадәттә, турырак һәм якынрак юл сайлар өчен мосафирлар бу ике төр юлны аралаштырып кулланган. Борынгы су юллары һәм андагы «тартаннар» янәшәсеннән, кагыйдә буларак, коры җир юлы да уза торган булган.

Урта гасырларда бердән-бер зур күләмдә товар ташый торган транспорт төрен су юлларындагы йөзгечләр тәшкил иткән. Билгеле, арба белән, йә дөя, ишәк, качыр сыртында, зур-зур кәрваннар оештырып та берьюлы бер кораб трюмына сыйган кадәр йөк төяп булмаган. Тарихи чыганакларда су юллары белән хәрәкәт итү вакытын «су көймәсе йөреше» («дневная дорога на лодке») төшенчәсе белән үлчәгәннәр. Бу берәмлек, билгеле, елга агымы буйлап йөзү һәм агымга каршы йөзү очракларына бәйле ике төргә бүленгән. IX гасыр фарсы географы Әбү Зәид әл-Бәлхи хезмәтендә: «От Итиля (столица Хазарии) до Булгара расстояние по степям около одного месяца пути; водою же, вверх по реке, около двух месяцев, вниз по реке – около 20 дней... От Болгара до Куябы (Киева) около 20 дней пути» [Беркутов: 1987, ББ. 51–52] Урта гасыр чыганагы Әбү Габдуллаһ

Мөхәммәд әл-Идриси картасы (1154 нче елда төзелгән) буенча, «су көймәсе йөреше» ераклыгы түбәндәгечә исәпләнелгән: елга агымына каршы бер көнлек юл – 25 км тәшкил иткән, ә агым уңаена бер көндә 75 км йөзеп булган [Шунда ук: Б. 52].

## Йөзгеч төрләре турында

Сәүдә су юлларында йөк ташу өчен кулланылган йөзгеч төрләреннән корабларны, көймәләрне (кәмәләрне) һәм каякларны санарга мөмкин. Юешләнми һәм бүртми торган агач-ише тауарны үзләреннән сал ясап, яисә сал өстенә төяп елга агымы буйлап агызып ташыганнар. Кайбер тауарлар бурдюкларга бәйләп, калкавыч сыман көймәгә тагып та ташылган. Кораб һәм көймә – чынлыкта җыелма конструкция, такта һәм бруслардан җыела. Мондый төр йөзгечләр, гадәттә, тыныч һәм мул сулы тирән елгаларда йөзү өчен кулланылган. Йөзү ысулларыннан: 1) су агымы буйлап «агып бару», 2) йөзгеч бортларына беркетелгән ишкәкләр белән ишеп йөзүне тизләтү, 3) җил уңаена җилкәннәр белән тизләтү, 4) агымга каршы ишкәкләр белән туктаусыз ишеп йөзү, 5) елганың салмак агымлы «тоба» урыннарына күчә-күчә йөзеп бару, 6) яр буеннан аркан ярдәмендә атлар, үгезләр, «бурлак» хезмәтен башкаручы «тартарчылар» тарафыннан тартып бару ысулларын санарга була. Каяк – бер юан бүрәнә кәүсәсеннән генә чокып калын стеналы итеп ясалган йөзгеч төре. Күбесенчә, шашкын агымлы, төрле шарлавыклы, кыя-таш арасыннан агучы, бормаланып аккан елгаларда йөзү өчен кулланылган. Каякчы ике башы да ишүгә җайланган ишкәкне кулыннан төшермичә, йөзгечнең як ягыннан тиз-тиз ишеп, каякның маневрлыгын тәэмин иткән. Калын стеналы булуы аркасында мондый йөзгечкә кыя-ташка бәрелеп ватылу куркынычы да янамаган диярлек.

## Тарихи экскурс

IX–X гасырлар чоры – «Хазар ханлыгы»ның көчсезләнүе һәм илдә дин сугышлары, сепаратизм хәрәкәте башлану белән үзенчәлекле булган. Югары Иделнең (Волга; Булгы Иделе) көнбатыш өлешендә яшәгән һәм елга үзәнендә сәүдә юлларында олаучылар, «тартан», кичүләрдә, күперләрдә, көймә-корабларда матрослар булып хезмәт салып, кәсеп итеп яшәүче җирле фин һәм славян кабиләләре христиан дине йогынтысына эләккән. «Варяг» яки «Викинглар» дип Балтыйк диңгезе тирәли утырган норман дәүләтләре – Дания, Швеция, Норвегия һәм Пруссия халыклары бабаларын атаганнар. Татарча аларны «карманнар», ягьни «кар кешеләре» дип йөрткәннәр. Безнең региондагы тәүге христианнар да «карманнардан» булган. Төньяк Увал сырты арьягында гына яшәүче карман-варягларга буйсынган фин, славян кабиләләренең дә чукынды-

рылган булуы моңа булышлык иткән, күрәсең. Боларга өстәп, көнбатыш күршеләр – Днепр бассейнында оештырылган Киев Русенда да дәүләт дине итеп христиан дине сайлануын өстәргә кирәк. Хазария таркалган чорда Идел бассейны тоташы белән болгар, саба (сувар – сабир, себер) һәм буртас исемле төрки кабиләләр кулына күчсә дә, әйтелгән дин сайлау сәбәпләре аркасында, бүгенге Суздаль, Ростов, Тверь шәһәрләре урнашкан төбәк Ростов-Суздаль кенәзлеге буларак аерымланган. Алар Киев Русеннан хакимлек итәргә легендар Рюрик династиясеннән «бөек кенәзләр» чакырып китереп «тәхеткә» утырткан. «Илаһияттән яңа мөрсәлим пәйгамбәр җибәрелүен танымаган», әвәлгечә несториан һәм яковит чиркәвендә («Гайса дине» мәзһәбләре) гыйбәдәт кылган төрки чыгышлы кайбер аксөякләр дә, ислам дине таралуыннан шүрләп бирегә күченеп килгән. Мисалга, Кастра каласын (бүгенге Кострама шәһәре) Чет-морза биләгән һәм шәһәрдәге Ипатьев монастырен төзеткән. Тифәр каласына (хәзерге Тверь шәһәре) кенәз Бахмет һәм улы Бикләмеш нигез салган диләр. Бикләмеш чукынгач «Михаил» исемен алып чиркәү салдырган. 1754 нче елда Ананий Федоров тарафыннан төзелгән җыентыкта Сусудал каласына (хәзерге Суздаль шәһәре) – Асан «премудрый», ә аның бертуганнары Сан белән Авесарханның – Бөек Новгород каласына нигез салулары турында хәбәр бар [Фёдоров: 2012, Б. 304]. Венгр чыгышлы Ефим исемле керәшен кешесе Торжок («Новый торг») каласына нигез салган һәм анда Борис-Глеб монастырен төзеткән. Беренче эш итеп «суздальлеләр» сәүдә юлларын болгарлардан тартып алуга омтылган. «Сәүдәгәр халык» буларак танылган, сугыш эшен бик өнәмәгән болгарлар «ныгытылган калаларда гына каты торганнарын» яхшы белгән «суздальлеләр» эшне болгар шәһәрләрен һәм сәүдә факторияләрен юк итүдән башлаган. Сәүдә юллары өчен туктаусыз барган сугышлар нәтиҗәсендә болгар, аннан аларның варислары булган казан сәүдәгәрләре башта Иделнең Булгы Иделе (Волга), соңрак Ука (Ока) бассейннары елгалары буйлап узучы сәүдә юлларыннан колак какканнар. Батый явына кадәр үк Булгы Иделенә коючы өске агым елгалары Кече Китеж каласы (хәзерге Городец-Радилов) торган урынга кадәр «суздальлеләр» кулына күчкән. Алтын Урда чорында, берникадәр чигенеш булып, бу өч дәүләт уртак дәүләт эчендә яшәп алып үзара каршылыксыз сәүдә итешкән. Әмма бу уртак дәүләт таркалу белән, сәүдә юллары, яңа җирләр өчен сугышлар яңадан кабынып киткән. Төньяктан Бөек Новгород вече республикасы (ас-Славия) бер туктаусыз «ушкуйник» (елга пиратлары) отрядлары җыеп, финанслап, талау походлары оештырган. «Ушкуйниклар» Идел Болгары җирләрендә бәйсез Вятка (Хлынов) вече республикасы һәм Бөек Пермь дигән «бәйсез төбәкләр» төзүгә ирешкән. Ул гына да түгел, «ушкуйник» отрядларының

кайчак ныклап көчәеп китеп Новгородның үзенә каршы талау походлары оештырганы да билгеле. Казан ханлыгы оешкан вакытка, элекке Владимир-Суздаль кенәзлеге нигезендә барлыкка килгән Московия дәүләте, Булгы Иделенең хәзерге Түбән Новгород шәһәре торган урынга кадәр, өске агым буйларына хуҗа булып өлгерә. Христиан динлеләрнең «Сарай епархиясе» дә бу төбәккә күчерелгәч, Московия дәүләте, магнит төсле, керәшеннәрнең туплану үзәгенә әверелгән. Ике арадагы чик Керженец, Унжа, Кострома елгаларының өске агым буйларыннан узган була. Идел Болгарының пайтәхете дә сугышлар нәтиҗәсендә акрынлап көнчыгышка таба «чигенергә» мәҗбүр ителгән. Башта башкала Артан (Арт-Болгар) каласыннан Брәхимгә күчерелгән. Аннары Брәхим яндырылгач, берара Биләр (Олы-Болгар) каласында булып торган. Батый хан явы барышында бу башкала да тар-мар ителгәч, ахыр чиктә пайтәхет Кече Болгар каласында урнашканы мәгълүм. Казан ханлыгы башкаласы башта Иске Казанда (Болгар-әл-Җәдид) һәм аннан Казан каласында урнаша.

Бүгенге көндә урыс халкы яшәгән төпкел төбәкләрдә урнашкан «тартаннарны», су юлы булырлык елгаларны, санап чыгуны кемдер бәлки кирәксенмәс тә. Аларның да безнең тарих өчен мөһимлеген аңлатып китсәк дөрес булыр. Төрки халыклар идарә иткән Бөек Төрки һәм Хазар ханлыклары чорларында да бу төбәк халкы белән уртак ватанда яшәгәнбез. Идел Болгары һәм Казан ханлыгы чорларында, биредә татар сәүдәгәренә сәүдә итешү бәлки мөмкин булмагандыр. Әмма Алтын Урда чорында, «Залесский стан» (Владимир-Суздаль кенәзлеге җирләре) базарлары татар сәүдәгәрләре өчен ачык булган. Өстәвенә, төпченеп китсәң, кенәзлекнең көнчыгыштагы җирләрен элек болгар бабаларыбыз биләгәне ачыклана. Җучи олысы җирләре көнчыгышта Енисей елгасы үзәнен үз эченә алып, көнбатышта шартлы рәвештә «Батый линиясе» дип аталган чиккә кадәр барып җиткән була. Бу «линия» Әдрән (Адриатик) диңгездән төньякка табан Эльба елгасы буйлап Данияга – Балтыйк диңгезенә кадәр сузыла. 1245 нче елда «Кабку-саин иясе» Батый хан яулары нәкъ шушы чиктә тукталган. Аерым тарихчылар тарафыннан тискәре бәя бирелгән бу яулар, көнчыгыш Европада 200 ел дәвамында эчке низагларны туктатып торуын ассызыкларга кирәк. Шушы бихисап территориядә татар сугышчысының ат тоягы эзләре калган икән, димәк, мәкаләдә искә алынган топонимнарны татар теле аша аңлатып карау бер дә хата булмас.

### «Җир кендеге төене» төшенчәсе турында

Дөнья океаннары өлешләрен тәшкил иткән диңгезләргә коючы «бөек» елгаларның күп очракта бер тирәдән башлануларына борынгыдан игътибар иткәннәр. Алар җир асты сулары аша бер-берсенә «тоташкан» төсле тоелган. Төрле елга системаларына караган берничә елганың бер калку

җирдән башлану урынын элгәре «җир кендеге» дип атаганнар. Елгаларны, шартлы рәвештә, кан тамырлары яисә җепләр итеп күз алдына китерсәк һәм аларның «очларын» бергә «төйнәп» куйсаң – шуның моделе күз алдына килер. Мисалга, «Алаун тавы»ннан (урысча «Валдайская возвышенность») төньяк Боз океанына коючы Төньяк Двина елгасы башлана. Янәшә диярлек, шул ук урыннан, Днепр елгасы башлана, ә анысы Кара һәм Урта диңгезләр аша Атлантик океан белән «тоташа». Татар халык иҗатында кулланылган «җир кендеге» сүзтезмәсе тарихи чыганакларда теркәлгән «пуп земли» төшенчәсе белән тәңгәл килә төсле.

Җирне, бар тереклекне туйдыручы, мифологик кеше – «Җир-ана» образы белән тиңләштерү гадәте бар. Кеше гәүдәсе кебек җир өстендәге табигый объектларга да кеше әгъзасы атамалары бирелгән. Мисал эзләп ерак барасы түгел, һәркемгә диярлек әйләнә-тирәбездәге яхшы таныш исемнәр. Чишмәләрне «яшьләре агып чыккан кеше күзенә» охшатып «күзләү» яки «кизләү» (кырым-татарча «гизлев») дип атаганнар. Диңгезләрдә, күлләрдә тоташ кеше әгъзалары атамалары – «борын», «авыз» (урыс телендә күбрәк «ирен» – «губа» дип кулланыла), «бугаз», «култык» һәм башка шундыйлар. Елгаларны бабаларыбыз мифологик «Җир-ана»ның йә тамырлары буйлап аккан кан әйләнеше белән тиңләштергән, йә имчәгеннән агып чыккан сөт, угыз төсле сыекчалар агымына тиңләгән. Һәр елганың «башы», «кулы», «якасы», «куентылары» һәм «тамагы» бар. Елгалар башланган калку урыннарны «каш» диләр, күз өстендәге каш сымак. Бер үк урыннан төрле елга бассейнына караган елгалар башланган җирне кендек төененә охшатып «кендек тавы» яки «җир кендеге» дип тә атау гадәте булган дидек. Аерым төбәкләрдә «җир кендеге» тауларын, елга башы чишмәләрен «туендыручы» җир асты су чыганагына бәйләптер күрәсең, «йөрәк тау» дип атау гадәте бар. Мондый очракта елгаларны, кендектән яисә йөрәктән тәннең бар әгъзаларына «челтәр сыман» таралучы, кан тамырлары буларак күзаллanганы аңлашыла. Әгәр шундый уртак чыганактан агып чыккан, төрле елга бассейны системаларына караган, елга-инешләр «берничә икълим аша агып узып», ахыр чиктә төрле «дөнья океаннарына» койсалар – шул су башы таулары «дөнья төене» булалар да, ахры. Аурупа иске язма чыганакларында теркәлгән «Петля мира» төшенчәсе шул булырга мөмкин.

Теманы яктыртуда кирәк булган кайбер «җир кендеге төене» тауларын («төен таулары») санап китәбез:

«Алаун тавы» («олау» сүзеннән булса кирәк) (урыс телендә «Валдайская возвышенность») – бу таудан Булгы Иделе (Волга) һәм аның кушылдыклары Молога, Тверца елгалары, Даугава (Көнбатыш Двина) һәм Днепр (Вар; Варух) елгалары башлары, Волхов елгасына коючы Сясь инеше, Илмень күленә коя торган Ловать, Мста, Пола елгалары

башланып, агып чыга. «Булгы Иделе» дигән атаманың килеп чыгышы антик чорда булып узган «Бу галәмәте» («паровый катаклизм», грек-эллин мифологиясендәге «Аквилон») вакыйгасы белән бәйле. «Бу җире» дигән макротопоним да шуннан калган. «Болгар тарихы» авторы Хисаметдин бине Шәрәфетдин Мөслими дә «Булгы Иделе» атамасын куллана. Татар халкын формалаштыруда катнашкан Буртас кабиләсе атамасы белән Иделнең урысча «Волга» дигән атамасы да «бу» яки «пар» сүзе белән бәйле. Аурупа тарихларында буртасларны «пароситлар» дию, ә Кара диңгезне – «Понт диңгезе» (шәрыкъ чыганакларында «Бунтис диңгезе» – А.А.) дию – «бу» сүзенең тәрҗемәсе булган «пар» сүзеннән алынган булса кирәк.

«Ишерим тавы» – Урал таулары белән Төньяк Увал сырты тоташкан урындагы иң почмакта «Ишерим тавы» урнашкан. Хантлар аны «Асерум» тавы дип атый, алар телендә атама «салкынлык», «суыклык» дигән мәгънәдә икән. Шушы тау артыннан Кама елгасына коючы Колва һәм аның кушылдыгы Вишера елгалары, Обька коючы Лозьва, Сосьва, Пелым елгалары һәм Печора башланып китә. Шушы урында Урал сыртының көнчыгыш итәгенә чыга торган тарлавык буйлап «тартан» юлы узган була. «Ишерим-Асерум» атамаларын төрки халыкларга кардәш булган этрусклар кулланган «крит-микен язу системасы» буенча аңлатып була кебек. Шул ук ысул белән Урта Уралның иң биек түбәләренең берсе – «Качканар тавы» атамасы – җиңел аңлатыла. Фонетик яңгырашына нигезләнгән беркатлы аңлатма буенча «качкыннар шайкасы» дигәннән түгел, әлбәттә. Этрусклар мирасы өчен бәхәс тынганы юк, һәр халык үзләренең борынгы бабалары белән бәйләргә маташа. Мәшһүр грек философы Синеканың «Шәрык этрускларга дәгьва итә!» дигән канатлы әйтемен исләренә төшерсәк, фәнни яктан беренче чиратта кайсы тел белән чагыштырма анализ ясалырга тиешлеге аңлашылыр дибез. Этруск язмаларын уку буенча якташым Фәрит Латыйпов тәкъдим иткән ПЕПЛОС методикасы да шул ук «крит-микен язуына» нигезләнгән [Латыпов: 1999 (2000)]. Без, үзебездә булган белем багажыннан чыгып, югарыда искә алынган атамаларга түбәндәге аңлатма бирәбез: «Ишерим» («Асерум») атамасында тамыр сүз иҗекләр итеп АС – «аскы як», ЕР – «җир» һәм УМ – «өм – өммәт – халык» дигән өлешләргә таркатырга мөмкин. Нәтиҗәдә – «аскы җир халкы» сүзтезмәсе килеп чыга. Хант-мансилар яшәгән төбәк – Обь елгасы тамагы, ул диңгез өсте тигезлеге белән чагыштырганда түбәнге, аскы агым була. Мансилар телендә Обь елгасы «Ас» дип аталганын да искә төшерергә кирәк. «Качканар» атамасы КАЧ – «чик», КАН – «көн – көнүк – гун» һәм АР – «ир – кеше – халык» өлешләренә таркатып, сөземтәдә «Көнүк (гун) халкы чигендәге тау» ди-

гән мәгънәдәге сүзтезмә чыгарабыз. Шушы ук методиканы куллансак, ушкуйниклар «оештырган» Бөек Пермь «ирекле төбәгенең» тәүге башкаласы Чердынь шәһәре нинди болгар каласы урынында нигезләнгәне ачыкланыр. Бүгенге атама төбәкчеләр уйлаганча коми-пермяк теле аша түгел, ә урыс теле аша аңлатылырга тиеш. Төп тамыр сүз «черта» булып, шуннан «чертыня»/«чертынь» сүзе тора-бара «Чердынь» формасын алган. Әл-Идриси картасында Каср (атама варианты – Касирә) һәм Маср (вариантлары – Масира, Масра) исемле болгар калалары теркәлгән. Масра каласы татар халык риваятьләре буенча, бүгенге Мөслим поселогы янындагы Кызыл-таудагы (Әкәй тавы) Урыс-Шуган шәһәрлеге (Базарлы-Шуган авылы янында, Мөслим районы, ТР) һәм «калатау зираты» (Иске Вәрәш авылы янында, шул ук район) дигән археологик һәйкәлләр урынында булганы турында элек язган идек инде. Әйтелгән Ишерим тавы тирәсендә башланган, Кама белән Караидел арасыннан узып, аннан Ык белән Сөн арасыннан дәвам иткән, азак Дим белән Ык арасыннан сузылучы һәм ахыр чиктә, ике Сарайга (Сарай-әл-Мәхруса һәм Сарай-әл-Җәдид) бара торган коры җир юлы булган. Төньякта, әйтелгән юл башында, бүгенге Чердынь шәһәре урынында Каср яки Касира каласы булган да инде. «Крит-микен язуы» нигезендә, башта кала атамасын «КАС» һәм «(Е)Р» тамыр сүзләренә таркатабыз. «КАС» шул ук югарыдагы «КАЧ» («чик») сүзе булуын, ә «ЕР» – «җир» сүзе дип кабул итеп, сөземтәдә «чик җир каласы» сүзтезмәсен китереп чыгарабыз. Урыс телендәге «черта» һәм татар телендәге «чик» сүзләре бер үк мәгънәдәге сүзләр булуы ышанычлы дәлилдер. «Роджер китабы» авторы әл-Идриси: «Идел елгасы башы – Оскаска тавы» дип тә теркәгән. Югарыда язылган ысул белән бу «Оскаска» тавы атамасы мәгънәсенә төпченеп карыйк. Атаманы «ОС» (татар телендәге «ас», «аскы» сүзләре туры килә), «КАС» (шул ук «кач» – «чик» сүзе) һәм «КА» (бу иҗек – кушымча булса кирәк) тамыр-сүзләренә таркатып, нәтиҗәдә «аскы җир чиге тавы» дигән сүзтезмә чыгарабыз. «Аскы» дигәндә, әлбәттә, без, «северная покатость» («төньяк авышлык»), «Обь тамагы» һәм легендар «Тартар чокыры» төшенчәләрен күздә тотабыз.

«Себер капкасы» иңкүлеге («Средний Урал») – Урал тавы тезмәләренең «өзек» урыны, Ямантау, Калкантау һәм Ирәмәл таулары тирәләре. Урта Урал тоташ сыртлардан тормыйча, күбрәк утраусыман ялгыз таулардан тора. Өстәвенә, мондагы тау тезмәләре, Көньяк, Төньяк һәм Поляр Урал сыртлары белән чагыштырганда, иңкүлек сыман түбәнрәк булуы белән аерыла. Чама белән, борынгыдан бирле чик билгесе булган «Ара ташы» кыясын («Арский камень» шифаханәсе янында, БРның Белорет районы) һәм Трёхгорный шәһәрен (Чиләбе өлкәсе) ориентир ит-

сәк тә дөрес булыр. Бу урыннан Иделгә коючы Өфе иделе (Караидел) һәм аның кушылдыклары – Әй, Йөрүзән (шәҗәрәләрдә «Үзән» исемендә теркәлгән – А.А.) елгалары, Объ елга бассейнына караган – Исәт елгасына коючы Миәс белән Тубылга коючы Уй елгалары да башлана. Шушы урыннан ерак түгел, Калкантаудан Каспий диңгезенә коючы Җаек елгасы да баш ала. Янәшәдәге Ирәмәл тавы итәгеннән Агыйдел елгасы да агып чыга. БРның төньяк-көнчыгышында, Белорет һәм Кыйгы аралыгында гына, берничә «капка» дигән топоним очрый. Караидел (Өфе иделе) елгасының төп агымы («русло») һәм аның кушылдыклары Йөрүзән белән Әй елгалары үзәннәре – татар дәүләтләре тар-мар ителгән соңгы чорга кадәр татар сәүдәгәрләре, мосафирлары өчен, Урал таулары аша чыга торган, төп «капка» хезмәтен үтәгән. Чөнки, исемләнгән елгалар Урал таулары артыннан, аның көнчыгыш итәкләрендә башлана. Елганың ике төрле атамасы төньякны белдергән «кара» һәм зират, курганны белдергән «уба» сүзләреннән ясалган [Ахунов: 2019. №40–42 (1251–1253)]. Караидел елгасы борынгы металлургия үзәге булган Иртәш күле буендагы Сагатин (Чаготин) каласы (хәзерге Кыштым, Кәсли, Озёрск шәһәрләре урынында булган) яныннан ук башланып, әйтелгәнчә, Урал тауларын аркылы кисеп чыга. Елгасы башланган сыртны «Юрма тавы» диләр, ул хәзерге Карабаш шәһәре тирәсе була. Юрма тавы атамасы татарчадан «Йөрмә тавы», ягъни «йөри торган тау» дигәннән алынган. Сыртны «Чертовы ворота» дигән тарлавык кисеп чыга. Кагыйдә буларак, урыслар атаган «чёрт», «шайтан» кебек җен-пәриләр белән бәйле атамаларга очрасаң, заманында татарлар белән бәйле һәйкәлләргә юлыгасың. Димәк, Юрма тавындагы тарлавык аша, борынгы коры җир юлы узган. Югарыда тасфирланган, төньяк-көнчыгыш диагональ буенча узган, Касира – Масира – Сарай юлының бер чаты ул. Караидел һәм Кама елгалары арасындагы субүләр буйлап барып, бер тирәдән Тулва, Төй, Танып, Буй елгалары, һәм Ирән суы кушылдыклары башланган «субүләр төенгә» (урысча әйткәндә «водораздельный узел») килеп чыгылган (Пермь крае Чернушка шәһәре тирәсе). Аннан, Йөрүк Танып елгасының ике ягыннан да елга агымы уңаена юлны дәвам итергә булган. Танып елгасының борынгы атамасын бүгенге көндә татар теленә «Җитез Таныл», башкорт теленә «Тере Таныл», урыс теленә «Быстрый Таныл» дип «аударырга» тырышыла. «Книга Большому чертежу» авторы А. Мезенцев та кайбер елгаларның (Ыргыз, Сал, Сакмар, Самар сулары санала) «Юрикъ» («Урюкъ») кушымтасы булуына игътибар иткән һәм аны «резвая» дип тәрҗемә иткән. Чынлыкта исә бу – бары тик олы юллар уза торган елгаларга гына, ориентир өчен бирелә торган атамадыр. Кышларын боз өстеннән, ә җәйләрен – шул елга буйларыннан йөрелә торган елгалар, димәк. Атамадагы «йөрүк» кушымтасы «йөри

торган елга буе (яры, якасы)» дигәнне аңлата. Хан заманнарында Танып елгасының һәр ике як субүләре буйлап «Аргыш юлы» узган. Сул як яр буйлап барсаң – Агыйдел буендагы Аргыш авылы (БРның Дүртөйле районы) аша узасың һәм «Әңгәсәк кичүенә» килеп төртеләсең. Әгәр Танып белән Буй арасыннан узып Агыйделгә төшсәң, БРның Калтасы районындагы Аргыш инеше (Кәлтәй суына коя) буйлап узып, ахыр чиктә Иске Аю авылы тирәсендәге «Андреевский брод» кичүенә (Андреевка авылы янында, БРның Илеш районы) барып төшәсең.

«Җиремҗә кыры» («җир-ана түше») – Агыйделнең уң ягындагы, «урман як» яки «идел эче» дигән төбәктә, Агыйделгә коючы Танып, Камага коючы Буй, Тулва елгалары һәм Караиделгә коючы Төй елгалары бер тирәдән башлана торган ялан. Бу урын Пермь краеның Чернушка шәһәреннән бераз төньяктарак урнашкан. Өстәвенә моннан Сылвага коючы Ирән елгасының берничә кушылдыгы да башлана. Борынгыдан олы юллар кисешкән юл чаты булган урын. Су юлларын кыскарту һәм көймәләрне Кама бассейны елгалары арасында бер-берсенә күчерү максатында бу урынны файдалану бик тә отышлы булган. Идел елгасын борынгы бабалар шартлы рәвештә Җир-ананың «гәүдәсе» белән тиңләштергән дидек. Идел башында «күз», «күз яшьләре» төшенчәләре топонимнарда кулланылса, бу тирәләрдә «имчәк тавы», «җир түше» атамалары очрый. «Җиремҗә» атамасы да «җир имие» дигән сүзтезмә булуы тоемлана. Бу очракта елга сулары имчәктән агып чыккан сөт агымы буларак күз алдына китерелгән, димәк. Ирәктәй волостының ике урында җире булып, берсе – Ык буендагы «Абдалби җире», икенчесе – бу тирәдәге «Җиремҗә җире» («Исәнби аймагы») була. Гали Чокрый һәм Гарифулла Кииковлар хезмәтләренә таянып, без бүгенге БРның Тәтешле районы территориясен «Җиремҗә җире» белән тиңләштерергә гадәтләнгәнбез. Чынлыкта исә, саналган елгалар башланган урын тарихи бу җирнең «үзәген» тәшкил итүе аңлашыла. Пермь краендагы Тюш посёлогы, БРның Балтач районында Тушкыр авылы (башта «түш кыр» булганга охшый) атамаларын дәлил итеп китерәбез. Борынгы «Истәк үзәге» дә булган урын ул. Риваятьләрдә искә алынган Зәй-кәтүн һәм Истәк калаларының берсе шул тирәдә урнашуы мөмкин.

«Көягеш сыртлыгы» («Бәләбәй-Бөгелмә калкулыгы») – сыртлыктан башланып, төрле якка агып китеп, Кама, Агыйдел һәм Идел елгаларына коючы кушылдыкларны аерып торучы субүләр дә «җир кендеге төене» дисәк була. Бу урында Калмашбаш авылыннан (Чакмагыш районы, БР) Нигъмәтулла мулла Ибәтуллиннан (1901 – 1987) 1986 нчы елда язып алган хәтирәләрен китерү урынлы булыр: «*...Безнең тирәдәге бик зур тау – Көягеш сырты, ул Чәрмәсәннән башлап*

*Ык суына тиклем сузыла. Сыртның бу ягыннан Күчәрбай, Абзан, Ламу, Көягеш сулары, Түреш елгасы, Идәш, Яңа Хәҗимән елгасы, Кабык-күпер (Иске Гусево) елгалары агып чыга. Ә теге ягыннан – Аблай елгасы, Көсәкәй, Сәвәде, Калмаш сулары, Макар, Каразирек* елгалары, Яңа Әлмән елгасы, Яңа Почкак суы, Каратал, Зонник, Күәш, Байбулат елгасы – Өрекмән сулары агып чыга. Безнең авыл да Көягеш сыртында утыра!» Кадими мондый белемнәр турында тәүге сабакны бирүче зат, заманында мәдрәсәдә белем алган гади авыл карты иде. Археографик эзләнүләр барышында, интеллект буенча чагыштырганда «мәдрәсә бетергән картлар» белән «совет картлары» арасындагы аерма җир белән күк арасы кебек икән дигән нәтиҗәгә килдек. Көягеш сыртлыгында урнашкан ТРның Бөгелмә шәһәре һәм Акбаш авылы тирәсендә Иделгә коючы Сок, Камага коючы Шешмә белән Зәй елгалары, Ыкка коючы Дим елгасы башланып китә. «Бөгелмә» атамасы «буга (үгез) алмак» дигәннән булырга тиеш. Сәүдә корабларын икенче елга үзәненә күчерер өчен җиккән үгезләр яллау урыны булырга мөмкин. Нәкъ шушы тирәләргә заманында К.М. Тәфкилев крестьяннары урнаштырылуы да күп нәрсә хакында сөйли, колониаль хөкүмәткә турыдан-туры буйсынган җирләр булган, димәк. Дәүләт милкенә әвереләдерелгән «тартан»-ның монда урнашуы да мантыйкка туры килә. Кораблар салынган арбаларны (чаналарны) тартып баручы үгезләр (яисә алашалар) килүен алдан кисәтү өчен малларга кыңгыраулар тагылган була. Дим һәм Ык елгалары арасында болак-каналлар булуга ишарәләр бар дидек. БРдагы район һәм авыл исеме булган «Бишбүләк» атамасы да биш болак булганны күрсәтеп, «кычкырып тора» шикелле. Акмый торган сулыкларда йөзгечләрне хәрәкәткә китерүче көч – әлбәттә, нәрсә беләндер тарттырып бару булган. Кушымчасы төшеп калган «кыңгырау» һәм «буга» сүзләре борынгы «тартаннар» урынын күрсәтүче топонимнар дияргә була. Бу тирәләрдә Ык бассейнына караган Кыңгыр елгасы ага. Урал ягында сөйләнелгән риваятьләрдә «Куңгыр буга юлы» искә алына. Пермь краенда Кунгур шәһәре атамасы да «кыңгырау» дигәннән үзгәрүе мөмкин. БРның Бакалы һәм Бөгәбаш авыллары атамалары да «буга» сүзеннән булса кирәк. Монда утыртылган керәшеннәр һәм чувашлар бабалары «тартан» хезмәтен башкаручылар булмас димә.

«Мөһаҗирләр тавы» яки «Йөрүк (йөреш) тавы» («Мугоджарские горы») – бу калкулыктан Җаекка коючы Орь елгасы, Каспийга коючы Җим (Эмба) елгасы һәм элек Арал диңгезенә койган Тургай (Саук) елгасы кушылдыгы Йөрүк Ыргыз елгасы башлана торган калкулык. Калкулыкның исеме әйтеп тора: моннан борынгы төркиләр юлы узган. Урысчага «гора эмигрантов» дип тәрҗемә ителергә тиеш.

«Олы тау» («Улытау») яки «Аргынат тавы» («Арганаты») – монда, Киндерлек (казахлар Кара-кинер диләр) елгасы буенда Җучи олысының тәүге башкаласы Орду-Базар каласы (элекке Кангар – көнүкләр башкаласы урынында яңартыла) урнашкан булган. Бүгенге көндә чүллектә урнашкан Сәмәрканд һәм Ашхабад шәһәрләре диңгез буенда урнашкан порт-лиманлы калалар булуын күпләр белми дә. Берничә тапкыр кабатланган җир тетрәве нәтиҗәсендә борынгы диңгез суы җир ярыкларына сеңеп бетеп, нәтиҗәдә күлләр сыман ике зур су чыганагы – Каспий һәм Арал диңгезләре торып калган диләр. Шушы «уртак» диңгезне төрле чор тарихи чыганаклар «Хазар диңгезе», «Хвалис (Хвалын) диңгезе», «Гиркан (Җүрҗән) диңгезе» дип атый. Борынгы «уртак» диңгез үзе дә антик чорларда «монда борынгы кешеләр килгәндә» Обь (Тартар) елгасы урыныңдагы «диңгез бугазы аша Төньяк боз океаны белән тоташкан» булуы турында риваятьләр калган. Ул диңгезне галимнар шартлы рәвештә «Сармат диңгезе» дип йөртә. Шуңа охшаш легендаларда Балтыйк диңгезе дә, уртак диңгез хасил итеп, Азов диңгезе (Азак яки Әҗәк диңгезе) белән тоташкан булуы турында бәян ителә. Ягъни, бу диңгезләр борынгы мифларда телгә алынган легендар «Тетис океанының» өлешләрен тәшкил иткән.

Заманында Олы-таудан агып чыккан мул сулы елгалар буйлап, Сырдарья елгасына йөзеп төшеп, аннан Баласагун, Семекне калаларына су юлы белән барып җитеп булган. Әмма риваятьләр буенча, «тәңре җәзасы», «гөнаһ шомлыгы аркасында» катаклизмнар нәтиҗәсендә югарыда әйтелгән климат үзгәрешләре күзәтелгән. Елга сулары кибә башлагач та, әле шактый еллар сәүдә су юлларын йөзәрлек булсын өчен корабларны йөздереп күчерә торган махсус «болак-каналлар системасы» казылган. Бу хакта күп сөйләп тормый интернет-ресурстан цитата китерү белән чикләнсәк, хилафлык булмас: «По археологическим раскопкам реки Сарысу, Иргиз, Тургай и Чу имели общий сток – в бассейне Сырдарьи. По мере нарастания засушливости климата, и тектонического поднятия коры, обширный бассейн Аральского моря распался на несколько отдельных систем. Вместе с тем, вследствие тектонических явлений река Узбой перестал впадать в Каспийское море и направились на север в Аральское море» [https://ru.wikipedia.org/wiki/Сарысу].

Казахстандагы Семипалатинск (Алаш) шәһәре атамасы да шул «болак-каналлар системасы» булуга ишарә итә. Каспий һәм Арал уртак диңгез булган чорда, диңгездән Тургай елгасы һәм җиде болак-канал аша Обь елгасы кушылдыклары – Тубыл, Ишим башларына кадәр йөзеп барырга мөмкин булган. Археологик казынулар гына түгел, җирле топонимика да шундый «болаклар» булуны исбатлый. Мисалга: 1) Җим (Эмба)

буенда Жагабулак авылы һәм коры елгасы бар; 2) Шул ук Семей (Семипалатинск; Алаш) шәһәре тирәсеннән Егиндыбулак елгасы ага һәм Жарык дигән авылы бар; 3) Казахстан картасыннан «болак» сүзе кергән топонимнар – Айнабулак, Бетбулак, Мибулак, Ембулак атамаларын табарга мөмкин. Тора-бара чүлләнү процесслары үзенең критик ноктасына җитә. Югары температура аркасында, каналлардагы сулар тулып та өлгерми, бик тиз парга әйләнеп бетә башлаган. Мондый шартларда, әлбәттә, су юлларында йөзгечләр куллану тукталган. Җүчи олысы башкаласын Орду-Базар каласыннан мул сулы Идел буйларындагы калаларга күчерү сәбәбе – климат үзгәреше булган дибез.

«Казык уртасы тавы» яки «җир уртасы» төшенчәләре турында. Казахстандагы Чемкент (казахча Шымкенд) шәһәре янындагы тарихи тау – аны Казахлар «Кузыгурт тавы» диләр. Урта гасыр латинча чыганакларда тау «Монс Таурус» буларак теркәлгән. Урыс телендә тауны «Быкова гора» дип атаганнар. Күрәсең, угызлар белән бәйле рәвештә, «угыз» һәм «үгез» сүзләренең фонетик охшашлыгы буенча шулай атаганнардыр дибез. Төрки «урталык халыклары» риваятьләре буенча, тау башына «Туфан суы кайтканда Нух нәби көймәсе туктаган» һәм урта гасырларда тауны «җир уртасы» итеп санаганнар. Чынлыкта, Нух нәби өч улына җир йөзен Арарат тавы (хәзерге Ирактагы тау сырты) түбәсендә торып бүлгән имеш. Бүгенге Чемкент урынында, «дөнья яратылганнан бирле» Семекне дигән кала урнашкан булган. Татар кешесе колагына ятышлы итеп «Самныкы» яки «Сам каласы» дип бераз үзгәртсәк дөрес булыр. Шәһәрнең бүгенге атамасы да «Сам (Чем, Шым) каласы» («канд» – «кала», «шәһәр», «торак пункт») буларак яңгырый. Тау башында эре тау ташыннан тәре-хач сыман итеп өелгән борынгы тарихи корылма бар. Нәкъ менә шушы, «Урта таш» дип билгеле корылма, «җир уртасын» күрсәтүче билге булып исәпләнә дә инде. Борынгы төрки бабаларның географик «башлангыч ноктасы», «җир котыбы»! Риваятьләр буенча, Сам баба үзенә бүленгән җир өлешен балаларына бүлү нияте белән шушы урында тәүге чик казыгы каккан урын. Шушы тәүге казыкка «бәйләп», межа таяклары һәм ориентир булырдай табигый объектлар ярдәмендә, үз биләмәсен дүрт кисәккә бүлгән имеш. Көнчыгыш тармак төркиләре өчен, «тәүге исәп башы» булган урын! Әвәлге чикләрне билгеләү нияте белән кагылган «тәүге межа казыгы» дисәк тә дөрес булыр. Коры җир сәүдә юллары турында бәян иткәндә, без шул «өлешләргә» ныклап тукталырбыз.

*(Дәвамы бар)*

**Әдәбият**


1. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, Казан, ТКН, 1981, III том.
2. В.М. Беркутов «Народный календарь и метрология булгаро-татар», Казань, ТКИ, 1987.
3. Фёдоров Ананий, «Историческое собрание о богоспасаемом граде Суждале», Владимир, 2012.
4. Ф.Р. Латыпов «Исследование этрусского и минойского языков на основе фоноэволюционной пратюркской гипотезы и комбинаторно-частотных методов», Уфа, Китап, 1999 (2000);
5. Айдар Ахунов, «Уфа каласының атамасы», «Мәдәни җомга» гәзите, №40–42 (1251–1253), 11, 18, 25 октябрь саннары, 2019, Казан;
6. Википедия/ https://ru.wikipedia.org/wiki/Сарысу.
7. Н.П. Барсов «Очерки русской исторической географии», Варшава, 1885.
8. Айдар Ахунов, «Урал алды татарларының формалашуында мадьяр компоненты», «Историко-культурное наследие» гәзите, №4–6 (15–17), IV–VI, 2010, Яр Чаллы.
9. Улоф фон Далин, «История Шведского государства», СПб., 1805.
10. А.В. Галанин «Волоки Северо-Восточной Европы»// Вселенная живая [Электронный ресурс] – Владивосток, 2009–2013, http://ukhtoma.ru/volok4.htm.
11. Лызлов А. «Скифская история» / Подг. текста, комм., указ. А.П. Богданов; Отв. ред. Е.В. Чистякова – М.: Наука, 1990.
12. Александра Исаева «От Волги к Дону», «Волгоградская правда», 10.08.2012 ел, https://vpravda.ru/kultura/mesto-dlya-vvoda-teksta-3473/.
13. «Полное собрание законов Российской империи с 1649 г.», Т. IX–XX, СПб., 1830. Уфа: 2022–2023.

*Ф.М. Зиннәтуллина*

# МУЛЛАШ АВЫЛЫ ТАРИХЫ



*Муллаш авылы. Дуван елгасы.*

*Бөтен Себер буйлап,*
*Орлык кебек,*
*Татар авыллары сибелгән.*
*Гасырларның*
*Изге туфрагына*
*Тамырлары тирән күмелгән.*
*Б. Сөләйманов*

## ***Кереш***

Төмән өлкәсе, Төмән районында урнашкан Муллаш авылына быел 305 ел була. Төмән шәһәреннән 50 чакрым ераклыктагы себер татар авылы ул. Муллаш матур табигатькә бай җирдә, калын урман эченә кереп урнашкан. Авылның уртасыннан Индерәй күленнән агып чыккан Дуван елгасы акса, Урал тауларыннан агып килгән Пышма елгасы авылның бөтен ягыннан диярлек уратып алган. Бу урын элек-электән җиләк-җимешкә, төрле җәнлекләргә, балыкка мул булган.

Муллаш башка авыллардан табигате белән генә түгел, төзеклеге белән дә калышмый. Монда киң күңелле кунакчыл себер татарлары яши. Авылда мәчет электән салынган, халкы динле булган, татарларга гына хас гореф-гадәтләрне, йолаларны тотып яшәгән. Хәзер дә авылга килеп керү белән мөселман авылы икәнен белдереп, соңгы елларда яңадан салынган матур мәчет ерактан ук күренә.

## ***Авылның килеп чыгышы***

Һәр авылның үз язмышы, сикәлтәле тарихы бар. Тарихи чыганаклардан, әби-бабайлар тарафыннан язып алынган истәлекләрдән чыгып карасак, авыл элек бер-береннән 1–2 чакрым ераклыкта урнашкан берничә урыннан торган. Моның сәбәбе: ике елганың якын урнашуы, яз көннәре су ташуы. Халык өйне биегрәк урыннарга салырга тырышкан. Беренче авыл хәзерге төп авылдан 2 чакрым ераклыкта, Дуван елгасы буенда урнашкан һәм ул «Дуван-авыл» дип аталган. Анда балыкчылар, аучылар гомер сөргән, мәчет тә булган дип сөйли иде авыл картлары, авылның зират урыны әле дә билгеле. Дуван халкы хәзерге авыл урынына язгы ташкыннар булу сәбәпле күчә башлый. Гаиләләр яңа йорт урыны эзләргә мәҗбүр була.



*Описание деревни.*

Архив документларына карасак, безнең авыл тирәсендәге җирләр Шыкча авылында яшәгән йомышлы һәм ясаклыларга XVII гасырның ахырында ук бирелгән булырга тиеш [ГАТО. Ф. И 7а. Оп. 2. Д. 329]. Бу җирләрне, ул чорда Шыкча авылында яшәүче кайбер гаиләләрнең «җәйге йорты» булгандыр һәм ул гаиләләр берничә дистә еллар дәверендә хәзерге Муллаш тирәсенә күчеп яши башлагандыр.

«Муллаш» топонимы кеше исеме белән бәйле. Муллаш дигән бабай авылга төп нигез салучы. Якынча, 1710–1740 елларда ясаклы татар Муллаш Айтякович (туу елы билгеле түгел) бу җирләргә килеп утырган булырга кирәк. 1743 ел «Ревизкая сказка» документына карасак, ул үзенең уллары белән «Юрты Муллашинские»да теркәлгән [ГАТО. Ф. И 47. Оп. 1. Д. 4982], ә 1710 елның Ясак китабында ул әле «Юрты Чикчинские»да санала. Бу документта аның хөкүмәткә күпме ясак түләгәнлеге билгеле:



*Ясак китабыннан.*

*«Волости Шикчинских юрт ... Муллашко Айтяков платил новичного(?) ясаку десять алтын и наложено на него ясаку вновь по переписной книги Ивана Качанова рубль 23 алтын две деньги и на нынешний 1706 марта 21 дня Великого Государя в казну с него ясаку две лисицы ценой в рубль да деньгами 30 алтын две деньги в прием у целовальника Федора Родионова»* [ГАТО. Ф. И 47, Оп. 1, Д. 885].

Шул ук елдагы «Ревизская сказка»да Муллаш йортында 21 хуҗалык турында язылган. Бу документка нигезләнеп, 1718 елга караган Беренче ревизия булуын да дәлилли алабыз, ләкин бу документ архивлардан элегә табылмаган [ГАТО. Ф. И 47. Оп. 1. Д. 4982].

Аксакаллар сөйләве буенча, Муллаштан бер чакрым ераклыкта Пышма һәм Дуван елгалары кушылган җирдә дә муллашлылар йорт салып яшәгән. Бүген бу урын истәлекле, аны авыл халкы «Бозкарау» дип атаган. Борынгы истәлекләр шуны сөйли: «Боз киткән вакытны авыл халкы җыелышып бәйрәм ясаган. Яше-карты киенеп-ясанып, ризыклар төяп, елгада балык тотып, учаклар ягып, чәйләр эчеп боз озатуны бәйрәм ит-

кән. Анда төрле халык уеннары, көрәш, ат чабышы үткәргәннәр. Иске әйберләрне җыеп, бозга салып озатканнар. «Авырулар, кайгылар, авырлыклар, күз тиюләр агып китсен», дип им-том иткәннәр.

Бу яр башының тагын бер истәлеге Гражданнар сугышы елларына бәйле. Ул урыннардан Колчак армиясе үткән. Кызыллар һәм акларның бер-берсенә каршы сугышуы билгеле. Сугыш коралларының һаман да табылуы –сугыш кайтавазы. Пышма елгасы ярында Гражданнар сугышы истәлеге итеп, ике һәйкәл куелган. Берсенең исеме билгеле түгел Кызыл командирга багышланган, икенчесе – сугышта һәлак булган кызылармеецларга. Авылдашлар өчен бу урынның тагын бер үзенчәлеге: Бөек Ватан сугышы башлангач, ир-егетләрне Пышма ярбашыннан озатканнар һәм сугыш беткәч, шуннан каршы алганнар.

Хәзерге көндә авылның төп атамасы Муллаш (русча Муллаши), шуның белән беррәттән Пышмы дигән топоним да бик таралган. Авыл халкы ясаклы һәм йомышлылардан торган. Зур токымнар бүген дә авылның нигезен тәшкил итә. Бабшановлар, Нәҗметдиновлар, Хәлиуллиннар, Ярмухаметовлар, Шаргабдуллиннар һәм башкалалар – ясаклылардан, Уразумбетовлар, Уразаевлар, Зөлбохаровлар, Байчуриннар, Йосыповлар, Якиннар һәм башкалар йомышлылардан чыккан.

Авылның башлангыч чорын күзалласак, халыкның борынгы шөгыле турында да әйтеп китәргә кирәк. Бу җирләрнең табигый үзенчәлекләренә бәйле халыкның төп шөгыле балыкчылык, аучылык, җиләк-җимеш җыеп эшкәртү, печән, утын әзерләп сату була. Моның сәбәбе: авыл халкының күпчелеген ясаклы татарлар тәшкил иткән һәм алар үз көннәрен үзләре күргән. Су алу сәбәпле, бәрәңге утырту, ашлык чәчу авырлык тудырган.

Моны 1783 елга караган «Описание деревень Тюменского уезда» дигән документ та исбатлый. Бу чыганактан күргәнебезчә, игенчелеккә яраклы булган җир, барлык җирнең 1/3 генә тәшкил иткән. Шулай ук XVIII гасырда табигать баерак та булган икән. Мәсәлән, нельма балыгын бездә инде онытып та өлгергәннәр.

*«№ 99 юрты Муллашевские состоят над речкой Дуваном на правом берегу на низком месте. Выпала речка из озера Андреевского от юрт выпала верст 20, впала в реку Пышму от юрт в одной версте, шириной речка десять сажен, а глубиной вовсе аршин; рыба чебаки, щука, окунь, ерш, весной бывает и нельма; разливается версты на три; от Ялуторовской дороги верстах в 10. Зверь, птица, ягода тоже показаны, как и выше писанных юртах (в бору есть ягода брусника; зверь – заяц, белка, горностай, волк; птица – журавли, утка, перепела, филины, щеглята, жаварята), бор Пышминский в одной версте из которого на дрова, на строение и на поделки довольствуются, шириной против селения верст*

*восемь, в дачах у них 4 озера: 1-е Бурашкуль длиной 1 верста, шириной 1 верста, глубиной 4 аршина, 2-е Тегайкуль длиной 1,5 версты, поперек 1 верста, глубиной 4 аршина, 3-е Малый Тигайкуль окружностью на 2 версты, глубиной 4 аршина, 4-е Иткуль окружностью две версты, глубиной 4 аршина, рыба в них караси из которой они рыбой и питаются.*

*Удобнейшей под данным селением пашенной земли серого и черного от части грунта 130 десятин, сенного покосу 100 десятин; неудобнейшей под пашню земли с 460 десятин»* [ГАТО: Ф. И 10. Оп. 1. Д. 632].

Авырлыкларга карамастан, кайбер гаиләләр иген чәчу эшен алып барган. Шуларның берсе – Бабшанов Заман (Саман бай). Ул иген игүдән кала, күп итеп мал-туар да тоткан. Аның оештыру сәләтен халык әле дә искә ала. Саман байның үзенең эшчеләр сайлау ысулы булган: булачак эшчене алдан ашатып алган, яхшы аппетит белән ашаганнарны гына эшле иткән. Әкрен ашаганнардан: «Әйдә, энем, син әле эшкә ярамыйсың икән, башта ашарга өйрәнеп ал», – дип көлгән. Ул үз заманына күрә алдынгы карашлы кеше була. Авылда Саман байның кешелеклелеген, юньлелеген һаман да искә алалар. Аның ярлыларга, ятимнәргә үзеннән өлеш чыгаруын, ятим калган туганнарын үз канаты астына сыйдыруын онытмыйлар.

Муллаш халкының элек-электән килгән тагын бер шөгыле: киез итек басу, тире эшкәртү. Муллаш хатыннарының кәҗә мамыгыннан бәйләгән шәлләре күрше-тирәдә бик популяр булган. Соңрак, XX гасыр урталарында, талның кабыгын суеп, аны киптереп сату да халыкка керем китергән.

### *Күмәкләштерү-колхозлаштыру еллары*

Руссиядә барган революция, Гражданнар сугышы, коллективизация шаукымы безнең Себергә дә килеп җитә.

1929 елда авылда телефон, радиолар кулланылышка керә һәм үзәк саналган Төмән шәһәре, тирә-юнендәге авыллар белән элемтәгә чыгуны арттыра. Шулай итеп, илдә барган үзгәрешләр Муллашка да килгән.

1932 елда авылда беренче коммуна төзелә. Хуҗалыктан хайваннар җыеп алына, ләкин аңа халык каршы чыга. Коммуна ике ай гына була һәм тарала. 1933 елда «Свой труд» исемле беренче колхоз төзелә. Башта ул 10 кешедән тора. Билгеле булганнары: Сәгыйдуллин Чәгвәр, Хәлиуллин Сабур, Кармушев Сәфәргали, Ярмухаметов Әбделхай, Нәҗметдинов Яхъя, Айнуллин Арипчан, Речапов Хәлиулла, Хәлиуллин Хәлим. Колхоз председателе булып Сәгыйдуллин Чәгвәр, соңрак Хәлиуллин Сабур сайлана.

1938 елларга кадәр колхозда балыкчылык артеле эшли: балык тоту, эшкәртү, аны сату белән шөгыльләнәләр. Артель башлыгы – Бабшанов Мәхмүт. Ул оста балыкчы, оештыру сәләтенә ия булуы белән башкалар-

дан аерылып тора. Сугышка китеп, һәлак була. 1938–1939 елларда колхоз председателе итеп Шәргабдуллин Фәйзиәхмәт сайлана. Укымышлы, таләпчән җитәкче, сугыш кырыннан кайтмый.

Дәһшәтле сугыш елларында колхоз рәисләре еш алышына. Авыл тарихында билгеле Уразумбетов Янабай баба колхоз рәисе вазыйфасын үтәгәндә ач-ялангач халыкка аш бүлеп биргәне өчен 10 елга төрмәгә ябыла һәм шунда гомере өзелә. Хәлиуллин Сабур баба да, сугышка кадәр һәм сугыштан соңгы авыр елларда колхоз рәисе булып эшли.



*Бабшанов Максут Мәхмут улы.*

1951 ел илебездә зур үзгәрешләр – колхозларны берләштерү елы булып тарихка кергән. Муллаш авылы колхозын 20 чакрым ераклыкта урнашкан Новый Барок авылындагы «Первое мая» колхозына бүлекчә рәвешендә кушалар. Бүлек җитәкчесе – Бабшанов Максуд. 1954 елда Муллаштагы бүлекчәне «Коммунизм»га дип аталган татар Шыкча авылындагы колхоз белән берләштерәләр. Колхоз председателе – Миннибаев Тимербай. Бүлекчә җитәкчесе булып Бабшанов Максуд кала.

Шул ук елда «Яшь комсомол» исемле тракторлар бригадасы төзелә, аның идарәчелеге Червишево авылында урнаша. Авылга беренче трактор 1946 елда ук кайта. Беренче тракторчы – Аблехсанов Рауф баба.

1960 елда колхозларны берләштерү, зурайту тагын да алга китә. Борки, Созоново, Щербак, Шыкча, Талмы, Явызбы, Криводаново, Муллаш авыллары зур «Россия» колхозына кушыла. 1961 елда колхозлар совхозга әверелә. Муллаш авылы бүлекчәсен «Калинин» исемен йөрткән совхозга кушалар. Үзәге – Ямбай авылы. Совхоз директоры Галиев Әбделмалчан исемле кеше була. Бу совхозда Муллаш 10 нчы бүлекчә санала. Авылда яшелчә үстерү, хайван үрчету эшен башкаралар. Бүлекне Бабшанов Максуд җитәкли. 1963 елда Муллаш бүлекчәсен үзәге Богандинка поселогындагы «Тюменский» совхозына күчерәләр. Бүлекчә хайваннар симертү, ит җитештерү үзәге санала.

Шул ук 1963 елда тагын бер истәлекле вакыйга – җирле электр станциясе куела. Хәлиуллин Шамил белән Нурмухаметов Биктимер беренче электр утын кабызучылар буларак авыл тарихына кереп калган. Беренче электр станциясе, 1965 елда «Государственная линия» кергәнче, төнге сәгать уникегә кадәр генә эшләгән.

1969 елда Муллаш бүлекчәсен ОПХ (опытно-производственное хозяйство) «Тополя»га күчерәләр. Аның үзәге – Московский поселогы. 1980 елларда авылда тагын зур үзгәрешләр башлана. «Сибкомплектмонтаж» берләшмәсе Муллашта ПСХ «Монтажник» төзи башлый. Бу совхоз Төньякта урнашкан нефть чыгару предприятиеләрен азык-төлек белән тәэмин итә. Авылда заманча зур ферма барлыкка килә. Саф татар авылында хәтта дуңгыз асрау һәм ит эшкәртү цехлары ачыла.

Авылда зур төзелешләр башлана: кирпечтән салынган йортлар, балалар бакчасы, зур кибет, ашханә, медпункт, спортзал төзелә. Муллашка башка милләт кешеләре күчеп килә башлый. Бүген дә авылга башка милләт кешеләре килүе дәвам итә. Авыл үсә, зурая, ләкин гореф-гадәтләр, йолалар онытылмый.

### *Авылның дини-рухи тормышы*

Муллаш авылын да болганчыклы вакыйгалар читләтеп үтмәгән. Шул ук революция, алдан искә алган Гражданнар сугышы, репрессия еллары... Мәчетләр җимерелгән, дин әһелләребез нахакка җәберләнеп төрмәләргә утыртылган, ләкин халкыбыз рухында дин сакланып калган.

*«Авылыбызнын рухи тормышы*
*Манарадан нур ала,*
*Мәчетле, иманлы авыл*
*Тарихка кереп кала!»* – дигән шигырь юлларында әйтелгән кебек, мәчет авыл халкының рухи тормышына зур йогынты ясый, чөнки халкыбыз элек-электән дингә ышанган.

Архив документларында безнең авыл мәчете XIX гасыр башында искә алына. 1815 елда «Ведомости о магометанских мечетях по уездам» дигән документ буенча, Муллашта авыл халкы акчасына агачтан мәчет салына. Мәчеткә йөрүчеләр санын 37 кеше тәшкил итә. [ГАТО. Ф.И 329. Оп. 2. Д. 54. Л. 45] Әмма авыл картлары сөйләве буенча, моңа кадәр Дуван авылында да мәчет булган. Шул мәчетне Муллашка күчергәннәр дигән фикер дә бар.

Әлегә мәгълүм булган материаллардан чыгып бу мәчеттә 1832–1856 елларда имам вазифасын Ярмухамет Аллабердиев (1789–1858) үти. 1856 елдан алып аның улы Тачетдин Ярмухаметов (1822 – билгесез ) якынча XIX гасырның 60 нчы елларына кадәр бу эшне башкара, ә 1970 елларда – Кульмухамет Юмачиков. Шул ук гасырның 80 нче елларында Муллаш һәм Манат авылларында Айтмухамет Шамсутдинов имам була. [Кабдулвахитов: 2005. С. 93; Гарифуллин: 2004. С. 63] 1882 елда Муллаш мәхәләсендә 106 ир кеше һәм 92 хатын-кыз була [Гарифуллин: 2004. С. 61]. Революциягә кадәр һәм аннан соңгы елларда Мухаметгариф Шаргабдуллинның имам-хатыйп эшен алып баруы билгеле. [Кабдулва-

хитов: 2005. С. 120; Гарифуллин: 2004. С. 77]. Архив документлары буенча 1923–1924 елларда Хакимов Абдулхаким муллалык эшен алып бара. Мәхалләдә кеше саны 169 булган [Кабдулвахитов: 2005. С. 125].

«Тобольский статистический комитет» материаллары буенча, 1903 елда Муллаш авылы мәчете каршында мәдрәсә эшләп килгән [Гарифуллин: 2004. С. 68].

Бу болганчык елларда авыл халкы динне саклап калу өчен үзенчә көрәшә һәм гыйбадәтханәне саклап кала. Төбәкче И.Б. Гарифуллин үзенең хезмәтендә мондый фактлар китерә: «В исламском храме Муллашах были организованы красный уголок, школа ликбеза. Как свидетельствуют архивные бумаги, отец с сыном избили бывшего председателя Муллашовского сельсовета за закрытие мечети, затем «группа лиц выбросила из здания мечети все оборудование красного цвета и школы ликбеза. Трое подстрекателей было арестовано, но население их увезти не дало, заявив, что их под суд не отдадим, а актив весь перебьем. Как бы в подтверждение своих слов стали кидать кирпичами» [Гарифуллин: 2004. С. 111].

Әмма соңрак мәчетне барыбер ябарга карар кылына. Тулы дога кылу, хатым ашлары, ураза тоту, дини йолалар һәм бәйрәмнәр үткәрү катгый тыела. Шуңа да карамастан, авыл халкы яшерен рәвештә дини йолаларны, гореф-гадәтләрне тотып яши. Хәтта Бабшанов Сабах һәм Байчурин Сәфәр бабалар җомга намазына атна саен 30 чакрым ераклыкта урнашкан Шыкча авылына җәяүләп йөрүләрен авыл халкы әле дә искә ала.

Бу елларда илдә барган дингә каршы агитация безнең авылны да читләтеп үтмәде. Дингә каршы агитбригадалар төзелә һәм алар Төмән янында урнашкан татар авылларында агитация эшләрен алып бара. Агитатор блокнотыннан:

«...В деревнях Муллаши, Чикча Тюменского района исполняют намаз до 46, а соблюдают уразу (пост) до 70–75 человек... В деревне Муллаши Тюменского района из 194 опрошенных 108 назвали себя верующими, 47 из них знают Коран, 125 человек отмечают Курбан-Байрам, 73 – соблюдают уразу, 79 проводят «хятем-хуча». В 24 домах имеются шамаилы – картины видов Константинополя и Мекки с изречениями Корана. Среди верующих женщины составляют примерно 60–70% ...» [Кабдулвахитов: 2005. С. 154–155; Гарифуллин: 2004. С. 123].

Чыннан да, бу сүзләргә дәлил итеп, мондый фактларны китерергә мөмкин: дини мәҗлесләрне, йолаларны үткәрү хатын-кызлар җилкәсенә төшә. Аларны үткәргән вакытта гаилә башлыгы партия әгъзасы булса, өйдән чыгып торган.

XX гасырның 60 нчы елларында хакимият мәчет биналары урынына мәдәни үзәк булдыру карарларын чыгара башлый. Безнең авылда да 1965

елның 9 июлендә мәчетне сүтеп, клубка нигез салалар һәм бинаның нигезенә хат куеп калдыралар. Бу хат 1991 нче елда клубны сүткәндә табыла. Аның эченә истәлеккә 20 тиен акча да кыстыралар. Хат шул елларга хас булган киләчәккә якты өмет белән язылган. Анда күрсәтелгәнчә, бу эштә ун авыл кешесе һәм читтән килгән ике хакимият вәкиле катнаша. Хатны язучы – Ярмухаметов Тачигали.

Яңа клуб бинасында китапханә, кызыл почмак (изба-читальня) булдырыла һәм кино күрсәтелә.

Үткән гасырның 90 нчы елларында – үзгәртеп кору чорында өлкәбездә яңадан мәчетләр торгызыла башлады. Безнең авыл картлары да җыелышып, авылда иске мәчет урынындагы клубны сүтеп, яңа мәчет салырга уйлыйлар. Шул елларда Авыл советы рәисе булган Хәлиуллин Мухаметсабир Сабур улы җитәкчелегендә администрация карары белән клуб урынында мәчет торгызу турында карар кабул ителә. Яңа мәчетне салуга башыннан ахырына кадәр башлап йөрүчеләрдән Бабшанов Махсуд Мәхмут улы була. Гыйбадәтханәне урынына кире кайтару аның өчен намус эше иде. Чөнки, 1960 нчы елларда Бабшанов Махсуд, авыл управляющие буларак, партия карары буенча, иске мәчетнең манарасын кисү эшен оештырырга мәҗбүр булган. Ул бөтен соңгы гомерен мәчетне торгызу, авылда дини тормышны җайга салу эшенә багышлый.

Халык бу изге эшкә акча туплауны башлап җибәрә һәм 1991 елның 3 июлендә клубны сүтеп, 13 июльдә мәчеткә фундамент салына. Картлар бер айлык пенсияләрен, ә яшьләр хезмәт хакларын бирәләр. Байтак акча беренче өлкә Сабантуенда җыела. Махсуд Махмут улы һәм Ярмухаметов Тачигали баба мәчет төзелешенә акча җыю өчен бәйрәм мәйданчыгына тартма куйдылар. Кешеләр бик теләп сәдака итеп акча бирделәр. Бер таныш булмаган татар хатыны үзенең эш адресын әйтеп, урыс булган түрәсеннән акча алырга булыша. Яңа мәчет өчен беренче зур сумманы Төмән районы комитеты рәисе Валерий Бугаев бүлеп бирә.

Махсуд баба хәтта Россиянең югары мөфтие Тәлгат Таҗетдин белән очрашырга тели. Уфа шәһәренә ул өч мәртәбә бара һәм соңгы баруында гына морадына ирешә. Мөфти аны бик җылы каршы ала, заманасы өчен зур сумма – 25 мең сум акча бүлеп бирә. Шуннан кала әле бер КамАЗ машинасы белән Муллашка Коръән китаплары, ислам дине йолаларына багышланган уку әсбаплары килә. Бу китапларны сатудан кергән акча мәчет төзелешенә тотыла. Шулай итеп бер ел эчендә мәчет салынап бетә һәм 1992 елның 17 нче июлендә мәчет ачу тантанасы үтә.

Авыл халкы яңа төзелгән мәчетнең имамы итеп, 1975 елда ук сайланган Нәҗметдинов Муса Исмәгыйль улын (1910–1999) билгели. Бу вазифаны ул 1999 елга кадәр башкара. Муса баба кечкенәдән үк ата-бабалардан калган

дини йолалар тәэсирендә тәрбияләнгән, иске татар язуын белгән һәм бер намазын, уразасын калдырмаган карт буларак авылдашларына үрнәк иде.

2000–2003 елларда мәчеткә имам итеп Ярмухаметов Зәкәрия баба сайлана. Ул да үзлегеннән дини белем ала, оста вәгазь сөйләүче була, яшьләргә дини тәрбия бирүдә актив эш алып бара. 2004–2014 елларда имамлык эшен Нурмухаметов Биктимер Нәҗметдин улы алып бара. Ул да үзлегеннән дини белем ала, тыныч холыклы, итәгатьле, яшь буынга һәрьяктан үрнәк дин әһеле була. Бүгенге көндә Биктимер бабаның эшен аның бертуган энесе Нурмухаметов Хәмзә Нәҗметдин улы башкара. Алар икесе дә муллалар нәселеннән, гаиләдә дини тәрбия алып үскәннәр. Хәмзә баба бүген авылның рухи тормышында иң актив эш алып баручы имам.

### *Мәктәп тарихыннан истәлекләр*

Бик борынгы заманнардан ук авыл халкы балаларын белемле, мәгърифәтле итүгә зур көч куя. Муллаш авылы мәчете каршында мәдрәсә булганлыгы билгеле, ләкин күп кенә шәкертләрнең заманасында дан тоткан Ямбай, Кыштунлы авыллары мәдрәсәләренә барып белем алулары да истәлекләрдә сакланып калган.

Совет мәктәбе (4 еллык башлангыч мәктәп) Муллашта 1924 елда ачыла, шул ук елны пионер оешмасы барлыкка килә. Беренче укытучылар – ирле-хатынлы Ибляминов Хәсән абый һәм Әминә апа. Мифтахов Чиәнкә Фәттах улы да сугышка кадәр Муллаш башлангыч мәктәбендә белем бирә. Хәсән һәм Чиәнкә абыйлар Бөек Ватан сугышына китеп, әйләнеп кайтмыйлар. Сугыш вакытында, сугыштан соңгы елларда балаларны озак вакыт Хисмәтуллина Майкамал Хәйрулла кызы укыта. Аңа иң авыр елларда эшләргә туры килә. 40 ел дәвамында бик күп балаларга белем һәм тәрбия биргән бу апаны авыл халкы онытмый. Мәктәп тарихында тирән эз калдырган укытучы ул. Бишенче класстан укучылар 25 чакрым ераклыкта урнашкан Кыштунлы жидееллык мәктәбендә интернатта торып укыйлар. Сугыш чоры елларында күп кенә балалар авыр тормыштан укуларын дәвам итә алмый. Муллаш авылында 1963 елда халык көче белән яңа мәктәп бинасы төзелә. Бу елларда дүртенче класстан соң балалар 20 чакрым ераклыктагы Шыкча авылының 8 еллык мәктәбендә (шулай ук интернатта торып) белем алалар.

1968 елда авылда сигезьеллык яңа мәктәп ачыла. Мәктәп төзүдә иң актив катнашкан авылдашлар Бабшанов Максуд, Хәлиуллин Камил, Камалов Тәкиулла, Зөлбухаров Хасим, Бабшанов Хачигирәй һ.б.

Сигезьеллык мәктәпнең беренче директоры – Фәйзуллин Әкрәм абый. Ул үзенә һәм башкаларга бик таләпчән, киң карашлы педагог, укыту-тәрбия эшен оста оештыручы кеше булган. Ул елларда мәктәп коллективы яңа эшкә килгән укытучылар белән тулылана: Фәйзуллина Фәүзия, Баши-

рова Рәбига, Хәлиуллина Әлфия, Нәҗметдинов Ильяс, Аскарова Фәрхия, Зөлбухарова Кәсирә, Газимова Әминә, Зиннәтуллина Фәнисә, Уразумбетова Зарифа белән Мәгъзия апалар мәктәп үсешенә зур өлеш керткән педагоглар. 1973 елдан директорлык вазифасын Нәҗметдинов Ильяс Йосып улы башкара һәм ул 2005 елга кадәр мәктәп белән җитәкчелек итә. 1983 елда сигезьеллык мәктәп урта мәктәп статусын ала. Ильяс Йосып улы эшләү дәверендә мәктәптә спортзал, музыка мәктәбе ачыла, укытучылар коллективы үсә, коллектив бердәм, үзара татулыкта, киңәшләшеп, ярдәмләшеп эшли. Шуның нәтиҗәсе буларак укучылар төпле белем алып, югары уку йортларына үз көчләре белән укырга керәләр.

1990 нче еллар ирегe милли мәктәпләргә дә яңа сулыш бирә. Мин, 40 елга якын татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак, татар теле укытуның дәрәҗәсе күтәрелүен аерым әйтеп китәсем килә. Бу елларда безгә, татар теле укытучыларына, бик уңай шартлар тудырылды. Берьяктан, Татарстандагы фәнни-мәдәни үсеш безнең эшкә дә уңай йогынты ясады, дәреслэр, укыту методикасы баеды. Икенче яктан, җирле хакимият тә яхшы шартлар тудырды. Муллаш мәктәбе дә, милли үсештәге мәктәп буларак, алдынгы мәктәпләрдән саналды. Шушы елларда без бик күп район, өлкә, ил күләмендә үткәрелгән чараларда катнаштык: милли темага багышланган ачык дәресләр, семинарлар, методик тәҗрибә уртаклашу утырышлары безнең мәктәптә дә үтте. Укучыларыбыз татар теленнән район, өлкә, ил күләмендә үткәрелгән олимпиадаларда призлы урыннар алып кайттылар. Мин, класстан тыш чара буларак, безнең өлкәдә беренчеләрдән этнопедагогикага нигезләнгән «Тормыш сабаклары» дигән дәресләр укыта башладым. Анда укучылар татар халкының гореф-гадәтләрен, мәдәниятын, җирле материалларга таянып, себер татарларына гына хас булган йолаларны үзләштерә иде. Әмма 2000 елларда татар телен укыту шартлары үзгәрә башлады, мәктәптә башка милләт балалары күбәю сәбәпле, татар теле дәресләре кыскара, өлкәдә милли темага багышланган чаралар сирәгәя барды.

2005–2015 елларда мәктәп директоры булып Нәҗметдинова Гөлчәрә Тәкиулла кызы эшли. Ул эшләгән елларда мәктәптә төрле милләт балалары белем ала. Укытучылар коллективы шушы мәктәпне тәмамлаган укытучылар белән байый, укучылар яңа уңышларга ирешә. Мәктәп районда алдынгылардан санала. Бүгенге көндә мәктәп директоры – Юсупова Рәмизә Мәксүт кызы. Мәктәптә барысы 153 укучы белем ала, шулардан 100 укучы – татар, 53е – башка милләт балалары.

### *Сугыш еллары*

Кечкенә генә Муллаш авылыннан Бөек Ватан сугышына 114 кеше китә. Аларның 58е яу кырында ятып кала, бары 56 ир-егет туган якка әйләнеп кайта. Сугыә чоры истәлеге булып, авыл уртасында батырлар-

га, тыл хезмәтчәннәренә багышланган һәйкәл тора. Без Дан орденының тулы кавалеры Якин Хабибулла Хәйрулла улы белән горурланабыз. Кайбер авылдашларыбызның әзтабарлар ярдәме белән каберләре табылды. Мәсәлән, Хәлиуллин Гафур Ростов өлкәсендә, Бабшанов Мәхмүт Кривой Рог шәһәрендә «Туганнар каберлегендә» җирләнгән. Ә сугыштан өенә кайтып үлгән Шамсутдинов Идрис бабаның батырлыгы турында мәгълүматлар яңа гына табылды. Идрис баба турында документларны аның кече улы Ризван Сәмигуллин җибәрде. Бик кызыклы бу документ авыл халкы өчен бу зур горурлык дип уйлыйм. Яшьләребез өчен, бүгенге катлаулы заманда, бу бигрәк тә чын батырлык үрнәге. Гади авыл егете сугышның башыннан ахырына кадәр зур батырлыклар күрсәтә. Аның батырлыклары турында улы архив документларыннан түбәндәге мәгълүматларны тапкан:

*«В 17 лет, 08 октября 1942 г. был призван в ряды Советской Армии Тюменским РВК Омской области...*

*...По прибытии на фронт был зачислен в разведроту полка. Ходили в тыл врага и производили диверсии. Перед наступлением полка, для полной информации дислокации противника, брали в плен «языка».*

*Неоднократно на своих плечах доставлял противника «языка» в КП.*

Послед заворачивали в чистую ткань и закапывали в землю, выбрав для этого место во дворе, где никто не ходит, или в подполье. В некоторых деревнях пуповину сохраняли в доме, чтобы она оберегала жизнь и здоровье ребёнка. Её заворачивали в ткань и хранили за матицей, в сундуке, под матрасом матери или подвязывали к люльке. Информанты отмечают, когда пуповину выбрасывали или теряли, ребёнок болел или

рано умирал. Обратите внимание, куда сейчас попадают пуповины и какое здоровье и продолжительность жизни у современных людей.



*Люлька.*

Первая еда, которую женщина принимала после родов, был майшырцай. Для приготовления этого жидкого супа кипятили воду со сливочным маслом, добавляли соль и немного муки. Его пили не только для бодрости, но и для того, чтобы у молодой мамы появилось молоко.

Добрую весть о рождении ребёнка разносили по деревне ребятишки. Такая традиция носит название «сөйөнцө». В ответ односельчане одаривали за весть монетами, конфетами или иными подарками [Баязитова: 2001. Б. 143].

Первые сорок дней женщину навещали родственницы и соседки, которые приносили с собой угощения и подарки для новорожденного – всё это приносило благодать (сауап). Первые распашонки стирали, гладили и откладывали в сундук для следующего ребёнка. По поверью, если семья соблюдала эту традицию, дети в семье были дружными.

Имянаречение (исем ататыу, исем ҡушыу) проводят в ближайшие дни после рождения до седьмых суток, или на 21-е сутки, если ребёнок слабый. Если проведение обряда имянаречения затягивается, ребёнок растёт неспокойным, т.к. в его поле появляются тёмные духи.

В этом обряде преимущественно участвуют близкие родственники, при этом малыша стараются не показывать. Отец или мулла читает азан и три раза произносит имя младенца в его правое ухо: «Синең исемең...» (Твоё имя ...) или «Перед Аллахом даю тебе имя…». Затем читается икамат и озвучивается имя в левое ухо. Далее проговаривают: «Твой Господь – Аллах, религия – ислам, книга – Коран, твой пророк – Мухамед». После этого следует праздничный обед с супом-лапшой и национальной выпечкой.

По шариату, при рождении девочки в жертву приносят одного барана, при рождении мальчика и близнецов – двух (если позволяет материальное благополучие). Стоит отметить, что по случаю рождения ребёнка, кости жертвенных животных не разрубают, а разъединяют в суставах.

При детской смертности проводили обряд продажи ребёнка и наречение вторым именем, таким образом, родители пытались запутать нечистую силу. Родители продавали ребёнка через окно, получали деньги, затем его приносили в дом через дверь и продавали родителям. Знаменитый поэт Пётр Ершов родился очень болезненным ребёнком, но пройдя обряд про-

дажи, его здоровье окрепло, и сегодня его знает вся страна. Существует мнение, что наш земляк был крещённым татарином, поэтому в его жизни и творчестве отражены история, культура и традиции сибирских татар.



*Колыбель.*

Люльку (цәңкелцәк, шәлтеп, шәлтөп, сәлтеп) изготавливали из можжевельника, сосны или берёзы. На деревянную раму средним размером 60 на 80(100) см. натягивали холст, прикрепляли к углам верёвки или кожаные ремешки, соединяли их и вешали на гвоздь, вбитый в матицу (арғалыҡ). Зыбка накрывалась лёгкой тканью от света, посторонних глаз и от кровососущих насекомых. Большинство колыбелей подвешивались к потолочной балке, однако встречались и напольные колыбели, один из таких экспонатов находится в сибирскотатарском этнографическом музее в с. Тукуз Вагайского района.



*Люлька.*

Матрасик для новорожденного иногда шили из старых штанин отца, чтобы ребёнок чувствовал его защиту и спал спокойно. Его наполняли семенами конского щавеля (сйыр ҡойроҡ), который хорошо впитывает влагу или осенним рогозом (ҡамыш). Также добавляли душистые травы: мяту (нәнә), душицу (йылыуыт) – для аромата и спокойного сна.

Отец или дедушка состригали первые волосы (ҡарын цацлар) до сорока дней или на сороковой день. Их старались сохранить рядом с пуповиной. Если первые волосы состригали позже сорокового дня, считалось, что ребёнок будет отставать в развитии или у него будет болеть голова.

На сороковой день проводился особый обряд – ҡырыҡлау/ҡырыҡ теләү/пала туй, на который приглашали родственников и повитуху. В этот день ребёнка впервые показывали посторонним людям, так как считалось, что к этому времени он уже окреп [История и культура: 2014. С. 364]. На этом обряде каждому раздавали мелкие калачики. С добрыми пожеланиями на голову ребёнку сыпали кедровые орехи и наливали

сорок ложек воды [Сибирскотатарско-русский словарь: 2019. С. 234]. В прежние времена в подарок гости приносили маленькие яркие подушечки – к̆алтацык̆. На них пришивали серебряные монеты или бумажные деньги и пуговицы с бусинками. Такими подушечками украшали люльки, и перед малышом всегда были яркие краски. Сегодня деньги кладут малышу под подушку или вручают родителям. Если гости желают, чтобы в их семье появился малыш, они дарят подарки со словами: «Пескә тә йолошсон/йок̆сон» («Пусть и нам перепадёт такое счастье»). Либо для этих же целей брали ребёнка на руки и ждали пока он помочится.

Когда ребёнок начинал ползать, его усаживали в долблёнку – түплинкә. Примерно в год некоторые матери уменьшали кормление грудью и переходили на кипячённое коровье молоко, которое давали с помощью соски – сымрак̆. Ф. Т. Валеев пишет: «Соску сибирские татары делали из коровьего вымени и коровьего рога. Коровье вымя в течение определенного времени держали в растворе соли, а затем натягивали сосок вымени на узкий конец подрезанного с обоих концов коровьего рога и завязывали суровой ниткой. Такие соски среди тарских татар сохранялись вплоть до конца 1920-х гг.» [Валеев: 1993. С. 146–147] Соску изготавливали также из марлевой ткани, в которую заворачивали хлеб с мёдом, с маслом или в сахарном сиропе.



*Тумары.*

Сегодня многие обряды и традиции связанные с рождением ребёнка, считаются устаревшими. Однако возрождается традиция домашних родов, изучена польза качания детей в подвесных люльках, доказано, что окуривание можжевельником убивает болезнетворные организмы в воздухе, постепенно возвращаются имена тюркского происхождения и т.п.

Рождение ребёнка – важное событие в жизни семьи и всего рода. Нежелание вступать в брак или рожать детей порицается в среде сибирских татар. Существуют наблюдения за теми, кто делал аборты, они часто не-

счастны, не доживают до старости или их дети умирают раньше своих родителей. Наш народ по-прежнему держится за традиции, молится за предков и за здоровье потомков во благо гармонии в роду и в обществе.

### Литература


1. Баязитова Ф.С. Себер татарлары. – Казан: Фикер, 2001. – 310 б.
2. Валеев Ф.Т. Сибирские татары: культура и быт. – Казань: Татарское кн. изд-во, 1993. – 208 с.
3. История и культура сибирских татар (с древнейших времён до начала XXI в.): Краеведческое пособие для студентов и учащихся старших классов общеобразовательных школ. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ; Изд-во «Артифакт», 2014. – 440 с. + 32 цв. вкл.
4. Марганова Ф.Ф. Колларым. – Тюмень: издательство ГАУК ТОНБ, 2017. – 275 с.
5. Сибирскотатарско-русский словарь (Себертатарца-урысца сүслек): около 30 000 слов / сост. Ф.Ф. Марганова. – Тюмень: 2019. – 470 с.
6. Татары. – М. Наука, 2001. – 583 с., ил.
7. Диянова А.М. Обереги в традиционной родильной обрядности сибирских татар // Омский научный вестник № 5, 2011 г.


**Информанты:**

*Абдуллина Манифа Фатыховна, 1953 г.р., уроженка с. Булашово Тобольского района, проживает в с. Сорокино Ярковского района.*

*Абайдуллина (Каричева) Галия Тухватулловна, 1940 г.р., уроженка д. Саусканы Тобольского района, проживает в Тобольске с 1990 г.*

*Алеева Роза Ахиевна, 1948 г.р., уроженка д. Сеиты Ярковского района, проживает в с. Сорокино Ярковского района.*

*Апсатарова (Кучебаева) Флора Азизовна, 1945 г.р., уроженка д. Байгара, проживает там же.*

*Багишева Халида Рифхатовна, 1958 г.р., уроженка д. Верхние-Бехтери Ярковского района, проживает в с. Сорокино Ярковского района.*

*Галиева Хариса Идиятулловна, 1961 г.р., уроженка д. Еманаул Ярковского района, проживает в с. Сорокино Ярковского района.*

*Дадашева Сатира Рахимчановна, 1955 г.р., уроженка д. Верхние-Бехтери Ярковского района, проживает в с. Сорокино Ярковского района.*

*Ибрагимова Марвар Тельмановна, 1966 г.р., уроженка д. Варвара Ярковского района, проживает в с  Сорокино Ярковского района.*

*Калиева (Губайдуллина) Гульнара Хамитовна, 1967 г.р., уроженка д. Чечкино Ярковского района, проживает в Тюмени.*

*Каримова Маулия Идиятулловна, 1954 г.р., уроженка д. Еманаул Ярковского района, проживает в с. Сорокино Ярковского района.*

*Кожевникова (Халитова) Зухра Ахметзяновна, 1947 г.р., уроженка д. Ревда Ялуторовского района, проживает в д. Петелина Ялуторовского района.*

*Колбаева Кульсиба Тусмухаметовна (1914–2010) уроженка д. Кошели Ялуторовского района, проживала в Тюмени.*

*Кульмаметева (Шарипова) Максута Шавалиевна, 1964 г.р., уроженка д. Тоболтура Тобольского района, проживает в с. Санниково Тобольского района.*

*Маметова (Мухамедьярова) Юлия Фаруковна, 1986 г.р., уроженка д. Уки, проживает в Тобольске.*

*Мачитов Октябрист Чаппарович, 1959 г.р., уроженец с. Казанское, проживает в Тобольске с 1980 г.*

*Мухамедьярова (Казакова) Муршита Ахматовна (1939–2020), уроженка д. Карбина, проживала в д. Уки с 1957 г.*

*Ниязова (Шарипова) Рамзия Шавалиевна, 1969 г.р., уроженка д. Тоболтура, проживает в Тобольске с 1986 г.*

*Речапова (Субханкулова) Роза Яруловна, 1935 г.р., уроженка с. Сафакулево Челябинской области, проживает в п. Прииртышском с 1972 г..*

*Русакова Самиха Сабирчановна, 1958 г.р., уроженка д. Верхние Бехтери, проживает в с. Сорокино Ярковского района.*

*Сайдуллина (Шарипова) Зульхайда, 1966 г.р., уроженка д. Малый Уват, проживает в с. Тукуз с 1995 г.*

*Сиаутдинова (Пурганова) Асия Салиховна, 1960 г.р., уроженка д. Ирек Тобольского района, проживает там же.*

*Тухватуллина (Аминова) Майра Сагдатдиновна, 1935 г.р., уроженка д. Катангуй, проживает там же.*

*Тухфатуллина Раиса Туктасыновна, 1961 г.р., уроженка д. Елань-Яр Вагайского района, проживает в Нижневартовске с 1999 г.*

*Хабибуллина (Рамазанова) Диля Загитовна 1960 г.р., уроженка д. Топкинская Тобольского района, проживает в п. Сетово Тобольского района с 1982 г.*

*Чумарова (Речапова) Фагиля Алимулловна, 1957 г.р., уроженка д. Черналы, проживает в Омске с 1974 г.*

*Шарипова (Бакиева) Мукарама Зайнулловна (1923–2012), уроженка д. Нижние Аремзяны, проживала в п. Надцы.*

*Шарипова (Тухватуллина) Люция Туктасыновна, 1963 г.р., уроженка д. Елань-Яр Вагайского района, проживает в Тобольске.*

*Янгулов Зуфар Камилович, 1974 г.р., уроженец д. Ачиры, проживает в Тобольске с 1983 г.*

# МИРАСЫБЫЗНЫҢ ТӨБӘК ТАРИХЫНА КАГЫЛЫШЛЫСЫ

# НАШЕ ИСТОРИКО-КРАЕВЕДЧЕСКОЕ НАСЛЕДИЕ

## СЕБЕР ТАТАРЛАРЫ ФОЛЬКЛОРЫННАН: ДАСТАННАР

### Ак Күбәк

*(дастан)*

Бер шәһәрдә Ал Бытык дигән би яшәгән, бу бидән бер угыл туган, аның атын Ак Күбәк дип атадылар, әнисенең карынында ук бала сөйләнеп яткан:

«Мин туармын, туармын,
Тугач, билем буармын,
Төнбоеклы тирән суда
Тулман буем йармын.
Мин туармын, туармын,
Бу дөньяны күрермен.
Көмеш шәкелле җиңгәмнең
Авызын-борынын үбәрмен».

Моны ишеткән кендек әбиләре качып киткәннәр. Бу бала туган. Туганнан соң, төнбоеклы тирән суга тулман буен юарга киткән. Суга төшкән. Атасының бер колы йылым тартып ята икән. Ятьмәсенә бер зур гына балык кергән булган. Яр буендагы кешеләр аны чыгара алмый яталар икән. Ак Күбәк, судан чыкканнан соң, күлмәк-ыштанын, башка киемнәрен киеп, атына менгән. Камчы сабына балыкны саңагыннан элеп, алып кайтып киткән. Әлеге балыкны өйгә китергән. Аны пешерергә кушкан, шушы балыкны бергәләп ашарга җәмәгатьне чакырырга дип, чыгып киткән.

Бара торгач, Кидән Ханны очраткан. Сәлам биргән. Тегесе сәламен алмаган. Бара торгач, Кидән Хан кабат икенче бер җирдә очраган. Ак Күбәк тагын сәлам биргән, Кидән Хан аның сәламен тагын алмаган. Аннан соң өченче җирдә очраган, Ак Күбәк сәлам биргән, хан тагын алмаган. Ак Күбәк ханга өч тапкыр сәлам биргән, тегесе бер тапкыр да сәламен алмаган. Ак Күбәк аннан сораган:

Атың кемдер?

Атым Кидән Хан булыр.

Ак Күбәк әйткән:

Кидән Хан дигәнче, Күтән Хан дисәңче.

Кидән Хан егеттән сораган:

Син кемсең?

Атым Күбәк.

Хан әйткән:

Сине нигә Ак Күбәк дип атаганнар, Сүбәк дип әйтсәләрче.

Аннан ары борылып кайтып киткән хан. Өендә Маңгыш исемле угылына әйткән:

Ал Бытык бидән бер угыл туган, аны кече чагында ук үтер!

Аннан соң Маңгыш Ак Күбәккә килгән.

Әйдә, алыш (дус), урманга сунарга бараек, – дигән.

Болар урманга сунарга киткәннәр. Урманда берничә көн йөргәннәр. Маңгыш моны көч белән үтерергә курыккан, берәр хәйлә табып үтермәкче булган. Маңгыш, бик ерактан уратып, сүз башлаган:

«Алыш булсаң, Ак Күбәк – ай,
Үр Колагың бир (этенең исеме), алыш – ай».

Ак Күбәк:

«Үр Колагымны бирәем – ай,
Бәһасын тапсаң, ал, алыш – ай».

Маңгыш янә әйткән:

«Алыш булсаң, Ак Күбәк – ай,
Этеңне бир миңа, алыш – ай».

Ак Күбәк:

«Этем йахшы, Маңгышым – ай,
Кыр урманга чапканда
Утыз биш төлке каптырган – ай,
Бәһасын тапсаң, ал, алыш».

Маңгыш: «Кыйбат», – дигән булып, берсен дә сатып алырга теләмәгән. Кайту юлында егетләр бер тау янында туктаганнар. Маңгыш әйткән:

Син инде бу йакка кит, мин ул йак буйлап китәем, бу җиргә кем элек җитсә, ул соңыннан килгән кешенең башын киссен.

Ак Күбәкнең апасы бар икән. Ак Күбәк аңа әйткән:

Бу җирдә кырык кызың белән мәҗлес җый.

Апасы килеп, кырык кыз белән мәҗлес корды. Маңгыш бу якка чыгып китте, Күбәк ул якка китте. Маңгыш килеп, Күбәк апасының мәҗлесенә юлыкты.

Маңгыш исерде, егылды. Ак Күбәк очрашырга тиеш булган җиргә житте, Маңгышны көтеп торды. Тегесе килмәде. Ак Күбәк аны эзләп китте. Килсә, Маңгыш кызлар янында исереп йоклап ята. Ак Күбәк шунда ук Маңгышның башын чабып атмакчы булды, әмма кылычы үтмәде. Маңгыш уянды, күзен бакты.

Син җиткәнсең, алыш! – диде, – инде вәгъдә – вәгъдә булсын! Башымны минем кылычым белән кис! Ак Күбәк Маңгышның кылычын кулына алып күтәрүгә, алдына Хозыр Ильяс килеп чыкты:

Кылычны күтәреп чапма! Үзеңнең башыңны кисәрсең. Кылычны җирдән сөйрәп барып кис башын!

Күбәк кылычны җирдән сөйрәп барырга булды. Шунда Маңгыш:

Тукта! – диде. – Башымны кискәннән соң, йөрәгемне йот! Пәһлеван булырсың. Карынымны кисеп, эчәгемне алып, билеңә бәйлә, аннан соң минем кылычым сиңа үтмәс булыр.

Инде Ак Күбәк, Маңгышның кылычын җирдән сөйрәп барып, башын кисеп атты. Йөрәген, йотарга дип, авызына китерде. Хозыр Ильяс әйтте:

Йотма! Дәрьяга ташла!

Күбәк Маңгышның йөрәген дәрьяга ташлады. Дәрьяның суы казандай кайный башлады. Ашказанын тишеп, эчәгесен алды, эчәген биленә чолгамакчы булган иде, Хозыр Ильяс тагын ярдәмгә килде:

Билеңә чолгама! – диде, – агачка чолга!

Ак Күбәк, Хозыр Ильяс кушканча, эшләде.

Агач, янып бетте. Күбәк өенә кайтты.

Илче Маңгышны Күбәк үтергән дип әйтергә Кидән Ханга килде. Аны ишетеп, Хан ачуына түзә алмыйча, Күбәккә китте. Кидән Ханны җиде кеше, җиде каен белән тәрәп, туктаттылар.

Барма, Кидән Хан, – диделәр, – бу пәһлеван сине дә үтерер. Угылың Маңгыш синнән дә пәһлеванрак иде, аны да үтерде. Сабыр кыл, син башта гаскәр җый! Гаскәр белән барырсың, – диделәр.

Кидән Хан бармады, гаскәр туплады. Гаскәр белән Ак Күбәккә китте. Күбәк бу хәбәрне ишетеп, тау башына тимер өй салды. Кидән Ханның гаскәре шул тауның итәгендә саклап ятты. Күбәк илче чакырды. Илчедән сорады:

«Нинди-нинди пәһлеваннар бар? – ай,
Аны әйт, Чылажым – ай:
Салыр Казан – ул да бар ай,
Буйдар Алып – ул да бар ай».

Ак Күбәк үз ягында бик күп алыплар-пәһлеваннарның булганын белде. Аннан соң атына атланды, кылычын югары күтәреп, чирүгә (гаскәр эченә) кереп, дошманны кырып бетерде. Аннан соң Кидән Хан белән очрашты. Күбәк сөңгесе белән ташланды, аңа җитмәде. Кидән Хан сөңгесе белән Күбәкне югарыга күтәрде. Сөңгенең сабы буйлап Күбәкнең каны акты.

Кидән Хан әйтте:

Минем угылым Маңгышның каны эчендә сиңа яхшымы иде? Бүген синең дә каның эчәр көн бар икән.

Күбәк әйтте:

Син минем канымны эчеп торам дисеңме? Мин синең авызыңа канымны түгел, ... агызып торам.

Кидән Хан сөңгесен читкә ыргытты.

Күбәк, атына атланып, кайтып китте. Кидән дә өенә юл тотты. Күбәк әйтте:

Тагы бер атнадан гаскәрләребез белән очрашырбыз!

Сөйләп бетергәсез зур орышлардан (сугышлардан) гаҗиз булган Ак Күбәк агасына кайтты.

Агам, – диде, – инде мине җиргә күм.

Агасы аны аты белән җиргә күмде.

Күбәк әйтте:

Бер җомга буе мине тынычлыкта калдыр! Дошман гаскәре килгәндә генә миңа килә аласың, – диде.

Өч көн булдымы, булмадымы, агасының хатыннары арасында җәнҗал чыкты. Аларны аерырга агасының көче җитмәде. Агасы Күбәкнең каберенә килде.

Тор, Күбәк, яу килде! – дип кычкырды.

Ак Күбәк аты белән күмгән җиреннән торып басты. Як-ягына каранды: яу юк!

Агасы әйтте:

Ике бичәм сугыштылар, мин аера алмадым. Ярдәмгә сиңа килдем.

Инде мин чынлап та үлдем. Беркайчан да үлгән кеше кабаттан терелмәсен! Мине яңадан күм!

Егылды Ак Күбәк. Ак Күбәкне яңадан каберенә куйдылар. Бер җомгадан соң әлеге яу чынлап та килде. Агасы, Күбәкнең гүренә йөгереп килеп, чаң сукты: «Тор! Яу килде!» Күбәк, азапланып-азапланып булса да кабереннән чыгарга теләде. Чыга алмады. Агасы, Күбәкнең атына менеп, яуга китте. Ике агачны тамыры белән кубарып, сөйрәп яуның эченә ташланды. Яу да ул якка, бу якка чапты... Бу орышта бик күп алыплар-пәһлеваннар шәһит булдылар.

Кидән Хан әйтте:

Килешәек! Синдә минем яманлыгым юк.

Аннан соң ярaштылар, килештеләр, бер-берләренә яманлык ясауларын туктаттылар.

*Текстны, бераз кыскартып, әдәби телгә Ф. Йосыпов күчерде.*

*Ф.Ю. Юсупов. Сибирские татары. Из сокровищницы духовной культуры. Дастаны. Мунаджаты. Баиты. Казань: Казанский университет, 2014. С. 143–224*

*Алынды: Түгәрәк уен. № 3, 2020. 50–51 бб.*

## Кузы Курпы мэн Паян-Сылу

*(дастан)*

Ике кан пулган. Персе аның Ак кан, персе Кара кан пулган. Пыларның катынлары корсаклы пулганнар. Ак кан пелән Кара кан үсара сыргалаштылар: синең улың пулса, минең кысым пулса, коталашабыс тиләр, сүз куйдылар.

Көннәрдән бер көнне пы ике кан ахутага цыгып киттеләр. Ахутага киткәндә пылар әйттеләр усләренең цәмагәтләренә: «Без осак калып, пала тапсагыз, пескә сөенцегә пер үвәсирне ебәрең», типтеләр. Пылар ахутада бик осак йөрептеләр. Пылар кайтканцы цәмәгәтләре пала таптылар. Пер увәсирне сөенцегә ебәрделәр. Үвәсир пы ике канга парып әйтте: «Цәмәгәтләрегес ир пала пелән кыс пала тапты тип. Ну пылар сөенәләр, сөенешеп тиз кенә атка менеп цабалар. Аңа-моңа карамай цабып парганта Кара кан егыла атыннан. Атыннан егылып төшеп Кара канның аягы сынды. Осак ятматы Кара кан, өйелде. Өйелгән суң Кара канны күмтеләр. Кара кан кайтмый калды шул өйелгән ерендә.

Кара канның катыны ятим калып паласын көйтәреп парды Ак канга. Акканның курасына керде. Яй көне булган игән. Ак канның ялцылары эрегән сөт алып цыгып тәпшегә[1] коялар, канның эт балаларын туйдырыр өцен. Канның көцекләре тәпше янына килеп эрегән сөтне эцә башлатылар. Шул уакытта Кара канның катыны үсенең паласын ергә ебәргән игән. Кара канның паласы елышып парып әлеге тәпшедәге эрегән сөтне кулы пелән алып ашай башлайты, көцекләр пелән пергә.

Кара кан паласының этләр мән ашауын Ак канның катыны карап торыпты. «Әй, тите, пы Кара канның паласы эт пелән пергә ашай», тигән, «Пы якшы кеше пулмас, моңа кызны бирмәү гәрәк», типте. Аннан суң Ак канның катыны үсенең күргәннәрен Ак канга әйтепте: «Мин шантай-шантай кәл күрдем» дип. «Кысыбызны эт палалары пелән бергә ашаган кешегә бирмәек, пы Кузы Көрпә монда калсын, пес башка шәһәргә, башка ергә күцеп китәек, Кузы Көрпе монда калсын» тип әйтепте Ак канның цәмәгәте. «Пы пала монда калсын, үссә, берәр йиңгә алыр үсенә» типте.

Ак каннар пы ерләртән күцеп китепте, Кузы Көрпәләрне калдырып.

Кузы Курпы 7–8 яшьләргә етепте. Урамта яшь малайлар мән уйнап йөри пашлайты. Пы Кузы Көрпә яшьтән ук бик көцле, пәлван пулган игән тите. Малайлар мән уйнаган цакта пы ике малайның кулын цыгарыпты, тагын пер малайның кулын-аягын цыгарыпты. Яман көцле игән пы Кузы Көрпә. Кешеләр пы Кузы Көрпәне орыша башлайтылар.

---

[1] Тәпше – агач савыт.

Көннәрдән пер көнне малайлар мән уйнап йөргәнгә пы Кузы Көрпә янә пер баланың кулын цыгарыпты. Пы бала елай-сыктай Кузы Көрпәне орыша-сүгә башлапты: «Син, типте, көцеңә таянып, көцең мән мактанып, юкка куатланып йөргәнце, үсеңне ташлап киткән катыныңны парып алыр итең» типте.

Кузы Көрпә пы сүсне эшеткәц, күңелсесләнеп, елткәсен тәбән салып[1] өенә кайтып китепте. Юлда кайтып парганда «Минем катыным пулган микәнни» тәп уйлап кайтыпты пы.

Өенә кайтып парганта Кузы Көрпәгә оцырапты, ти, пер корткаяк. Пы корткаяк Кузы Көрпәнең елткәсен тәбән салып кайтып килүен күреп моннан сорапты: «Ник пылай башыңны тәбән салып кайтып киләсең?» тәп. Кузы Көрпә моңа: «Мәнем катыным пултымени?» типде.

Корткаяк әйтепте пы палага: «Сәнең катының Ак канның кысы Паян-Сылу, – типте. Ак канның кысы Паян-Сылу мән сәне сыргалаштырганнар әте, – типте. – Ак канның кысы Паян-Сылуны[2] сәңа бирмәен кацырып алып кәтте, – типте[3] – Син мыны өеңә кайтып инәңнән сура, инәң сөйләр, сөйләмәсә син аны кәйләмән сөйләт, көцләп сөйләт, – тиде. Син өеңә кайт та «Инәм, син миңә кавыргыц[4] куырып бир, минем куырган кауыргыц ашагым киләте, – тиген. Инәң сиңә кауыргыцны куырып бирер. Куырылган эссе кауыргацны ул сәңа кугац[5] мән сосып пирер. Син әйт: «Инәм, син мәңа куыргацны кугац мән сосып бирмә, кулың пылән алып пир, тип әйт. Ул сәңа куыргаңны кулымән сосып алып бирер. Куыргацны кулына алу мән син аның кулын кысып ошла, аннан суң «минем катыным пулдыма, ницек булды теп сора. Кулы пешкәнгә цытай алмай ул сәңа сүләп бирер» тигән. Шулай тигән тә корткаяк атлап киткән.

Кузы Көрпә өенә кайтып инәсенә:

– Миңә куыргац куырып пир, минең куыргац ашагым киләте,– типте. Инәсе куыргац куырып биреп, куыргацны кугац менән салып пирепте. Шуннан Кузы Көрпә әйтепте: «Инәм син мәңа куыргацны кугацка салып бирмә, кугацка салып бирсәң мәнем юлым кыйгац пулыр, син аны мәңа кулыңмын алып бир, – типте. Инәсе куыргацны кулына алу мән Кузы Көрпә алың кулын кысып ошлапты. «Я, инәм, син миңа әйтеп, сөйләп бир, минем катыным кем пулацак ите, – типте.

Кузы Көрпә инәсенең кулын ебәрмәй пылца тотыпты, ошлапты. Кузы Көрпәнең инәсе алай порылыпты, пылай порылыпты, сөйләмәс итә дә кауыргаң эссе пулгац кулы пеште, сөйләмәй пулмайты. Шаннан суң Кузы

---

[1] Елткәсен тәбән салып – җилкәсен түбән салып, кайгырып.

[2] Кайбер урында бабай «Баянсылу» дип тә әйтә. – Х.Ярми.

[3] Кайбер урында «типте», «тите» ди, ә кайбер урында «тете» дип тә җибәрә бабай. –Х. Ярми.

[4] Кауыргыц – куырылган арпа.

[5] Кугац – туздан тегеп ясалган, чүмеч кебек әйбер.

Курпәнең инәсе әйтеп пирте моңа пулган кәлләрне парсын та. Парсын та сөйләп пөтергәц Кузы Күрпә инәсенең кулын ебәрте, пушатты инте моның кулын. Инәсе әйтте:

– Я, палам, инде куйматың, сөйләп бир титең, менә мин сәңа пулганын сөйләп, әйтеп бирдем, тиде. Тик син инте, палам, алар янына парасы пулма, анта барсаң, алар сәне үлтереп куярлар, – тиде. Алар сәне яратмадылар, тиде, атаң кан исән пулмагац, – тите. Инәсе янә әйтте Кузы Көрпәгә: Улым, тиде, аның юлы та бик авыр, асаплы юл пулыр ул, тиде. Аның юлынта алты ай туңмас тәрья бар, тие, ул тәрьяны уткәц цыцкан үтмәс орман пар, ти. Тәрьяга еткәц, тәрья алдында алты ай ятарсын, аны ницек үтәрсең, – тиде. Аннан Кузының инәсе пыларның барын сарын пелән әйтеп пирде[1]. Кузы Көрпә торып әйтте: «Мин, – тиде, – алты ай туңмаган тәрьяны алты көндә туңдырып кицәрмен, – тиде.

Инәсе янә сарынмән әйтте, Кузы Көрпәне ебәрмәскә теләп.

Кузы Көрпә: «Юлга цыгам, кысны эстәп китәм» дигәч, инәсе янә әйтте сарын белән. «Әнә атаңнан калган цыбыртккы, аннан калган кылыц пар, юлга цыгар булсаң, аларны ал, – тиде. Ул цыбырткы мән барсаң, тәрья алдына еткәц сарын әйтеп шул цыбырткы мән суксаң, алты ел туңмаган тәрья алты көндә туңар, кылыц мән цыцкан утмәс цытырманны кисеп цыгарсың юл ясап. Аннан сауыскан үтмәс кара цүлгә чыгарсың, кара цулне уйтәрсең, кара цулне уйтәц, Ак канның пәстүгенә оцырарсың. Ул пәстук барырсың, улым, – тиде. Ол пәстүк сәңа юлын курсәтер кайдан парырга тиде.

Ну, пы Кузы Көрпә юлга кәзерләнә. Атасыннан калган цыбырткыны, кылыцны алды. Юлга цыгып сур тәрьяны, цыцкан үтмәс кара орманны ярып үтте. Барып, барып елгы пәстугенә барып етте. Елгы пәстугенә бара, керешә моның пылан исәнлек сорап. Елгы пәстуге кунак итә моны: өц ел колынламаган бер ту бияне суеп ашатты моңа, Кузы Көрпәгә.

Аннан пы пәстук әйтте:

– Менә пы юл пылап барырсың, сыер пәстугенә, – ди. А-а-а-на алыста тугел сыер пәстуге булыр, – ди, пес пер-перепестән алыс түгел, – ди.

Кузы Көрпә бара-бара сыер пәстугенә барып етте. Сәләм бирешеп исәнләштеләр, сөйләштеләр. Сыер пәстуге янә моңа өц ел пысауламаган пер сыерны суеп, Кузыны кунак итте. Аннан соң ул Кузыны куй пәстугенә ебәрде.

Кузы куй пәстуге янына барып етте, исәнләштеләр, сөйләштеләр. Ул янә пер симес куй суеп Кузы Көрпәне кунак итте, ашатты.

Кузы Көрпә моннан сураша: «Инте, ди, ницек итеп Паян-сылуны табарга, ди, Паян-сылу кайта булыр, ди, аны ницек итеп табарга, – тәте.

---

[1] Сарынын (дастанның көйле шингъри өлешен) оныттым ди Хәсән бабай, исенә төшерә алмады. – Х. Ярми.

Пәстүк әйтте: «Пылай барсаң, сәне үтерерләр, тәте, сән мәнем кие-менме ки, үс киемеңне мәңа калтыр тәде.

Аннан юлны өйрәтте: «Ә-әнә, тәте, куйларны елгага цаклы аппарырсың, елгага еткәц куйларга:

Кицерел, куем, кицерел, куем,

Кицередмәсәң, тора кал, куем, – тәп әйтерсен тәте.

Кузы Көрпә куйларны елгага цаклы алып барып еткәц, ни тип сарын әйтергә онытып ебәрде. Шул арада Паян-Сылу килеп цыгып: «Син көндә әйтеп йөргән сүсеңне онытасың. Кицерел, куем, кицерел, куем, кицерелмәсәң, тора кал, куем!» тип кыцкырсаң, алар цыга бирәте, тәте. Кузы Көрпә куйларга «Кицерел, куем, кицерел, куем! – тәп кыцкырды. Куйлар елганы кицеп цыгып китте.

Шаннан суң пәстүк аңа өйрәткән инте: – Менә минем ята торган испушкәм пулыр, тигән, шунда кереп ятарсың, тигән. Аннан әйткән: «Аш-суны Паян-Сылуның кысмәткәрләре пешереп куярлар, тигән, аны пәлән кумнатка парып ашарсың, цай эчәрсең», – тәгән.

Ярар, пы Кузы Көрпә кайтты Паян-Сылу янына. Аш кумнатларына керде. Цай эцкале утырган суң Паян-Сылу мыны ошатты үсенең элеккե егетенә. Утыралар. Кыс күңелсез, еңәләремән сыер саварга цыкматы, пәстүк янында осагырак калты пы. Еңәсе дә сирәк кеше пулган. «Нишләп осак цыкмый тордың?» тип сорады Паян-Сылудан. «Әнә, ти, Паян-Сылу әйтә, пы пәстүк порын күтәреп песнең цайны яратмайты, аның янынта осагырак пулдым», – тиде. Паян-Сылу пылан Кузы Көрпә шал еңкәләре цыгып киткән арада кәпләшеп алтылар.

Аннан киц пола. Пылар киц тә оцырашып сөйләштеләр, таныштылар.

Паян-Сылу шал төнне осагырак йоклап кала, иртәмән сыер сауарга цыкмай калаты. Иртә пылан кинәт ижеген төбертәтә еңәсе сарын әйтеп:

Торсана, Паян-Сылу,
Торсана, тышта коцкацаклар
сайрашаты.

Паян-Сылу цавап бирде:

Ац пүреләргә ем булсын
Коцкацакларың, ти.
Ац пүреләргә ем булсын,
Куйларың, ти[1].

Аннан соң еңәләре кәбәр итәләр Паян-Сылуның аталарына, инәләренә. Алар та пы эшне пеләтеләр, сизәтеләр. Инәләре Паян-Сылуга әйтәделәр: «Пы Кузы Көрпәдән матур егет әллә илтә юкмы, илгә цыксак, илгә цыксак антайны кырыкны табарбыз», – ти. (Инәсе сарын әйтә, мин оныттым, ди бабай).

---

1 Аннан тагы сарыннары пар иде, онытылган, ди бабай – Х. Ярми.

Паян-Сылу: «Миңа Кузы Көрпәдән пүтән кеше кәрәкмәйте», – тип әйтепте. Аннан соң пылар Паян-Сылуны алдап:

– Ярар, Сине Кузы Көрпәгә бирәбез, тип әйтептеләр, алтаптыдар Паян-Сылуны. Узара Кузы Көрпәне үлтергәле тип киңәш итептеләр. Пылар усара кәпләшеп арцан-курцанны әзерләп куептылар. Шаннан пер увәсирне Кузы Көрпәне кунакка цакыргалы ебәрептеләр. Паян-Сылу пыларның ни өцен цакырткаларын пелеп әйтепте Кузы Көрпәгә:

– Парсаң, сакланып эц, кән эцмә, исермә! – тип.

Беренце цакыруда Кузы Көрпә бармайты. Үвәсир кайтып әйтте: «Кузы Көрпә килмәйте», – тип. Кан тагы кайта, ебәрте ике үвәсирне. Кузы Көрпә алар цакыруына та парматы. Үвәсирләр кайтып әйттеләр. Өценце рәт кан ебәрте өц үвәсирен. Өц үвәзир цакыра килгәц Паян-Сылу: «Инте пар, тите, ебәрте Кузы Көрпәне. Юлга цыкканта: әйтте Паян-Сылу: «Пар, тиде, саклан, кән эцмә, исермә»,– тиде.

Кузы Көрпә барты кунакка, әцеп исереп китте, арцан-корцан исертте мыны.

Канның караулцылары арасында Паян-Сылуның тус кыслары пулаты. Алар Паян-Сылуга кәбәр иттеләр: «Кузы Көрпәне алдатылар, изерттеләр», – тип.

Паян-Сылу аталарына килде, Кузы Көрпәне өйзенең пүлмәсенә алып цыгып китте. Паян-Сылу Кузы Көрпәгә әйтте: «Ник эцтең, ник аларның сөйзен тыңладың?» – тип. Моңа Кузы Көрпә әйтте: «Иртән, ти, син мине озат, ти, мин кайтам өйз өемә», – тиде. Паян-Сылу әйтте: «Мин синнән калмаем, мин синең мән китәм», – тиде. Кузы Көрпә: «Син кәзергә кал, мин сине алгалы яңатан килерем, – тиде, – мин сине күцереп китәрмен», – тиде.

Иртән торып Кузы Көрпә атына атланып китә, Паян-Сылу мыны осатып калды.

Пер авылга парып етәте Кузы Көрпә. Шал ауылның цитендә пер күпер пулган игән. Кузы Көрпә күпергә килеп етү мән күпер астыннан пер кеше килеп цыкты. Пы кеше әйткән Кузы Көрпәгә: «Син миңа езнә юлы[1] пир», – тигән. Кузы Көрпә моңа езнә юлы пирмәгәц, кеше әйткән: «Әгәр син езнә юлы бирмәсәң, бер тумыгыңны ацып куй, мин шаңа атаем типте». Кузы Көрпә пы кешенең огы әлләни ауыртмас тип уйлап: «Мә, типте, атып пак, типте, тумыгын ацып куепты». Әлеге кеше укмән атып мының тумыгын ярты. Кузы Көрпә баягы кешене камцысымән сугып екты, ярты: «Атам та ауырттырганы юк, инәм та ауырттырганы юк, син мине яралатың», – тиде, әлеге кешене тагы ярты камчысымен.

1 Езнә юлы – җизни бүләге.

Инте китте Кузы Көрпә. Пара-пара моның аяк шешше. Паралматы, атыннан төште. Пер пайтирәк пар ите, Кузы Көрпә шал пайтирәк төбенә килеп ятты.

Кузы Көрпәдән кәбәр килмәгәц, Паян-Сылу мыңа кацкацакны ебәргәле пулты. Ебәрте кацкацакны: «Пелеп кил, теремә, үлеме Кузы Көрпә, шаны пелеп кил», – тип. Кацкацак китте. Кацкацак пик күп ерләр, пик күп цүлләр үтеп парып етте пайтирәк янына. Караты, Кузы Көрпә үләр тәрәцәгә йеткән. Кацкацак мыны пелеп, оцып кайтып китте.

Пы кацкацак оцып кәбәр алып кайтып йеткән вагытта Баян-Сылуның инәсе аның пажын карап ята тигән. Паян-Сылу инәсе алдында ятып йоклап китепте. Шал арада мының йоклап китүеннән пайталанып еңәсе кацкацакные тотып алып, аннан сорапты: «Үлеме, тереме?» – тип. Кацкацак мыңа пер сүс әйтмәйте. Шаннан йеңәсе пы кацкацакның йөнен йолгып алыпты, «әйт!» тип. Кацкацак пыларга сүс әйтмәде. Кәбәрен әйтмәгәц, кацкацакны үтергәле пултышар, аны утка салтылар. Утка салгац кына кацкацак әйтте: «Кузы Күрпә палән цүлтә, пәлән-пәлән пайтирәкнең төбендә ятаты, аның кале петкән», – тип. Пы сүзне Паян-Сылу ишетерлек итеп кыцкырып әйтте, Паян-Сылуның колагына әйтте.

Паян-Сылу пы кәбәрне эшетеп бик кайгырды, пы өйтән ницек цыгып китү юлын эстәй башлаты.

Инәсенә әйтте: «Мин кысларым пылан сәелгә цыгам», – тиде. Энце, якут, мәрцәннәрен алып, кырык кысны ияртеп цыгып китте. Юлта парганда Паян-Сылу энце, мәрцәннәрне ергә цацып ебәрә, кыслар моңа алтанып, энце, мәрцәннәрне цүпләп калатылар. Паян-Сылу пылартан кацып китә. Пылар куып килеп етү пылан тагы энце, мәрцәннәр, якутларын цацып ебәрәте. Кыслар тагы аны еып калатылар. Паян-Сылу Кузы Көрпәне эстәп пара бирде. Пара-пара пы әлеге цүлгә парып етте. Анда пайтирәкне тапты, пайтирәк янында Кузы Көрпә үлеп ята тигән. Аннан Паян-Сылу әйтте: «Кайтсам, мине парыбер пүтән перәүгә бирерләр, мин кайтмаен, мин мынта үләен», – тиде. Паян-Сылу: «Үлсәк, пергә үләек», – тип пыцагын күкрәгенә катап, Кузы Көрпәне коцаклап өйлә.

Пылар икесе тә өйелгәннәр инте.

Паян-Сылуның пайтирәк янына китүен пер кыс пелгән. Пы кыс мының үлүен инәләренә кәбәр итте.

Моның артыннан киткәннәр куып, Ак кан үсе тә вәсирләр мән пергә куып килә, кысын эстәп. Куып килеп етсәләр, пылар икесе дә коцаклашып өйлгәннәр. Ак кан әйтте: «Пыларның икесен пергә күммәйпес, ти, персе елганың пы ягына, персе менә пы ягына күмелсен», – ти.

Күмәләр – персен елганың пер ягына, ә персен ричканың икенце ягына.

Ну инте Ак канның кияүе пулган игән, әлеге Кузы Көрпәнең тумыгын атып ярган пер сәүтәгәр. Ул үлгән кайгырып. Ак кан әйткән: «Паян-Сылуның яраткан кияүе менә пы кеше ите, – тигән, – аны Паян-Сылуның янына күмегес», – тигән. Күмгәннәр.

Пылар күмелгәц әлеге пайтирәк Кузы Көрпәнең дә, Паян-Сылуның та кәбере өстенә өйсеп цыккан. Сатуцының кәбере өстенә пер тал өйсеп цыккан. Паян-Сылу мән Кузы Көрпә кәберләре өстенә өйсеп цыккан пайтирәкләр пер-персенә якын килеп, ишелеп өйскәннәр. Сәүтәгәр кәбере өстенә цыккан тал өйсенә-өйсеп, сушыннан тыршаеп корып калган.

Паян-Сылу мән Кузы Көрпә пер пересен яратканнар, ә сатуцыны Паян-Сылу яратмаган, аңа кысны көцләп пирмәк пулган Ак кан.

Бу дастанны 1940 елның 22–23 нче маенда Новосибирск өлкәсе, Каргат районы, Муса авылы Советы, Тәрәнә авылында (Яйләү авыл – Җәйләү сүзеннән, аларда бу тирәдә Кышлау авылы да бар. Димәк җәй көннәрен Җәйләүдә, кыш көннәрен Кышлауда торганнар) Хәсән бабай Кәримовтан язып алдым. Ул 1863 елда туган, аңа хәзер 77 яшь.

Тәрәнә авылында хәзер колхоз бар, аның исеме «Ирек». Хәсән бабайны төп себер кешесе дип әйтергә була. Аның этисе монда, Себердә, туган, үзе дә монда туган. Ә бабасы элекке Казан губернасының Тәтеш ягыннан килгән имеш. «Безнең бабайлар солдат бирмәс өчен, Бараба татарлары исеменә язылып, торыр өчен монда килгәннәр», – ди ул. Хәсән бабай үзе дә Бараба кызына өйләнгән. Колхозда 1930 елдан.

Бу дастанны ул яшьрәк чакта шушы авылда ишеткән булган. Ул аны бик җиңел сөйләде. Сүзгә оста карт. Бер язып чыктым, аннан яңадан сөйләтеп, төзәтеп язып чыктым. Бабай сүзләрне нигездә бараба татарлары шивәсендә сөйли. Ләкин кайбер сүзләрне төрлечә әйтә, искечә грамоталы, ул үзе китаплар да, гарәп хәрефләре белән, укыган булса кирәк. Үзе: «Мин грамотасыз», – ди.

Мин Хәсән бабайдан бараба татарлары шивәсендә булган кайбер сүзләрне язып алдым. Бараба татарлары да «ц» белән сөйлиләр, аларда «ч» юк диярлек.

*Шәбалә – кашык /төмән татарларында шабала/.*
*Цацнау – чүмеч /төмән – цүмец/.*
*Табак – тарелка /төмән – тәрилкә/.*
*Латка – чугун /төмән – цуйгун/.*
*Цыны – чынаяк /төмән – цынаяк/.*
*Тумөк – тубык /төмән – тубык/.*
*Кос – күмер /янган/ /төмән – кус/.*

*Сампар – самовар /төмән – самавар/.*
*Корас – әтәч /төмән – курас/.*
*Көркә – күркә /төмән – күркә/.*
*Кармакцай – сыерчык /төмән – бакцар/.*
*Мунцак – бусы (мәрҗән – ред.) /төмәң – мун/й/цак/.*
*Пыцак – пычак /төмән – пыцак/.*
*Күнәк – чиләк /төмән – циләк/.*
*Кацау – өтерге /төмән – кацау/.*
*Колца – кыр суганы /төмән – юуа/.*
*Пыяс – суган /төмән – пыяс/.*
*Йомак – әкият /төмән – йомак/.*

Моннан башка мин бараба татарларының сөйләшү вакытларында кулланыла торган шивәләрен язып алдым. Алар арасында шундый сүзләр һәм җөмләләр бар:

*Ога калган всятакай /шулай да отып, аңлап алган.*
*Өйзеңнеңке нождаң өйзеңкә йеткән / үз нужаң үзеңә җиткән.*
*Ул нимәне пелсен /ул нәрсә белсен.*
*Нәцем карт пар итте, алар пулса пелер итте/ Нәҗми карт бар иде, ул белер иде.*
*Картлар өйлеп пөткән /картлар үлеп беткән.*
*Кәрим тәган карт полган /Кәрим дигән карт булган.*
*Кызын какырып тәте /кызын качырып диде.*
*Пер цөлгә цыккан /бер чүлгә чыккан.*
*Өйлцәп цыккалы тәте /үлчәп чыгарга ди.*
*Одырылап цыга /каршы чыга.*
*Өйзенеке /үзенең.*
*Сарнаган /җырлаган, көйләгән.*
*Ницә сәгатьтә килгәле, минем сәгать юк/ничә сәгатьтә килергә, минем сәгать юк.*
*Мәгаләй /бияләй.*
*Нимәсе цыксын /нәрсәсе чыксын.*

Бу сүзләр Хәсән бабайдан һәм башка иптәшләрдән язылды.

1940 ел, 22 май, Яйләү-Тәрәнә авылы.

1870 нче елларда шушы Тәрәнә авылында В.В. Радлов булып киткән. Авылда күп кенә карт кешеләр бар, дигәч, мин бу авылның иң карт кешеләрен җыйнап, Радлов турында сораштым. Чөнки мине Радловның нинди кеше булуы, бу ерак Себердәге татар авылларында аның ничек эшләп йөрүләре, халык иҗатын ничек һәм кемнәрдән язып алулары бик нык кызыксындыра. Минем уемча, Радлов бу авылларда бик аз тукталып үтеп китүенә карамастан, ул халыкның тел үзенчәлеген бик яхшы тотып

ала белгән һәм әкият дастаннарны халыкның үз телендә, үз шивәсендә бик матур итеп язып алган. Аның /В.В. Радловның/ әйтүенә караганда, дин әһелләре аны фольклор язып йөрүенә бик нык каршылык күрсәткәннәр, ләкин ул, шулай булуга карамастан, күп эш эшли алган.

Минем үтенүем буенча җыелышка,чакырган җиргә, түбәндәге картлар килде:

Хәсән карт Кәримов – 77 яшь

Фазулла карт – 85 яшь

Габдулла карт – 90 яшь.

Габбас карт – 92 яшь.

Гыймран карт – 70яшь.

Бу картлар белән бик озак сөйләшеп, гәпләшеп утырдым. Мин аларга Казан хәлләрен сөйләдем, ә үзем шушы ерак Себер җирләрендәге борынгы тормыш хәлләрен тыңлап, мәс килеп утырдым. Кайбер материалларын язып алдым. Картлардан бары 92 яшендәге Габбас карт кына В.В. Радлов килүен хәтерли. «Мин яшь идем. Безнең авылга озын гына, башына кара эшләпә кигән бер кеше килгән иде. Ул картларны чакырып сөйләшкәнен хәтерлим. Ни язгандыр, ни сорагандыр, анысы белән мин кызыксынмадым. Ул вакытта без бер нәрсә белән кызыксынмадык. Аның янында бер яшь кеше дә бар иде сыман. Алар бездә берничә көн торып киттеләр», – ди. /В.В. Радловның архивын, көндәлекләрен табасы иде, анда сәяхәте турында бардыр дип уйлыйм/.

*Язып алучы, комментарийлар авторы*
*Хәмит Ярми (Ярмөхәммәтов),*
*1940 ел, 22–23 май, Тәрәнә авылы.*

# СЕБЕР ТАТАРЛАРЫ ФОЛЬКЛОРЫННАН[1]: СӨЙЛӘКЛӘР



*Рауза Яхина с информантами.*

Журналыбызның бу номерыннан башлап, без себер татарлары фольклоры буенча булган материалларны бастыра башлыйбыз. Гөлфизәр апа Абдрахманова кулъязмалары безгә Рауза апа Яхина тарафыннан җиткерелде. Китерелгән әсәрләр фольклористлар классификациясе буенча «сөйләкләр» жанрына карый һәм Төмән өлкәсе Вагай районының Ешаир авылында язып алынганнар. Алар татар әдәби телендә һәм җирле себер татарларының диалекталь телләрендә ничек язып алынган, шул килеш биреләләр.

## Еш-кыс ataштырты

Пы кәл пулты, мең тугыс йөс алтмышынцы йылны сентябрь айынта. Шул уакытны минең йәш уакытларым ите. Йәшлек исәрлек тип тикмәгә әйтмәгән пулыр поронколар.

Пергөннө цыктык торнагүс йыйгалы «Уба паш» пуйлап саска «Кара утрау» – тигән йергә.

---

[1] Текстлар күбесенчә җирле сөйләмдә биреләләр.

Пес тип кемнәр: Әптеракман пава пелән Айника мама, Пасир әкә пелән Кәлпигә йеңкә, Әптекәй әкә пелән Шәмши йеңкә, Пикә йеңкә, Сапир әкә пелән Туктапигә йуңкә, Мөкәррәмә йеңкә, Шәүкәт әкә пелән Майрә, Вәли әкә, Коппи, Вәкил әкә, Миңлегали, Мөгәмәтгирәй әкә, Нияз, Анвар әкә пелән Мөнәүәрә, Миркә йеңкә әм мин. Пәрепес йгермә ике кеше ите. Әргем пәтрә, капцикларны тултырганнан суң, киңке йагын, кайткалы тип цыктык. Шул цакны, ауылның әм мынталыларның иң олосо Әптерәкмән пава сураты: «Кем төстә йакшы йөри пеләте» – тип. Йәш пулганга ма, араларыннан пагыртым – тейтем ми-и-н тип. Әптерәкмән пава әйтте, алайса пәреннән цык алтка тите. Мин масайып, кайышып килеп атлап киттем. Пара-пара иңер төшөп, краңкы та пулып китте. Ә пес иңней йулга әле цыгалмайпыс. Менә алт йакта, песне цагырып, йәшел көйләкле пер кыс күренте. Пес ул кыс торган йергә парсак, ул тагын та алтта. Ул цагырган, йәшел кейемле кысны, пөтөнепөс күрәпес, Әптерәкман паватан пашга. Шул уакытны, Әптерәкман пава пәрепесне тә туктатты «аташтык» тите. Ул үсе көйгәк кеше мине ийеп параты. Пелмәгәң, нимә күтең кысмай, мактанып куйасын тип. Әркем үсенә-үсе нейрат ите. Әптерәкман пава перенце пулып, пәр пулган торнагүсен караңкылыкта мөккә актарты. Малтан паш кыпат тите. Исән-аман мыннан кайтуны гына уйлау кәрәк тите. Пашгалар та, үсләренең көнө пуйы йыйган торнагүсләрен, караңкылыкта йак-йакка түктеләр. Шуннан суң, Әптерәкман пава, перәй йуанрак агац төпкә парып, кунгалы әйтте. Осак пуматы нацагай уйнай пашлаты. Аның йалтырап калган йарыгынта, пер күчә утырган йуан агацларны күреп, анта атлатылар, пәр калык. Пырастан айаклар, каты йергә тейтеләр. Шуның өцөн мынта гына кунгалы пултык. Нацагай уйнаган уакытта, пырас йарыпейәте йак-йак, пес перас коро цыпыртык йыйыпыйапыс. Аның йарыгынта, Сапир әкә пелән Туктапигә йеңкә, пернимәгә, пер-пере пелән орошоп сугышып китәтләр, ату караңкыта, кемне суккалы пелмәйтеләр. Кинәттән йап-йарык нацагай уйнапейгәннән суң, шатыртатып, цытыртатып күкерт кукрәп ейте. Шул уакытны сугышта пулган Әптерәкман пава, ул ике сугышны гражданнар сугышын та, кырык перенце йылныкынта күргән кеше, мынтай ите кәпе: «Айника ыснарят мыннан та тың йарылаты» – тип. Ә Пасир әкә, Кәлпигә йеңкәгә: «Корткайак, мин камантер пулганта, кәтүшә атканта, менә пылай йарып-йарып китәтегән ите ауата» – тип. Әптекәй әкә корткайагына «Ысталинграттa нимец пелән песнеңкеләр аралашып киткән ите. Пес атапыс, нимец ататы, ыспайлап карапаксалар, нимецләр үсләренеңкен, ә песнеңкеләр, үсләренеңкен атканнар игән, мынтай йарыкта гына пелтек» – пес. Әргем төрлө нимәләр кәпләп, йаңкыр йауып утырган, ицкем рәтләп, йоклай та алматы, шулай итеп аратирә ут йагып, төннө нәсилә цыктык. Көскө көн пулгац, ируастан гына

йарый пашлаты. Перәүләре цай кайнаткалы тип, пәтрә алгац, су эстәп мөклө йургә парты. Шул уакытны, ул цыңкырып – әйтте. Йул пы пуйта гына тип. Иртәге йарыкта, пәре тороп, карапаксалар, йоклап, тим алып. Кунган йерепестән ун-унпиш кенә атлам йертә, йул усаты игән. Имән кунып цыгыптык, саска төшәтегән генә йертә. «Кара утраута» куныптык, аннан йөс кенә атлам йертә, ауылга кайтатыган тагыртап йаткан олло йул. Алай пулса та, йулга көц-кәл пулсын тип, пес цай-нимә кайнатып, эссе цай эцеп алтык. Шуннан суң кына, кайтыр йулга кусгалтык.

Менә шунтай кәлләр пулты пер төстәге еш-кыс өцөн. Мин ул көннө перттә онота алмайым.

Йасылты 19 октябрьдә 1999 йылны сәгәт кицке 7.15 ите.

*Мавликаев Сәгтәттин Мырсултанның паласы, аңа 61 йәш.*
*Ешаер аулы, Вагай районы. 19.10.1999.*

## Кем ул ак сагаллы карт

Сеснең өй астыгыста йарбашта «Казан кайнаган йер» – пар. Ул пуйга цүп түкмәң, аннан усганта төгөргөнкәле, сүгешкәле тә йарамайты.

Пергөннө минең пелән пулты мынтай кәл. Йәйнең көнө сеснең өй пуйыгыстан, кицке сыйыртан кайтып парганымта пер картны күртем. Ул карт ак сагаллы, тайак тайанган ите. Пы уакыткацак ауылта антай карт күренмәгән ите ицкайта. Шул уакытны йылга йактан әсгәт синең килеп утырганыңны күртем. Аның турынта синнән сурагалы иткән итем, ул карт әллә-калай йугалып китте.

Ул ук көннө йоклап йатканымта, менә мынтай төш күртем. Йылга йанта йарбашта пер-үсе сеснең өйегес утыраты игән. Тактапашта, ул ук ак сагаллы карт, үсенең тайагы пелән йайганып, сине кергесмәй тороп куйты. Өйгә пашгаларны пәрен тә пушатты ә сиңа пылай тип әйтте: «Сине Әсхәт кергесмәйем, ник тисәң. Мин синнән кургам» – тип.

Менә нимә игәнен ул, үсем тә пелмәйем.

Кәпләте Кәлпигә мама Аминова пенсионерка. 17 июньдә 1984 йылны, Ешаер ауылынта.

*Йасылты 13 октябрьдә, 1999 йылны. Сәгәт киөке 9.02 ите.*

## Хикмәтулла әүлиәнең үнәре

Кимә күлнең уртасына йеткәц, өц кеше пагор пелән, йылымның мәтицәсен эстәй пашлаты. Ул уакытны кимәтәге өцәүнең, перәүе цыңкырты, таптык мәтицәне, пагор пренимәгә эләкте тип. Кинәттән пагор суга төшөп китте, ә кимә асты йактан күтәрелеп китеп, актарылып китте. Шул уакытны ыспайы гына койашлы көн тымык пулса та, әллә-кайтан өүерлеп килеп койон килте. Койон кәттә кимәне күтәреп өүереп китте тә, суның ур-

тасыннан алып килеп пәрте. Кимә тик цыракланып китте. Ул койон күсне ацкылык түгел, әшкәрә каты пулты. Әркем йергә йатып кына, котолоп калты. Койон алай уйнап усганнан суң, көн ыспайлап, сәйелләнте. Кыйна күлнең өстөтә көмөш сынны суы, йалтырап күренте. Ә йуан талның йанына парып, кешеләр цыракланып йаткан кимәне тә күртеләр. Ә кимәтә пулган өц кеше калай киткәнен, иңкем пелмәте. Инте күлнең йанынтагы палыкка килгән калык, нимә эшләгәле пелмәте. Ауылга кайтып ницек ул өц кешенең семийасына әйткәле. Йылымны та мәтицәсес пулгац, кәрәге йук тип, калтыртылар. Йурыктан цыккан, цыракланып йуан талның йанынта йаткан, кимәнең калтыкларына, карап торганнан суң, перәү әйтте: Кицә әйте гуй, Хикмәтуллага-әүлиә иртәгә палыкка килмәң тип. Йак, пес туймаслыгыпысны уйлап, тагын та килтек. Менә, инте пескә алтыпыста көмөр пуйына пы уакыйга тәрес пулсын.

Ауылга кайткац, пелтек, Хикмәтулла әүлиә күрше ауылга парыпты. Анта кинәттән Кәтицә тигән матур сылу инте үсеп йеткән кыс аурып киткән. Инте үләте генә тигәнтә, кецегәсе өйтәгеләренең пелтермәйтен, ат пелән Ешаир ауылыннан, сәгәт иртәге пишләртә, Хикмәтулла-әүлиәне алып килепейгән. Перәй сәгәттән суң ул, төсәтеп Кәтицәне алган. Ә төштән суң, аның кецегәсе әүлияне Ешаир ауылына кире ат пелән илтеп тә килгән.

Песне тыңлап алганнан суң, Хикмәтулла әүлиә пылай тип әйтте: «Йә оланнар, менә күртегесмә инте, цаматан тыш пайлыкка сырыну, ицкемне әле йакшылыкка алып килмәгән» – тип.

Ул уакытта Хикмәтулла-әүлиәгә каралган сылу кыс Кәтицә, кәсер инте пенсиятәтә пулуына карамастан, әле тә матур, ыспайы. Шулай ук әле тә күрше Көмөшлө аулынта йәшәйте. Йәшләрне тә йеткесмәен, тик йөгөрөп кенә йөрите.

Менә шунтай кеше ите, синең олло-атаң Хикмәтулла әүлиә – Әсхәт.

*Йасылты 28 сентябрь 1999 йыл.*

## Төнкөгә ацык калган сөт

Пы кәл пулты мең тугыс йөс алтмыш түртенце йылны. Йәйнең көнө иртәнке сәгәт алтылырта, әллә-нимәгә мин кинәттән уйанып килтем. Пырастан калмай инәм тә уйанты. Аннан инәм пылай тип әйтте. Менә кәсер төшөмтә, мин Гани абыйларга кертем. Өйләренең эце пуйлап, пөтөн йерләрентә йөрөп цыктым. Пыларның эцке йакларынта, мейец аргата куңыр мискәтә, йарты мискә сөтләре аусы йапылмай, утырып калыпты. Менә аннан мин, пер пармагым пелән тәмләп пактым.

Мыңацак, мин Гани абый пелән Роза апаларга кереп йөрмәгән перттә. Нәрсләренең, кайта, ницек утыруын та пелмәйем. Ирмәк өцен, менә

– творческой деятельности Якуба Камалиевича Занкиева в контексте татарской литературы второй половины XX века;

– языковой и этнической общности волго-уральских и сибирских татар;

– деятельности учителя родного языка в условиях обновленных ФГОС НОО.

На конференции состоялась презентация хрестоматии для учащихся начальных классов Тюменской области – «Татарская детская литература (конец XX – начало XXI в.)» («Татар балалар әдәбияты (XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы), авторы-составители – **Лилия Харисовна Фаизова**, кандидат филологических наук, доцент кафедры теории и методики начального и дошкольного обучения ТПИ им. Д.И. Менделеева (филиала) ТюмГУ и **Гузель Чахваровна Файзуллина**, доктор филологических

наук, профессор кафедры теории и методики начального и дошкольного обучения ТПИ им. Д.И. Менделеева (филиала) ТюмГУ. В подготовку хрестоматии немалую роль внесли художники-иллюстраторы – **Асия Альбертовна Закорюкина,** преподаватель МАУ ДО ДШИ им. А.А. Алябьева Тобольска и **Наталья Молдук**, студентка 4-го курса. На презентации книги присутствовали ученые, учителя школ с этнокультурным компонентом, студенты, общественные деятели, писатели, среди которых были поэтессы Тюменской области **Галия Абайдуллина** и **Фахричамал Утяшева**. Хрестоматия издана при поддержке Правительства Тюменской области, Комитета по делам национальностей Тюменской области, РОО НКА сибирских татар и татар Тюменской области». В дополнение к хрестоматии также изданы методические рекомендации по ее использованию в образовательном процессе начальной школы.

Мастер-класс «Формирование функциональной грамотности детей младшего школьного возраста на уроках родной литературы (на материале творчества Г. Абайдуллиной)» с использованием хрестоматии провела **Баниса Сунгатулловна Ниязова,** почетный работник сферы образования Российской Федерации, учитель татарского языка и литературы МАОУ СОШ № 15 Тобольска с участием своих учеников – младших школьников.

В рамках работы секционных заседаний рассматривались актуальные вопросы, связанные с проблемами методики обучения языку и литературе в школах с этнокультурным компонентом образования; историко-культурного наследия как фактора сохранения национальной идентичности; также были обсуждены вопросы совершенствования традиционных форм воспитания и обучения в начальном и дошкольном образовании; представлены филологические исследования, представляющие интеграцию науки и педагогической деятельности.

Программу конференции продолжили экскурсии: в музей народного образования Тюменской области; в музей национальной школы МАОУ СОШ № 15 Тобольска. Гости и участники конференции посетили интересные выставки, посвященные творчеству Я.К. Занкиева.

Музыкально-литературная гостиная проходила на базе Центра сибирско-татарской культуры Тобольска и стала ярким и творческим завершением программы конференции. На мероприятии коллеги, друзья, близкие и родственники Якуба Камалиевича Занкиева поделились воспоминаниями об учителе, писателе, фронтовике, прозвучали строки из его произведений и мемуаров.

Организаторы поблагодарили партнеров и участников конференции, приехавших из разных населенных пунктов Тюменской области, делега-

ции коллег из Республики Татарстан и Республики Узбекистан (Бухарский государственный университет)!

*Г.Ч. Файзуллина*

**Туган якны өйрәнү – мөһим мәсьәлә**

«Төбәк тарихы һәм татарларда туган якны өйрәнү: тарих һәм заман» дигән темага 2023 елның 28 апрелендә Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе узды. Аны БТК, БТК БКның татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр белән эшләү комитеты, ТР ФА, фән һәм сәнгать буенча Петр академиясе, «Европа-Азия» халыкара гуманитар академия, Дөнья мәдәнияте институты (Юнеско), ТРның «Татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте» төбәк иҗтимагый оешмасы үткәрде.

Конференциядә катнашучыларны сәламләп, БТК БКның татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр белән эшләү комитеты башлыгы, ТРның «Татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе А.Ә. Борһанов БТК һәм ТР ФАнең фәнни-туган якны өйрәнү десантының 9–12 апрельдә Беларуська булган сәфәре турында видеопрезентацияне күрсәтүдән башлап җибәрде.

Туган якны өйрәнүче, РФ Язучылар берлеге әгъзасы, Россия тарихчылар җәмгыяте әгъзасы, татар төбәк тарихын өйрәнүчеләрнең Ульяновски өлкә Советы әгъзасы, хәрби хезмәт ветераны Р.Б. Илкин «Аллагул (Атнагыл) авылы тарихы» исемле китабына эчтәлекле презентация ясады. Рус телендә дөнья күргән аның бу фундаменталь хезмәте ике китаптан тора: беренчесе «История села Аллагулово (Атнагыл)» дип атала, ә икенче китабы «Возрождение имени предков» исеме белән басылган (Димитровград, Издательский центр «UNI Press», 2023, 532 с. (43, 225 п.л.)). Атнагыл авылының бай тарихы тирәнтен һәм күпьяклы өйрәнелгән әлеге 2 кг авырлыктагы китапка кереш сүзне А. Борһанов язган. Р. Илкин китабының презентациясендә тарихи-архив документлары, Илкиннарның нәсел шәҗәрәсе күрсәтелде.

Уфадан килгән туган якны өйрәнүче, фән һәм сәнгать буенча Петр академиясе мөхбир-әгъзасы, ТР ФАнең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты фәнни хезмәткәре Р.Ф. Мәсәгутовның доклады зур кызыксыну белән тыңланды. Башкортостанда татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыятенең башкарма комитеты җитәкчесе Р. Мәсәгутов рус телендә басылган «Западное Приуралье в свете образования Татарской и Башкирской Республик 1917–1922 гг.: надежды и реалии» (Сборник документов и материалов. Составительи Р.Ф. Масагутов и М.Х. Ибрагимов. Казань.

Редакционно-издательский центр «Школа». 2023, 256 с.) китабын фәнни җәмәгатьчелеккә тәкъдим итте. Хезмәтнең гыйльми мөхәррире – тарих фәннәре кандидаты Р.Р. Әминов, рецензентлары: тарих фәннәре докторы, академик И.Р. Таһиров һәм юридик фәннәр докторы Д.Р. Зәйнетдинов (фән һәм сәнгать буенча Петр академиясенең Татарстан төбәк бүлеге карары буенча басылган).

Профессор, тарих фәннәре докторы Э.Р. Таһиров ватанпәрвәрлек рухы белән сугарылган чыгышында Ринат Илкин һәм Руслан Мәсәгутов хезмәтләрен югары бәяләде. Р. Илкинның китабын батырлык дип атады. Аннары «туган якны өйрәнү» төшенчәсен аңлатты, аны гуманитар фәннәр рәтенә кертеп карарга кирәк, диде. Э. Таһиров фикеренчә, туган якны өйрәнү – иҗтимагый хәрәкәт тә ул. Хәзер Россиядә туган якны өйрәнү өлкәсендә Яңарыш бара, шул исәптән Татарстанда да туган якны өйрәнү гуманитар фән һәм иҗтимагый хәрәкәт буларак, үсә, диде «Европа-Азия» халыкара гуманитар академия президенты. Татарстан мисалы башка халыкларга да үрнәк, тәҗрибәне өйрәнәчәкләр, дигән өмет белдерде. «Махсус хәрби операция чорында да Татарстан – Россиянең таянычы», – дигән фикер дә әйтте Дөнья мәдәнияте институты ректоры. «Соңгы елларда туган якны өйрәнү хәрәкәте Татарстанда активлашты», – диде Э. Таһиров, мондый яңарышны ул акыл үсеше белән чагыштырды. Аның патриотик чыгышы конференциядә катнашучыларны да рухландырып, канатландырып җибәрде.

Тарих фәннәре кандидаты, ТР ФАнең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты фәнни хезмәткәре Р.Р. Әминовның доклады Көньяк Урал һәм Урал буена караган фәнни материалларга нигезләнеп, татар казакларын өйрәнүнең кайбер нәтиҗәләренә һәм киләчәккә куелачак бурычларга багышланган иде. Шулай ук үз чыгышында галим Оренбургта яшәүче милләттәшләребез туган якны өйрәнүгә үзләреннән зур өлеш кертүен билгеләп үтте.

Н.К. Гафиятов, туган якны өйрәнүче, «Татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте» әгъзасы буларак, Минзәлә төбәген тәфсилле өйрәнүе хакында тулы хисап тотты. Минзәлә районының татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте рәисе презентациясендә «Нугай Урдасы һәм Казан ханлыгы, 1462 елгы карта» күрсәтелде. Бу исә җәмәгатьчелек игътибарын уятып җибәрде. «Китабыгызны кемнең фәнни хезмәтләренә нигезләнеп яздыгыз?» – дип сорадым. Докладчы күренекле галим Марсель Әхмәтҗанов хезмәтләренә таянып, Нугай Урдасы белән Казан ханлыгы дустанә, аралашып яшәгәннәр, Нугай Урдасы Казан ханнарына Нурсолтан, Сөембикә кебек атаклы ханбикәләрне биргән, дип сөйләде. Шулай ук: «Салават Хөсәенов архив документлары белән нык ярдәм итте, 1 нче һәм 2 нче ревизия китапларына да таяндым»– диде.

А.Борһанов әйтүенчә, «Татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте»ндә татардан тыш, рус, мордва, чуваш милләтләреннән дә туган якны өйрәнүчеләр бар. ТР ФАнең А.Х. Халиков исемендәге Археология институтының лаборант-тикшеренүче А.И. Бугарчев – шундыйларның берсе. Ул үз чыгышында эшләгән эшенә кыска отчет бирде, мәсәлән, Питрәч районын өйрәнеп, гыйльми китаплар чыгарган, төрле журналларда һәм җыентыкларда 15 фәнни мәкалә бастырган. Гомумән, бу конференциядә докладчылар, нигездә, фәнни хисап тоттылар. А.Бугарчевның презентациясендә 2022 елда – 2023 ел башында туган якны өйрәнүче нумизматларның эшчәнлегенә йомгак ясалды, табылган, үзе өйрәнгән XII–XV гасырлардагы тәңкәләр монитордан күрсәтелде.

А.Г. Дәминов – туган якны өйрәнүче, РФнең мактаулы нефтьчесе – русча чыгыш ясап, Көнбатыш Себердә эшләгән чоры һәм Иске Ромашкино авылы турында китаплар язганын, бүгенге көнгә барысы өч китап бастырып чыгарганын әйтте. РФнең атказанган төзүчесе А.Дәминов Иске Ромашкино һәм Биктимер авыллары хакында 1 нче ревизия китапларына таянып язган. Ханты-Манси автоном округы – Юграның нефть-газ табу сәнәгатенең атказанган хезмәткәре сөйләвенчә, мәсәлән, Иске Ромашкино янында Биктимер исемле кечкенә авыл булган, анда барлыгы 79 кеше яшәгән, инде ул авыл күптән юк.

Конференциядә катнашучыларны икътисад фәннәре докторы, КФУ профессоры, ТР ФА мөхбир-әгъзасы һәм вице-президенты, фән һәм сәнгать буенча Петр академиясенең Татарстан төбәк бүлеге рәисе, «РФ икътисад җәмгыяте» Татарстан төбәк бүлеге җитәкчесе В.В. Хоменко сәламләгәннән соң, Р. Мәсагутов, А. Дәминов, Р. Салиев, М. Черепанов, Н. Гафиятов, М. Шәмсетдиновка ТР ФАнең Рәхмәт хатын тапшырды.

Туган якны өйрәнүче, «Нократ» туган якны өйрәнү район оешмасы җитәкчесе Р.А. Муллаәхмәтова Мамадыш төбәгенең танылган кешеләре турында конференциягә күркәм презентация әзерләп килгән. Ул сүзен Мамадыш районында туып үскән атаклы шәхес, шагыйрь, эзтабар-язучы Шәйхи Маннурдан башлады, эзтабарлыгының матур нәтиҗәсе – архив документларына нигезләнеп иҗат иткән «Муса» романы. Икенче күренекле эзтабар-әдип Шаһинур Мостафин иде, ул остазы итеп Р. Мостафинны таныган. Мәсәлән, Ш. Мостафин Газинур Гафиятуллин батырлыгын кабатлаган 438 солдат язмышын ачыклый. Мамадыш районы шулай ук язучылар Р. Мөхәммәдиев, З. Мансуров, җырчылар М. Галиев, Г. Ибушев, композитор Ч. Зиннәтуллина һ.б. шәхесләре белән горурлана. Мамадыш ягы атаклы өч композиторны – Заһидулла, Фәрит, Мирсәет Яруллиннарны биргән төбәк санала. Туган авылы Кече Сөндә Салих Сәйдәшевнең укытучысы З. Яруллинга һәйкәл ачылган. 2017 елда Беларусьта

Ф. Яруллинга һәйкәл куйганда, Ч. Зиннәтуллинаның «Аерылмагыз» җырын башкарулары ямь өстенә ямь өстәгән.

М.Х. Шәмсетдинов – туган якны өйрәнүче, Питрәч районының Чыты авылы Мәдәният йорты директоры – үз чыгышында Чыты авылында төзелгән Мәүлә Колый проекты хакында тулы итеп аңлатты. Чыннан да, соңгы елларда питрәчлеләр XVII гасыр татар шагыйре М. Колыйны бик нык күтәрделәр, аларга бу игелекле гамәлләре өчен зур рәхмәт. Газ кертелгәч, асфальт юл салынгач, мәчет, Мәдәният йорты, парк төзелгәч, яшьләрнең туган авылда төпләнеп калуын искәртте, Чыты авылының яшәреп китүен, яңаруын ассызыклады. М. Колыйга, Ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуга багышлап фәнни-гамәли конференцияләр оештырулары Питрәч төбәгендә туган якны өйрәнүчеләрнең актив эшләвен күрсәтә торган ачык дәлил. Докладчы шулай ук Питрәч ягының горурлыгы саналучы, шушы районнан чыккан Советлар Союзының өч Каһарманы Гаврилов, Осипов, Камалиевны телгә алды. Аерым алганда, питрәчлеләргә хас булганча, Күн авылында туган Петр Гаврилов турында аеруча күп сөйләде.

Тарих фәннәре кандидаты, «Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәгенең өлкән фәнни хезмәткәре Н.А. Кореева кыска гына хәбәрендә Россия империясе татарларының эшмәкәрлек тарихы буенча хәзерге заманда якланган кандидатлык һәм докторлык диссертацияләренә характеристика биреп, атап үтте, мәсәлән: Илшат Фәйзрахманов, Радик Салихов (Казандагы атаклы татар сәүдәгәрләре турында), Андреева (Чувашстан), Арсентьев (Удмуртия), Гафиятуллина (Чистай төбәгендәге татар эшмәкәрлеге), Наил Таиров (татар эшмәкәрләре Акчуриннар хакында). Шулай ук Россия империясенең Казан, Түбән Новгород губерналарында, Себер, Новосибирск, Оренбург төбәкләрендә гомер кичергән татар эшмәкәрләренең эшчәнлеге турында да диссертацияләр якланган.

«С.К. Гыйматдинов исемендәге Осиново гимназиясе»нең тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы, туган якны өйрәнүче Н.Н. Вәлиуллина мәктәптә Тау ягының күренекле вәкилләре – Каюм Насыйри белән Гайнетдин Әхмәровны өйрәнүләренә басым ясады. Гимназия укучыларында тарихи үзаңны булдырыр, аларга милли тәрбия бирер, бала күңелендә милләте белән горурлану хисен арттырыр өчен мәктәп партасыннан ук татар халкы тарихын ныклап өйрәнә башларга кирәк дигән кыю фикер әйтте ул.

Л.А. Ахромова – «Иске Казан дәүләт тарихи-мәдәни һәм табигать музей-тыюлыгы» ТРның дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе фәнни хезмәткәре Камай авылындагы Иске Казан музей-тыюлыгына тукталып, татарлар турында гына сөйләргә кыен, чөнки ул җирлектә башка халыклар да яшәгән, диде. Музейга экспонатлар итеп Р. Фәхретдинов,

А. Борһанов китаплары да куелган. Туристлар өчен музейның коммерция нигезендә эшләвен искәртте, кергән акча Иске Казан кальгасын төзекләндерүгә тотыла.

РФ мәгарифенең мактаулы хезмәткәре Р.З. Салиев, рәис буларак, Биектау районының туган якны өйрәнүчеләре җәмгыяте башкарган эшләр хакында хисап тотты, мәсәлән, Биектауда туган якны өйрәнүчеләрнең конференциясе уздырылган.

Бөтенроссия конференциясен йомгаклап, А. Борһанов туган якны өйрәнүчеләр алдында торган бурычларны тагын бер тапкыр ачыклады:

1) Туган як тарихын архив материалларына таянып, фәнни нигездә ныклап өйрәнү;

2) Танылган шәхесләрне барлау, онытылган татар исемнәрен халкыбызга кире кайтару;

3) Этнотуризмны үстерү максатында Татарстанның тарихи шәһәр-авылларына, Россиянең татарлар борынгыдан яшәгән җирләренә этнотуристик маршрутларны булдыруга ярдәм итү, татар объектлары турында туристларга сөйләрлек дөрес эчтәлекле чыгышлар әзерләү, сатып яки бүләк итеп бирерлек китаплар язып бастыру;

4) Туган якны өйрәнүчеләр, тарих укытучылары һәм музейлар ярдәме белән яшь буында туган якка мәхәббәт тәрбияләү.

*Илһам Фәттахов*

## Имеш, өч әлифба кирәк

Менә чираттагы «Милли тормыш һәм дин» дигән исем астында үткәрелүче XIII бөтенроссия татар дин әһелләре җыены да (19–21 май) узып китте.

Сүз уңаеннан искә төшереп китим әле: берничә тапкыр мөфтиләр, аерым алганда, Саратовта оешкан Идел буе мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Мөкатдәс хәзрәт Бибарсов, олуг мөнбәрдән чыгыш ясаганда: «Монда дин әһелләре җыелган, шуңа күрә җыенны, динне алга куеп, «Дин һәм милли тормыш» атамасы яктылыгында үткәрү дөресрәк булыр иде», – дигән тәкъдим белән чыккан иде. Моңа БТК җитәкчеләре, чараны төп оештыручы – Татарстан Диния нәзарәте түгел, Татар конгрессы, шуңа күрә нинди исем бирү безнең ихтыярда» мәгънәсендәрәк җавап бирде. Бер караганда конгресменнар хаклы кебек. Әмма төптән, сүз сөрешеннән караганда, кулланыштагы атама да, Мөкатдәс хәзрәт тәкъдиме дә отышлы түгел. «Милли тормыш һәм дин» дип әйтсәк тә, «Дин һәм милли тормыш» дип тәгаенләсәк тә, әлеге төшенчәләрне аерып куябыз түгелме

соң?! Милли тормыш – үзе бер аерым өлкә, дин үзенә бер аерым тармак түгел ләбаса. Милли тормыш динне колачлаган сыман, дин үзе дә милли хәятыбызны күз уңында тотарга, милләтебезне саклауга өлеш кертергә тиештер шәт. Минемчә, бу мөһим җыенны «Милли һәм дини тормыш» дип тәгаенләргә, шушы рәвешле әлеге төшенчәләрне янәшә куеп, тормышыбызның ике асыл хасиятенә, сыйфатына әверелдерергә кирәк.

Сер түгел, дин өлкәсендә дә, милли хәятыбызда да әледән-әле проблемалар чыгып тора, электән хәл ителми килгәннәре дә үзен сиздереп куя. Әйтик, мәдрәсә тәмамлаган яшьләрнең шәһәрдән китәргә, авыл җирендә эшләргә теләмәүләре дигән җитди мәсьәлә бар. Моның сәбәбен гадәттә мәдрәсә тәмамлап авыл җиренә кайткан яшь имамнарга тәгаенләнгән хезмәт хакы булмауга, мәчетләргә халыкның аз йөрүенә бәйләп аңлаталар. Шул ук вакытта бөтенроссия татар дин әһелләре алдында, җыенның пленар утырышында нотык тоткан Россия мөселманнары Диния мәҗлесе рәисе Әлбир хәзрәт Кырганов: «Әнә илебезгә Урта Азиядән килеп дини гыйлем алучы егетләр социаль пакетсыз да авылда эшләргә әзер», – дип белдерде. Әлеге хәл мәдрәсә тәмамлаган татар яшьләренә ихласлык, гайрәт җитми дигәнне аңлата. Югыйсә, баш казыебыз Җәлил хәзрәт Фазлыев тәкъдим иткәнчә, яшь имам авыл җиренә барып төшүгә, өйдән-өйгә йөреп мәхәлләдәшләре белән танышып чыкса; карт-корының, яшь-җилкенчәкнең күзенә карап, кулыннан тотып, дингә өндәсә; җирле халык мәнфәгатьләрен йөрәгенә якын алып, җәмәгать эшләрендә катнашса, өммәттәшләребез күңеленә ачкыч тапмый, мәчетләрне тутырмый калмас иде.

Күптән түгел генә Сахих Бохариның бер тәфсирен тыйдылар. Моның сәбәбе әле һаман дини әсәрләргә сәяси-фәлсәфи анализ ясамыйча, психология, филология күзлегеннән экспертиза үткәрүгә кайтып кала, – дип Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин дини тормышыбызда булган хилафлыкларга тукталды. Мондый конфликтларга җирлек калдырмас өчен, ул Россия күләм дини экспертлар шурасы оештырырга, дини әдәбиятны барча мөфтиятләр белән бергәлектә, килештереп нәшер итәргә тәкъдим итте. Шунысы кызык: татарча дини әдәбиятның тыелганы юк, дип ул каләм тибрәтүче имамнарны дини әдәбиятны үз телебездә язарга чакырды. Шул җөмләдән башкалабыз Казандагы Ислам динен кабул итүнең мең еллыгы исемендәге мәдрәсә ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин, мәдрәсәләрдә барча фәннәрне татарча укытырга, шул рәвешле мәдрәсәләрдә, мәчетләрдә милли мохитне саклап калырга өндәде.

Татарча укыту проблемасы башкалабыздагы Россия Ислам университеты өчен дә актуаль. РИУның уку-укыту бүлеге мөдире Нәзирә Гыйззәтуллина, әлеге зарурлыкны танып, бу җәһәттә булган проблемаларны барлады. Болар, беренче чиратта, дини уку йортларына урыс телле аби-

туриентларның күпләп килүе, татар телендә укытырлык укытучыларның аз булуы, дини фәннәр буенча татарча дәреслекләрнең аз бастырылуы.

Оренбур өлкәсе мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Әлфит хәзрәт Шәрипов, 130 еллык тарихы булган «Хөсәения» мәдрәсәсендә милли тарихыбызны, телебезне өйрәнү уңышлы алып барыла, дип нотык тотты. Әлеге сүзләргә ышанып бетмичә, берничә көннән хәзрәттән, сездә ничә шәкерт укый, дип белештем. «Җәмгысы өч йөзләп шәкерт. Аларның мотлак күпчелеге – читтән торып укучылар. Көндезге бүлектә унике шәкерт. Аларның икесе генә – татар. Калганнары – таҗик, үзбәк, казакъ балалары», – дип сөйләде ул. Мин әле үзем апрель аенда гына Оренбург өлкәсенең Әсәкәй районын гизеп, бер уңайдан мәчетләрен дә багып кайткан идем. Анда имамнар: «Оренбургтан практикага шәкертләр килә килүен, тик алар урыс телле, туган телебездә дин нигезләрен аңлата алмый. Шуңа күрә аларны чакырудан әллә ни мәгънә күрмибез», – дип зарлана. Монысы бер хәл. Мөселманнар мәшһүр «Хөсәения» мәдрәсәсе бинасын һаман үз карамакларына ала алмаган, әле дә ул җирле агроуниверситетның бер бинасы булып хезмәт итә. Бу җәһәттән мөфти хәзрәт: «Дини биналарны дин тотучыларга кайтарып бирү тиешлеге хакында 2010 елны ук РФ хөкүмәте карары чыкса да, шәһәребездә православие биналарын да, мөселман биналарын да бик зур кыенлык белән кайтаралар. Әле бит биргән сурәттә, аның көнкүреш чыгымнарын күтәрүгә ел саен 300 мең сум акча кирәк булачак. Ул хәтле акчаны кайдан табыйк?!» – дип аһ орды. Өлкә өчен бу шул кадәр зур акча микәнни?! Әнә Чуаштандагы Комсомол районының Тукай авылы мәдрәсәсе химаячылар шурасы рәисе Әгъзам хаҗи Шакиров: «Мәдрәсәбезнең көнкүреш чыгымнарын күтәрү һәм мөгаллимнәргә хезмәт хакы түләү өчен ай саен 200 мең сум акча тотыла», – ди.

### Милли хәятыбыздан тагын бер хәвеф

20 май көнне булган икенче бер җыелышта – Бөтендөнья Татар конгрессының Милли Шурасы утырышында да милләтебез яшәешенә караган бик мөһим мәсьәләләр күтәрелде. Шуларның берсенә генә тукталып китәм. Кайбер «кайнар башларның» татар теленең көнчыгыш диалектыннан аерым себер татар теле ясарга маташуларын әйтүебез. Бу ыгы-зыгы Россия Фәннәр Академиясенең Тел белеме институты әлеге диалектны аерым тел дип игълан итүеннән соң көчәеп китте. Әлеге вәзгыять уңаеннан утырышта Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры урынбасары Олег Хисамов әтрафлы чыгыш ясады. Галим дөрес әйтә: татар әдәби телендә бездәге үзенчәлекле авазлар, аерым бер грамматик формалар юк, дип кенә уртак әдәби телдән баш тартырга ярамый; сезнең диалектта булган үзенчәлек тагын бер башка

диалектта, сөйләштә булмый калмый лабаса. Шәт гомуми телебездә бар икән, димәк, бер тел мохитендә яшибез.

Әгәр диалектлар арасында охшашлык 90 проценттан ким икән, аерым тел итеп карарга мөмкиннәр. Татар кайсы диалектта сөйләшсә дә, ярты сәгатьтән бер-берсен тулаем диярлек аңлый башлый. Шунысы кызык: себерләрне аерым тел итеп карарга тырышучылар арасында лингвистлар юк, – дип тә ачыклык кертте О. Хисамов. Әлбәттә, әдәби тел берничек тә барча диалектлардагы үзенчәлекләрне туплап бетерә алмый. Әнә кытай теленең йөзләп сөйләше бар; аларның күбесе бер-берсенең ни әйткәнен төшенми, диләр. Әдәби кытай теле булганга, алар бер-берсен аңлый да инде. Гарәп телен генә алыйк. Аның кырыктан артык шивәсе яшәп килә. Уртак әдәби тел эшләнгәнгә, алар ансат аралаша.

Әле бит себер татар диалекты үз чиратында тубыл-иртыш, тумлы, бараба сөйләшләренә бүленә (кайбер галимнәр, саз ягы сөйләшен дә аерым карарга мөмкин, ди). Аларны ничек өйрәнеп һәм өйрәтеп бетермәк кирәк, мондый хәлдә нишләргә, дип, әлеге гауга куера башлагач, Себер татарлары конгрессы рәисе Ринат Насыйровка мөрәҗәгать иткән идем. «Әйдә, Казан булышсын! Балалар үз телен онытмасын өчен, өч төрле әлифба нәшер итеп бирсен!» – дип җавап бирде ул миңа. Көлсәң – көл, еласаң – ела!.. Шул ук вакытта себер татар әдәби телен беркем дә булдырырга җыенмый. Биредә әлеге дә баягы Ринат Насыйровның Милли Шура утырышы вакытында яңгыраткан гыйбрәтле күрсәткечләрен китереп китү дә урынлы булыр. «Егерме ел элек бездә, Төмән өлкәсендә 140 татар мәктәбе бар иде, бүген 39 мәктәп татар мәктәбе санала, биш елдан соң шушындый унике мәктәп кенә калачак», – дип белдерде ул. Андый темплар белән татар мәктәпләре юкка чыкканда, җирле сөйләшләрне кайда, кем өйрәнер-үзләштерер икән?

Милли Шура утырышында катнашкан РФ Дәүләт Думасы депутаты Илдар Гыйльметдинов та бу вәзгыятькә ачыклык кертергә тырышты. «Тел белеме институты җитәкчеләре белән сөйләштем. Алар бу очракта бернинди сәяси төсмер күрми. Аерым тел дип белдерүнең Росстат агентлыгына тәэсире юк, дигән фикердә торалар», – дип белдерде ул. Билгеле, җанисәп вакытында күпчелек халык үзен «татар» дип тәгаенли икән, чиновниклар әллә ни кыра алмый. Әнә Себердә яшәүче ярты миллион татарның нибары 6 меңе үзен «себер татары» дип язган икән, мичкәдәге бер тамчы гына бу. Бу җәһәттән РФ Фәннәр академиясенең Тел белеме институтында: «Алты мең кеше дә аерым бер милләт булып саналырга хаклы. Шундый аз санлы милләтләр дә бар лабаса», – дигән караштa торучыларның булуы да мәгълүм. Әйе, Себернең аз санлы халыклары арасында шулай аз калучылар да бар. Әмма бу очракта, шайтан – башка,

җен – башка, дигәндәй, биш йөз мең милләттәшеннән аерылып торырга уйлаган алты мең кеше турында сүз баруын онытмыйк.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдуллин милләтебезнең бердәмлеген какшата торган мондый омтылышларны кискен гаепләп чыкты. «Ни генә әйтсәгез дә, бу – сәяси мәсьәлә. Милләтебезне таркатырга тырышучыларны кемнәрдер рухландырып, матди яктан ярдәм итеп тора. Язучылар мохитеннән бер генә мисал. Россия халыклары әдәбияты җыентыгына, себер татарлары әдәбияты, дип аерым кешеләрне тәкъдим иттеләр. Монда татарны бүлгәләү һәм юкка чыгару максаты куелган. Әнә башкорт галимнәре Көнбатыш Башкортстан татарларының телен башкорт теленең бер диалекты итеп игълан итте», – дип сөйләде ул.

Р. Зәйдуллин фикеренә кушылып, соңгы вакытта «асаба» башкорт милләтчеләрнең нугай милләтчеләре белән берләшеп Әстерхан татарлары арасында коткы таратуын, җирле татар тиңдәшлеген җимереп, милләттәшләребезне нугайлаштырырга омтылуын да искәртеп китмичә булмый. Кавказдагы нугайлар белән Әстерхан нугайлары төрле халык икәнен белү-төшенү өчен урта гасырлар татар тарихын, Алтын Урда тарихын белергә, үзбәк кардәшләрнең әле һаман да без-татарларны «нугай» дип исәпләүләрен онытмаска кирәк. Хәер, урта гасырларда Салават Хәмидуллин кебек башкорт тарихчылары бармактан суырып алган «Башкирия» дигән дәүләт булмаган, Урал тавы итәгендә, Агыйдел, Караидел буйларында башында нугай бабаларыбыз – Идегәйләр торган Нугай Урдасы хөкем сөргән.

*Рәшит Минһаҗ*

## Татарчасы кирәк

Заманасы да, урыны да шундый: күп сөйләп, аятьләр-хәдисләр китереп, бер-беребезне вәгазьли торган вакыт түгел. Монда барыбыз да – милләт һәм өммәтебезнең хәлен эчтән белгән, шуның өчен йөрәге әрнегән затлар.

Җәмәгать, Чуаштандагы татарлар тормышы хакында күбегез белә, Аллаһка шөкер, хәлебез начар түгел. Мондый үрнәкләр, әлбәттә, күп төбәкләрдә бардыр.

Чуашстанда милли һәм дини тормыш бергә бара. Шуның дәлиле буларак һәр мәчет каршысында булган мәхәллә мәктәпләрендә татар телендә булган китаплардан динебез нигезләрен өйрәтергә тырышабыз. Ел дәвамында дини укулар барышында «Шәкертләр бәйрәме» вә шәкертләр ифтары кебек дини ярышмалардан тыш, милләтебезнең дәрәҗәсен күрсәтер өчен, бөек татар шагыйрьләренең шигырьләрен сөйләү бәйгеләре дә уза. Бу тәрбия өлешендә еш кына мөхтәрәм Васил

Гаяз улы Шәйхразиев та, кадерле кунагыбыз буларак, мәҗлесебездә катнашырга вакыт таба. Мисалга үзем яши торган Тукай авылын китерәм. Монда бер мең ярым кеше яши, барысы да – татарлар. Электән үк дини булган авылыбызда гөрләп мәчет эшләп тора. Быел аны сүттек, быел ук аның урынына зур, заманча мәчет төзергә ниятлибез. Моңа хәтле авылда өч катлы мәхәллә йорты – мәдрәсә төзегән идек. Бу эштә Рөстәм әфәнде Миңнеханов та саллы ярдәмен күрсәтте. Өч катлы мәхәллә йортында, мәхәллә мәктәбендә Чувашстанда бердәнбер дәүләт лицензиясе булган «Гөлстан» мәдрәсәсендә эшләнгән программа нигезендә һәр көнне, яшьләренә карап, дини укулар бара. Зур ашханәсендә чәй мәҗлесләре, конференцияләр залында авылның иҗтимагый советы утырышлары уза, спорт залында балалар шөгыльләнә, мәчет залында гыйбадәт кылына. Кыскасы, татар авыллары өчен үрнәк бина бу, һәм ул тулы куәткә, зур дәрт белән эшли. Төп шатлыгыбыз, әлбәттә, анда укулар баруы. Олылар өчен дә, балалар өчен дә дини укулар оештырыла. Барысы да туган телебездә. Бу бинаны, аның эшчәнлеген тәэмин итү ай саен 150 мең сумга төшә. (Сер түгел, кайбер төбәкләрдә яшь имамнарны тоту, эшләтү өчен биш-ун мең сум таба алмый интегәләр). Укытучыларга түләү, ут-газ чыгымнарын – барысын да авыл халкы күтәрә. Үзенә кирәк булгач, малын җәлләми милләтебез. Кыскасы, мәхәлләбез тормышы кызыксындырса, килегез, күрегез, өйрәнегез. Барысын да монда сөйләп бетереп булмый.

Авылда өр-яңа мәктәп һәм балалар бакчасы эшли. Шунысын да әйтим: авылда балалар бакчасы булмаганда, башта ул мәчеткә терәтеп ясалган бинада оештырылган иде. Аны да авыл халкы төзетте. Мәктәбебез татар телле, балаларыбыз да татар телле.

Әмма мин күтәргән мәсьәлә – Чуашстан татарлары өчен генә түгел, Татарстаннан читтә яшәүче меңләгән татар балалары хакына хәл ителергә тиешле бер проблема. Монысын берничә ел сөйләп тә, һаман хәл итә алмыйбыз әле. Монда утырганнарның күбесенә кагыла бу.

Эш шунда ки: Россиянең барлык мәктәпләрендә дә, закон тәртибендә, ФГОС буенча «Основы религиозных культур и светской этики» дигән фән укытыла. Ул дәүләт фәне, әмма мәктәптә татар телен сайлап алып булган кебек, бу фәннең дә модульләрен сайлап алырга мөмкин. Теләгән бала яки ата-анасы сайлап православие өйрәнә, теләгәне будда яисә яһүд динен, теләгәне барлык диннәрнең дә нигезләрен өйрәнә. Теләгән бала «Основы исламской культуры» дигәнен сайлый ала. Закон буенча бу шулай. Ул дүртенче классларда укытыла. Ислам мәдәнияты буенча ФГОС раслаган яхшы гына дәреслек бар. Әлбәттә, бу фән Ана телендә булса, балаларның һәм ата-аналарның әлеге модульны сайлап алуына җәмгыя-

тебездә тагын бер этәргеч булыр иде. Әйтергә теләгәнем шул: әлеге фәнне татар мәктәпләрендә татарча укытасы иде, җәмәгать.

Моны без генә булдыра алмыйбыз. Бу – дәүләт эше. Без бу юнәлештә шактый эшләп-эзләнеп карадык. РИУ ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшинга зур рәхмәт, ул бик зур ярдәм итте. Аның ярдәмендә, татар балаларына татарча укытылсын өчен, Россия күләмендә бу фәннән олимпиадалар, укытучыларның белемнәрен арттыру курслары уздырдык. Барыгызга да яхшы аңлашыладыр: татар баласына татарча ислам дине мәдәниятын өйрәтү – ул өстәмә татар теле дәресе дә. Әмма китап юк.

Проблемалар күп, ләкин без көчле, гайрәтле халык. Теләсәк, барысын да эшли алабыз. Әмма җәмәгать оешмалары булдыра алмаганнарын хәл итүдә дәүләт даирәләренең ярдәм итүләрен сорыйбыз.

Сүземне тәмамлап, Татарстан Рәисе Рөстәм әфәнде Миңнехановтан, татар телен саклау һәм үстерү комиссиясеннән «Основы исламской культуры» дәреслеген татарчага тәрҗемә иттерүен вә укытучыларның белемнәрен арттыру курсларын саллы дәрәҗәдә үткәрергә булышуын үтенәм.

*Наил хәзрәт Җамалетдинов,*
*ЧР Комсомол районының Тукай авылы мәчете имам-хатыйбы*

**Мөслимдә Исхакыйлар нәселе**

1 июль көнне Чистай районының Мөслим авылында «Авыл көне» булды, анда мин дә катнаштым. Бәйрәм тантанасы Рамил Нуруллин һәм Рафыйк Насыйровның Мөслим авылы тарихы турында документаль китабын тәкъдим итүдән башланды. Заманында бу төбәктәге милли һәм дини тормышның үзәге булган Мөслим авылы мондый саллы, җитди китапка бик лаек! Тантанада авторлар үзләре дә катнашты, чыгыш ясадылар. Шушы авыл тумасы Рамил Нуруллин – Биләр урман хуҗалыгының баш урманчысы, Рафыйк Насыйров – тарих фәннәре кандидаты, Аксубай районының Түбән Татар Майнасы урта мәктәбе директоры. Мин дә халык алдында чыгыш ясап, бу төбәкнең тарихына, бигрәк тә көчләп чукындырулар чорына тукталдым, Гаяз Исхакыйның «Зөләйха» әсәрендәге вакыйгаларның шушы як авылларында барганлыгын әйттем. Сөйләгәннәремне дәлилләп, Мөслим китапханәсенә Зөләйханың прототибы булган Гөләйза турындагы «Гөләйза» китабымны бүләк иттем.

Бу авылга кайтуымның икенче сәбәбе Гаяз Исхакыйның нәселе белән бәйле иде. Тарихтан билгеле булганча, Гаяз Исхакыйның әнисе Камәрия абыстай шушы Мөслим авылы кызы була, аның әнисе Мәхфүзә абыстай биредә кырык елдан артык балаларга ислам сабагы бирә. Тарихчы Ра-

фыйк Насыйров Мөслим зиратындагы кабер ташларын өйрәнгәндә, бик матур язылган һәм бик яхшы сакланган бер кабер ташына юлыга. Анда Мөхәммәтша кызы Мәхфүзә абыстай җирләнгәне, аның кырык елдан артык балаларга гыйлем бирүе язылган була.

Метрика кәгазьләре, ревизия документлары белән чагыштырып, нәсел шәҗәрәләрен өйрәнеп, Рафыйк Насыйров бу кабер ташының Гаяз Исхакыйның әбисе Мәхфүзә абыстайныкы икәнлеген ачыклый. Ул бу кабер ташындагы язуларны күчереп ала, аларны кирилл хәрефләренә дә әйләндерә. Рамил Нуруллин җитәкчелегендә һәм Мөслим мәчете ярдәмендә, Мәхфүзә абыстайның кабере рәткә китерелә, зират капкасының шул турына коймага истәлек тактасы куела. Анда, «Бу кабергә татар халкының бөек юлбашчысы, сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе, язучы, драматург, нәшир Гаяз Исхакыйның әбисе Мәхфүзә Мөхәммәтша хәзрәт кызы, Габделвәли хәзрәт җәмәгате, кырык елдан артык Мөслим авылы балаларын укыткан галимә-остазбикә җирләнгән. (1839 – 1903)», дип язылган.

Авыл халкы алдында чыгыш ясап, мин Мәхфүзә абыстайның оныкчыгы Сөембикә ападан күп сәламнәр тапшырдым, ул Гаяз Исхакыйның апасы Гайнелмарзиянең кызы, 104 яшендә, Ташкент шәһәрендә яши. Авылдашы Наилә Потеева аша без аңа Мөслим авылындагы әбисенең кабер ташы һәм истәлек тактасы фотоларын җибәргән идек. Сөембикә апа әбисенең каберен яхшы хәтерли булып чыкты, элегрәк анда кайтып та йөргән. Мөслим авылында Гаяз Исхакыйның нәселе белән бәйле истәлекләрне кадерләп саклаганнары өчен ул авыл халкына зур рәхмәтләрен әйтте.

Рафыйк Насыйров белән берлектә, мин дә Мөслим зиратында булдым, Коръән укып, Мәхфүзә абыстай рухына, Гаяз Исхакый нәселенә дога кылдык. Шунысын да әйтергә кирәк, бу нәсел ике яклап та танылган дин әһеле, кырымлы Гәрәйләр династиясе вәкиле Морат муллага барып тоташа, аның кабере янәшәдәге Чирүле Шынталасы авылы зиратында.

«Авыл көне»н халыкның исендә калдырырлык итеп уздырганы, туган авылы турында китап язганы, Гаяз Исхакыйның нәселе белән бәйле истәлекләрне кадерләп саклаганы өчен Рамил Нуруллинга һәм Чулман аръягы төбәгенең төп тарихчысы Рафыйк Насыйровка зур рәхмәтләремне әйтәм!

*Фәүзия Бәйрәмова,*
*1.07.23. Чистай районы, Мөслим авылы.*

## Кабер ташы табылды

Семи-Җидепулат (Казахстан) шәһәреннән милләттәшебез Рамил Рәхимбаевның хәбәр итүенчә, иске татар зиратында танылган дин әһеле Хәбибрах-

ман Мәсәгутовның кабер ташы табылган. Татар энциклопедиясенең язуынча, Хәбибрахман хәзрәт – дин һәм җәмәгать эшлеклесе, Алабуга шәһәре ахуны, 2 нче Дәүләт Думасы депутаты (1907), «Мөселман хезмәт таифәсе» әгъзасы, «Дума» газетасын чыгаручыларның берсе. Туган елы 1862, үлгән елын энциклопедиядә чама белән, 1930 елдан соң, дип язганнар. Яңа табылган кабер ташы моңа төзәтмә кертә – Хәбибрахман Мәсәгут улы 1921 елның апрелендә, үпкә чиреннән үлгән, Җидепулат шәһәренең татар зиратында җирләнгән. Янәшәсендә 5 яшьтә үлгән баласының да кабер ташы бар.

Хәбибрахман Мәсәгутовның кабер ташында аның Морт авылы имамы, Алабуга һәм Сарапул мөхтәсибе, 2 Дума әгъзасы, матбугат хадый, Семипулатта мосафир хәлендә 59 яшендә, 1921 елда үлүе язылган. Дөрестән дә, Хәбибрахман хәзрәт 24 яшендә Морт авылы Җәмигъ мәчетендә имам булып эшли башлый, 1896 елда инде Алабуга өязенең ахуны итеп билгеләнә, аңа тирә-як авыллардагы 12 мәчет карый. Күргәнебезчә, ул җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша, Сарапул һәм Алабуга өязләреннән Думага депутат итеп сайлана, милләт хокукларын яклап, «Шура» журналына мәкаләләр яза. Революциядән соң Җидесу төбәгенә китә, үләр алдыннан бер ай Семипалатинскиның Җәмигъ мәчетендә имам булып эшләп өлгерә. Хәбибрахман хәзрәтнең нәсел чыгышы хәзерге Әгерҗе районының Кодаш авылыннан, җиде буын муллалар.

Семидан Рамил Рәхимбаевның хәбәр итүенчә, бу ярымташландык татар зиратында меңләгән милләттәшебез ята. Күп кенә дин әһелләре дәһшәтле 1921 елда вафат булганнар. Рамил Рәхимбаев белән җирле тарихчы Мадьяр Насыйров хәзер шул борынгы кабер ташларын өйрәнәләр. Дөрес, 2016 елны Казан галимнәре килеп, кайбер кабер ташларын өйрәнеп киткән, әмма гектарларга сузылган иске татар зиратын бер килүдә генә өйрәнеп бетеп булмый. Инде шундый борынгы бер татар зираты юкка чыккан, аның өстендә хәзер «Локоматив» стадионы. Инде монысы өстенә дә ничә тапкыр йортлар салырга омтылып карадылар, хәзергә халык бирми, татарлар каршы тора. 2011 елда мин үзем дә бу борынгы татар зиратында булып, бик тетрәнгән идем, әйтерсең лә, меңләгән кабер ташы, ярдәм сорап, каршыма чыгып басканнар иде...

Әйе, бу каберстанда танылган дин әһелләре дә, сөргенгә сөрелгәннәр дә, туган җирләрен ташлап китәргә мәҗбүр булган татарлар да ята... Милләтнең бер өлеше шушы далаларда ята... Дога көтеп, ярдәм көтеп, мәрхәмәт көтеп...

*Фәүзия Бәйрәмова,*
*4.07.23.*

13 мая 2023 г. главный редактор журнала «Туган җир. Родной край» принял участие на торжествах, посвященных 100-летию МБОУ «Шеморданский лицей «Рост» Сабинского муниципального района РТ. Он поздравил коллектив школы и участников мероприятия с юбилеем от имени Исполкома ВКТ, вручил от его имени подарок, пожелал успехов в работе и предложил руководству лицея более тесное сотрудничество с «Обществом татарских краеведов РТ» и с журналом «Туган җир. Родной край».

19–20 мая 2023 г. в Тобольске РТОО «Наследие» по Тюменской обл. проводился III-й международный фестиваль-конкурс историко-культурного наследия сибирских татар и коренных народов евразийского пространства «Сүзге-тора». В рамках данного фестиваля состоялась III-я Всероссийская научно-практическая конференция «Историко-культурное наследие сибирских татар и коренных народов евразийского пространства: истоки и современность». 20 мая 2023 г. на этой конференции выступили члены редколлегии и гл.редактор журнала «Туган җир. Родной край»: д.и.н. Д.М. Исхаков (тема: «Основные этапы формирования татарской нации»), д.и.н., в.н.с. Института истории им. Ш. Марджани АН РТ И.Л. Измайлов (тема: «Татарская нация: теория и практика современного подхода к изучению этнической истории»), с.н.с. ТКНС УрО РАН, к.и.н. З.А. Тычинских (тема: «Проблема «Сибирского карачи»: новые подходы»), с.н.с., к.и.н. Отдела новой истории Института истории им. Ш. Марджани АН РТ, Б.И. Измайлов (тема: «Татары в перписях населения 19 – первой половины 20 веков»). Выступления вызвали у участников целый ряд вопросов, на которые были даны квалифицированные ответы.

2023 нче елның 26 май көнендә Г. Ибраһимов ис. ТӘһСИда Ш.Ш. Кадыров һәм И.Г. Закирова авторлыгында чыгарылган «Татар халкының музыкаль-эпик иҗаты: себер ареалы» (Казан, 2022.–312 б.) исемле хезмәт тәкъдим ителде. Чарада журналыбызның баш мөхәррире, тарих фәннәре докторы Д.М. Исхаков катнашты. Бу хезмәтне (ә ул 1968–1972 нче елларда булган экспедиция материалларыннан тора) ул югары бәяләде һәм анда татар халкының Себер төбәгендә тупланган көй белән башкарыла торган эпик һәм лиро-эпик жанрларга караган әсәрләрнең ноталар белән бергә басылуына игътибар итте.

## Фестиваль «Язгы моңнар»

4 июня 2023 г. в Тобольске состоялся II-й Межрегиональный фестиваль татарского народного творчества «Язгы моңнар», организованный Тобольской городской общественной организацией «Национально-культурная автономия сибирских татар». В мероприятии приняли участие самодеятельные коллективы из разных уголков Тюменской области. Фестиваль прошел как большой, теплый и яркий праздник для татарского населения города и региона.

Инициатор проекта, зам. председателя НКА сибирских татар Тобольска Илтус Уразмаметов поблагодарил всех участников за любовь к родному языку и культуре, выразил благодарность за компетентное и доброжелательное судейство направленным Всемирным Конгрессом татар жюри фестиваля – старшему преподавателю кафедры хореографии КазГИК Муллагалиевой Резеде Флюровне и доценту кафедры сольного народного пения КазГИК, Заслуженному работнику культуры РТ Бабаевой Гюльмире Билаловне.

Гран-при фестиваля получил ансамбль ветеранов-педагогов «Яшьлеккә сәяхәт».

*Зайтуна Тычинских*

26 – 30.06.2023 г. в Санкт-Петербурге прошел конгресс антропологов и этнологов России. На форуме присутствовали свыше 800 ученых, в основном из РФ, но были и зарубежные участники (из КНР, Узбекистана и некоторых др. стран). В ходе заседаний конгресса работали 54 секции, 7 «круглых столов» и 1 воркшоп. С докладами из Казанских научных центров выступили известные ученые, доктора наук Л. Сагитова, Г. Макарова (Институт истории им. Ш. Марджани), О. Хисамов (ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова) из АН РТ, а также гл. редактор журнала «Туган җир. Родной край», д.и.н. Д.М. Исхаков (тема доклада: «О дискуссионных аспектах Списка языков России: татарский случай»), а также член редколлегии журнала, с.н.с. ТКНС УрО РАН, к.и.н. З.А. Тычинских (тема доклада: «Перепись 1926 г. и судьба бухарской идентичности в Западной Сибири»). Форум завершился избранием президиума Ассоциации антропологов и этнологов из 25 чел. и ее президента – им повторно стал академик В.А. Тишков.

«Туган җир. Родной край» журналының баш мөхәррире Д.М. Исхаков 2023 елның 11–13 июль көннәрендә БТКның Милли Шурасы рәисе

В.Г. Шәйхразиев катнашында үткән Курган өлкәсе, Йолдыз авылында булган Милли Шураның бюросы утырышында катнашты.



22 июля 2023 г. в п. Прииртышский Тобольского района Тюменской области состоялся III-й Гастрофестиваль «Сибирский баурсак». Он с 2021 г. проводится по инициативе Тобольского района для пропаганды традиционной культуры сибирских татар – коренного населения юга Тюменской области.

Баурсак – традиционное национальное блюдо практически всех тюркских народов и традиции его изготовления уходят вглубь веков. Однако только у тоболо-иртышских татар известен подобный вариант этого кулинарного изделия, без которого не обходится ни один хатым-аш, ни один традиционный праздник. В народе такой баурсак еще называют олло-баурсак, кэбэц баурсак.

В 2021 г. на первом фестивале был изготовлен самый большой баурсак, размеры которого были занесены в книгу рекордов России. В этом году победители конкурса баурсаков – команда Центра сибирско-татарской культуры Тобольска (и.о. директора А.В. Муратова) побили прежний рекорд и изготовили баурсак высотой 36 см, а в диаметре – 76 см!

# ТӨБӘК ТАРИХЫНА КАРАГАН ХЕЗМӘТЛӘР ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТ. РЕЦЕНЗИЯЛӘР

# ИНФОРМАЦИЯ О КРАЕВЕДЧЕСКИХ ТРУДАХ. РЕЦЕНЗИИ

## НОВАЯ КНИГА




Вышла новая книга по истории сибирских татар, которая тут презентуется. Авторы – казахстанские историки и в монографии представлены взгляды национальной историографии Казахстана на историю Сибирского Улуса в связи с историй казахов.

Несмотря на то, что не со всеми взглядами, изложенными в этой работе, можно согласиться, эта работа заслуживает внимания, в том числе и для широкого круга интересующихся историей татар Сибирского региона.

# МИЛЛИ АШЛАР, СӘЛАМӘТЛЕКНЕ САКЛАУ ЮЛЛАРЫ

# НАЦИОНАЛЬНАЯ КУХНЯ, ПУТИ СОХРАНЕНИЯ ЗДОРОВЬЯ

*Зайтуна Тычинских*

## СИБИРСКИЙ БАУРСАК



На 0,5 литра молока – 4–6 яиц, 200 гр. сливочного масла, 0,5 ч.л. соды, 0,5 ст. ложки сахара, 1 ст.л. ложка соли. Молоко немного подогреть, смешать с солью и растопленным сливочным маслом, содой, сахаром до растворения соли и сахара. Постепенно всыпать муку до образования мягкого эластичного теста. Очень быстро разделить на кусочки и скатать небольшие шарики. Их раскатать немного и разложить в большое блюдо или тазик слоями, между которыми проложить чистую ткань, чтобы не слипались. Накрыть тканью/полотенцем и поставить в теплое место примерно на 30 мин. Когда делаем шарики и раскатываем тесто, нужно как можно меньше присыпать мукой. В большом широком блюде хорошо нагреваем масло, можно растительное, 1–1,5 литра. Берём лепешки и постепенно растягиваем. Затем опускаем в масло. Сверху постоянно поливаем поварешкой маслом до получения румяных хрустящих золотистых «шапочек». Вынимаем осторожно из масла и опускаем следующий баурсак.

*Фирая Захарова*

# ХАЛЫК МЕДИЦИНАСЫ



**Дару үләннәре турында төп мәгълүматлар**

Һәр кеше, гомумән, барча җәмгыять өчен сәламәтлектән дә кадерлерәк нәрсә юк. Дәвалау үзенчәлекләрен киң кулланучы халык медицинасы бу юнәлештә җитди урын били. Үсемлекләр, терлек, җанвар майларын, минераль чималларны чамасын төгәл белеп дәвалау, хастаны аякка бастыру ысуллары бик борынгы заманнарда барлыкка килгән. Мондый мәгълүматларны Кытай, Мисыр, Һиндстанда җентекләп җыйганнар. Санскрит, Европа, кытай, грек, латин, татар-төркиләрнең борынгы мәдәни ядкарьләрендә үсемлекләрнең шифалы хасиятләрен файдалану турында кызыклы мәгълүматлар укырга мөмкин.

Әлеге язмаларны яхшылап укыганнан соң, дәвалау барышында төрле майлар (мазьлар), шактый катлаулы микстура, примочкалар, хуш исле бальзам, сумалалар кулланылганы ачыклана. Дөньяда дәвалау сыйфатында кулланып булмаслык бер нәрсә дә юк, дип әйтелә борынгы будда медицинасы киңәшләрендә. Фәнни медицина (тыйбб) фәне Борынгы Грециянең мәшһүр табибы Гиппократтан башланган дип исәпләнә. Грек цивилизациясе илебезнең көньяк төбәкләрендәге борынгы медицинаны үстерүгә җитди тәэсир ясаган. Гиппократ дәвалау максатында 200 төрле үсемлекнең дәвалау үзенчәлеген шәрехли.

Дәвалагыч сыйфатында беренче медицина әсәрен борынгы Рим табибы Авел Корнелий Цельс язган. Аның хезмәтләрендә үсемлекләрне ни рәвешле куллану турында бик күп киңәш-тәкъдим бар. Рим гаскәре табибы Диоскорид, шифалы үләннәрнең исемлеген тагын да киңәйтеп, 500ләп төрен тасвирлый.

Шифалы үләннәр турындагы яңа тәгълимат авторы, мәшһүр табиб һәм фармацевт Клавдий Гален дару матдәләре (үсемлек чималыннан әзерләнгән төнәтмә, экстракт һәм башка дәвалаучы эшләнмәләр) ясауның стандарт ысулларын беренчеләрдән булып тәкъдим итә. Шул сәбәпле алар әле дә Гален эшләнмәләре дип исәпләнелә һәм бүген дә әһәмиятен югалтмый. Латин үләнчесе Апулей хезмәтләре үз заманында бик киң таралган булган. Борынгы урыс дәүләтендә дә шифалы үләннәргә зур игътибар биргәннәр. Киев Русе оешкач, язу таралгач, дәвалагыч, шифалы үләннәр, дигән беренче китаплар дөнья күрә. Нигездә болар итальян, алман, поляк теленнән тәрҗемәләр була. Шифалы үләннәр турында урысча кульязмалар да булган. Гөлсем әбием дә үлән төнәтмәләре белән дәвалый иде. Әйтик, мәтрүшкәнең дәвалау үзлеге булуы халкыбызда күптәннән билгеле. Үз заманында татарларда халык табиблары – им-томчылар зур хөрмәт казанган. Күптән түгел чит ил архивларында XII гасыр болгар-татар галиме Таҗетдин Әл-Болгариның «Шифалы үләннәрнең мөмкинлекләре» дигән хезмәте табылды. Бу җәһәттә XIX гасырда яшәгән һәм иҗат иткән атаклы мәгърифәтчебез Каюм Насыйриның да хезмәтләре билгеле.

Илебездә үсә торган үсемлекләрнең мөмкинлекләре, куәте белән кызыксыну Петр Беренче реформаларыннан соң аеруча көчәеп китә. Патша галиҗәнәбләре шифалы үләннәр җыюга зур әһәмият биргән. Дөрес, бу кызыксыну бер көчәеп, бер сүрелеп тора. Бөек Октябрь революциясеннән соң гына сәламәтлек саклау өлкәсе ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатында шифалы үләннәрне җыю, өйрәнү, куллануга мөнәсәбәт үзгәрә. Фитотерапия – тулы бер дәвалау чаралары системасы барлыкка килә. Илебездә яшәүче халыкларның шифалы үләннәрне кулланудагы күп гасырлык тәҗрибәсен өйрәнүгә бүген дә зур әһәмият бирелә. Бу хәл

үз чиратында үләннәрдән ясалган нәтиҗәле эшләнмәләрне медицинага уңышлы кертүгә ярдәм итә. Соңгы дистә елларда шифалы үләннәрне файдалану зарурлыгы күп мәртәбә артты. Дәвалау барышында шифалы үләннәрне кирәгенчә кулланганда терапевтлык мөмкинлекләре күпкә киңәя. Байтак кына авыруларны булдырмау, кисәтү максатында, дәвалау курсы үткәргәндә дә шифалы үләннәрне куллану яхшы нәтиҗә бирә.

Үләннәрнең өстенлеге шунда: зыяны булган сурәттә дә организм аларның тәэсирен җиңелрәк кичерә. Шуңа күрә аларны һич шикләнмичә, дәвамлы рәвештә кулланырга мөмкин. Шулай ук җиләк-җимеш, яшелчә куллану да зур терапевтик әһәмияткә ия. Кайчагында бу рәвешле дәвалауның файдасын берни алыштыра алмый. Әмма шул ук вакытта химик синтезлау нәтиҗәсендә ясалган даруларны үсемлекләр кулланып әзерләнгән эшләнмәләргә каршы кую дөрес булмас. Тегеләре дә, болары да мөһим. Әйтик, интенсив терапия вакытында антибиотиклар, гормоннар һәм психотроп матдәләрне берни белән алыштырып булмый. Җиңел патология формаларын дәвалау яки кисәтү максатында, хәл булмаганда, кәеф киткәндә шифалы үләннәргә өстенлек бирергә мөмкин.

**Дару үләннәрен үстерү, әзерләү, киптерү һәм саклау**

Илебезнең табигате чималга, шул исәптән кыр-урманнарда үсә торган дару үләннәренә бик бай. Әмма шифалы үләннәр иксез-чиксез түгел, бездән соң киләчәк буыннарга да җитсен өчен, аларга сакчыл карарга кирәк. Үләннәрне киң кулланырга чакыру белән бергә табигый байлыкларыбызның сакланышына һәрберебез җаваплы икәнен искә төшермичә булмый. Шөкер, һәртөрле җир кишәрлекләрендә гади генә шифалы үләннәрне дә, безнең якларга ятрак булганнарын да үстерүләрен еш күрергә туры килә. Бу – бик куанычлы хәл. Кыргый үсемлекләрдән тыш илебездә дару үләннәрен промышленность масштабында үстерү һәм җыю да алга китте.

Үсемлектәге биологик актив матдәләр аның төрле урынында, үсешенең билгеле бер мәлендә туплана. Кайсыбер үсемлекләрнең шифалы матдәләре бөресендә, яфрагында, сабагында, икенчеләренең чәчәгендә яки җимешендә, өченчеләренең тамырында яки кабыгында була. Кызык: әлеге шифалы матдәләрнең саны, исәбе өлгерү чорында бер килеш тормый, хәтта көн дәвамында үзгәрергә мөмкин. Шуның өчен дә вакытында җыеп алмаган сурәттә үләннәр актив кушылмалары бик аз тупланган мәлдә әзерләнүе ихтимал. Гәрчә болай җыелган үсемлекләр дә, көч-куәте шактый зур булганга, җитәрлек тәэсир итә. Гомумән, аларны җыю һәм әзерләү вакыты биологик актив матдәләрнең туплану һәм җыелу урынына, вакытына карап билгеләнә.

Бөреләр. Дәвалау чималы рәвешендә каен, нарат, тупылның бөреләрен кулланалар. Аларны иртә язда, тулышып килгән мәлдә, әмма әле үсүгә

керешкәнче җыялар. Бу гадәттә март-апрель аенда була. Эре бөреләрне (әйтик, наратныкын) пычак белән кисеп алалар, вакларын (каенныкын) ботагын китергәннән соң, сыдырып алалар. Бөреләрне салкынча, җиләс бинада шактый вакыт бик сак киптерергә кирәк, караңгы бинада алар ачыла башлый.

**Кабык.** Агачларның һәм куакларның кабыгын (имән, балан, эт шомырты) – язын, согын мул биргәндә җыярга кирәк. Мондый чакта кайры агачыннан ансат аерыла. Яз ахырында, җәен, үсеш туктагач, кайрыны каезлау кыен. Кисеп, чабып алынган яшь ботаклардан кайрысын алу өчен анда 25–50 см. саен балдак сыман уентылар ясыйлар да, аны көпшә кебек суырып, тартып чыгаралар. Әгәр ботакны мүк (**лишайник**) сара башлаган булса, кыйммәтле чимал бозылмасын өчен, аны әүвәл пычак алып чистартырга кирәк.

**Трутовиклар.** Фармацевтика өчен һәм ризык әзерләү масатында аларны язын, сокны мул биргән вакытта һәм көзен, гөмбә кышка әзерләнеп, файдалы матдәләр туплаган мәлдә җыярга тәкъдим ителә. Корыган агачлар үскән урында һәм җиргә якын төштән трутовикларны алу киңәш ителми. Аларны үткен пычак яки балта белән кисеп алалар. Әгәр гөмбә уалып тора икән, ул җыярга яраклы түгел.

**Яфраклар.** Аларны бөреләнгәндә (гонҗәгә әверелгәндә) һәм үсемлек чәчәк аткан вакытта җыялар. Бу эшне коры һава торышында эшләү, кул белән өзеп җыю мәслихәт. Гадәттә төпкә якынрак, яхшырак үскән, кәүсәнең уртарак төшеннән җыеп алалар. Сулган, төссезләнгән, бөҗәкләр ашый башлаган, гөмбәчектән зыян күргән яфракларны җыярга ярамый.

**Үләннәр.** Аларны гадәттә чәчәк аткан вакытта, кайбер төрләрен шау чәчәктә утырганда җыялар. Аларны җиргә тидермичә урак белән урырга, пычак белән кисеп алырга була. Кайвакыт үсемлекләрне печән чапкан кебек чалгы, урак белән чабалар да, шул «печән» арасыннан сайлап, җыеп алалар.

**Чәчәк һәм оешма (укмаш) чәчәк.** Боларны чәчәк ата башлаган мәлдә җыялар. Бу вакытта чәчәктәге файдалы матдәләр күбрәк була, сакларга куйганда алар аз коела, киптерүне яхшырак кичерә, төсен җуймый. Чәчәкне, кул белән җыялар да сабагыннан аералар. Кайвакыт укмаш чәчәкләрне җыю өчен махсус җайланма – чүмеч кулланалар.

**Җимешләр, төшләр.** Өлгергән җимешләр, төшләр шифалы матдәләргә аеруча бай. Шул сәбәпле аларны тулысынча өлгерүенә карап, кул белән сайлап, җимеш сабакчасыннан аерып, берәмтекләп җыялар. Миләш, әнеч (тмин) һәм башка тәлгәшләнеп үсә торган җимешләрне учлап җыялар да, кипкәч, җентекләп тәлгәшеннән аерып алалар. Гөлҗимешне касәсе белән җыялар да, кипкәч, кул белән уып, касәсеннән аера-

лар. Сусыл җир җиләген, кура җиләген, караҗиләкне җыю аеруча кыен. Шуңа күрә сытылмасын, изелмәсен өчен, аларны сабагы, яфрагы белән җыярга туры килә.

**Тамыр, тамырча, суганча.** Аларны, җир өсте өлеше кипкәч, корыгач, үсемлекләр тынычлану чорына кергәч (җәй азагында, көзен) җыялар. Аларны иртә язда, җир өсте өлешләре үсә башлар алдыннан да җыярга мөмкин. Тик бу язгы мәл бик кыска, берничә көн генә. Аларны көрәк белән казып алырга, көпшәк туфрактан сәнәк, тырма белән дә суырып чыгарырга була. Тамырлар һәм тамырчаларның туфрагын каккач, яхшылап суда юалар. Тамырлар зур күләмдә җыелган икән, аларны агымсуда үрелгән зур тырыста яки тутыкмас тимердән ясалган челтәр савытта юуы ансатрак. Юылган тамырларны чиста үлән, капчык яки кәгазь өстенә тезеп, кояшта киптерергә дә мөмкин. Аннан соң әлеге тамырларны сабак калдыкларыннан, вак-төяк тамырчыклардан, зыян күргән яки чери башлаган өлешләреннән азат итеп, ахыр киптерү урынына урнаштыралар. Тамырларның кайбер төрләре, әйтик, гөлҗимеш, көнбагыш, калган тамырларын 1 см.дан да кыскарак итеп кисәргә, вакларга кирәк, чөнки алар киптергәннән соң «таш» кебек ката.

Үсемлекләрнең җир асты өлешен фәкать коры һава торышы вакытында гына җыялар. Әгәр иртә чык төшсә яисә яңгыр явып китсә, әзерләү эшләрен үсемлекләр тулаем кипкәч кенә башлыйлар. Кичен чык төшсә, шулай ук җыю эшләре башкарылмый. Шифалы чимал җыюның иң кулай вакыты иртән сәгать 8дән 10га, төштән соң, кичен 16.00дан 18.00 га кадәр. Үләннәрнең җир асты өлешләрен һава торышының нинди булуына карамастан әзерләргә мөмкин.

Үсемлекләрне киеренке юл хәрәкәте булган юл буйларында, чүплек, зыянлы сәнәгать урыннарына, чүплекләргә якын җирләрдә җыярга ярамый. Шулай ук нык тузанлы, пычранган, төрле чирләргә, корткычларга дучар булган, ниндидер химикатлар белән эшкәртелгән төшләрдә дә дару үләннәре җыймыйлар. Чималны шунда ук савытка җыярга кирәк. Шифалы чималны, бигрәк тә чәчәк, яфрак, өлгергән җимешләрне җыю өчен иң яхшы савыт – зур булмаган капчыклар, катыргы тартмалар, җитен, киҗе-мамык, бәз капчыклар. Коры җимешләрне, орлыкларны, үсемлекләрнең җир асты өлешләрен капчык, тартма, чиләк һәм башка шушындый һава керә торган савытларга салып сакларга була.

Киптерү урынына алып килгән чималны тукыма, чиста идәнгә яки брезентка бушатып тезәләр һәм очраклы рәвештә эләккән таш, туфрак кисәкләреннән, кипкән үлән калдыкларыннан чистарталар.

Җыелган чималны беренчел эшкәрткәннән соң тиз арада киптерү зарур. Үз вакытында киптермәсәң, үсемлекләрдәге файдалы матдәләр

(гликозидлар, алкалоидлар һәм башка шундыйлар) юкка чыга, чималны черетә, бурсыта торган микроорганизмнар һәм гөмбәчекләр үрчи. Киптерүнең төп максаты – чималдагы дымны бетерү. Нәтиҗәдә анда тереклек барышы, ферментларның хәрәкәте туктый. Никадәр тизрәк киптерсәң, чимал да шулкадәр сыйфатлырак.

Киптерү рәвеше чималның төренә, анда нинди матдәләр гамәлдә булуга бәйле. Әйтик, эфир мае булган үсемлекләрне (бөтнек, мәтрүшкә, чабыр һәм башкалар) 30–35 градустан югары булмаган температурада әкрен генә киптерәләр. Югарырак температура булса, майлары очып бетәргә мөмкин. Киресенчә, үсемлекләрдә гликозидлар булганда (горицвет, энҗе чәчәк, сарыбаш), аларны 50–60 градус җылылыкта киптерү зарур. Мондый җылылыкта гликозидларны юкка чыгара торган ферментлар эшчәнлеге тиз туктый. Аскорбин кислотасы булган чималны (гөлҗимеш, нәүрүз гөле, күкебаш яфраклары һәм башкалар), әчемәсен өчен, 80–90 градус җылылыкта киптерү зарур.

Һава торышына карап дару чималын табигый яки ясалма җылылык шартларында киптерәләр. Яхшы көндә аны ачык һавада, кояшта, түбә астында, әйбәт җилләнә торган биналарда, начар һава торышы булганда киптергечләрдә, мичтә киптерәләр. Иң уңайлы һәм тиз киптерү ысулы – калай түбә астында, анда җилләтү өчен тәрәзәләр булса тагын да яхшырак. Дару үләннәрен киптерү өчен терлек фермалары, шәхси хуҗалык абзарлары чарлаклары отышлы түгел, чөнки анда чималга башка исләр сеңәргә мөмкин. Исле әйберләр, ашламалар, химикатлар саклана торган биналар да бу исемлеккә керә.

Эфир майлары һәм гликозидлар булган яфраклар, чәчәкләр, сабакларны яки үсемлекләрнең җир асты өлешләрен кояш нурлары тигезмичә киптерәләр. Тамырларны, тамырчаларны, җимешләрне һәм төшләрне кояшта киптерергә мөмкин. Киптергәндә чималны даими әйләндергәләп торырга кирәк. Яхшы киптерелгән чималда 8–15 гигроскопик дым була, бу чималның сыйфатына тәэсир итми. Тамыр-тамырчыклар, кайры бөгеп караганда сынса, уалса киптерү эше тәмамланган була, бөгелсә, әле кибеп җитмәгән, димәк. Яфраклар һәм чәчәкләр тәмам кипкән сурәттә онга әйләнә, җитешкән җимешләр кысып караганда ябышмый, оешмый.

Җыелган чималны кәгазь яки чүпрәк капчыкларда, тартмаларда, әрҗәләрдә һәм банкаларда сакларга мөмкин. Әгәр чималда эфир майлары, оча торган матдәләр булса, аларны яхшы ябыла торган пыяла банкаларда саклау хәерле. Пакет, банка, әрҗәләргә салганда чималның төре һәм җыю вакыты турында язу тыгып калдыралар яисә тышына язып куялар. Үксә уты, канлут, түндербаш кебек агулы үләннәрне яхшы ябыла

торган пыяла банкаларда яки, гомумән, балалар керә алмый торган биналарда саклау бик мөһим.

Чималны коры, караңгы (ультрашәмәхә нурлардан саклый торган), чиста биналарда саклыйлар.

**Биологик актив матдәләре булган шифалы үсемлекләрнең эчтәлеге.**

Хәзерге вакытта кулланыла торган күпчелек дару үсемлекләренең шифалы тәэсире аларда һәртөрле биологик актив матдәләр булуга бәйле. Алар кеше организмына кергәч, нинди дә булса бер физиологик йогынты ясый. Әлеге матдәләрнең составы төрле һәм алар химик кушылмаларның төрле классларына карый.

**Алкалоидлар** – үсемлек чималында тозлар яки утырмалар рәвешендә булган төрле химик төзелешкә караучы катлаулы табигый азот кушылмалары. Алкалоидларның фармакологик хасиятләре бик күп төрле. Алар үзәк нерв системасын тынычландыра, ярсуны баса, йөрәк-кан тамырлары системасына гипертензив һәм гипотензив, кан тамырларын тарайта, медиаторика системасына, тән тукымаларының эшчәнлеге системасына төрлечә йогынты ясый.

Үсемлекләрдәге әлеге кушылмаларның эчтәлеге еш кына табигать шартларына, җыю вакытына, үсемлекләрнең үсеш мәленә, үстерү ысулларына бәйле. Алкалоидларның никадәр күп булуы үсемлекләрнең чәчәк атканда һәм гонҗәләнгәндә (бутон) нинди халәттә булуына бәйле.

**Гликозидлар** – азотсыз табигатьтәге матдәләрнең зур төркеме. Аларның молекулалары шикәрле өлештән (гликон) һәм шикәрсез өлештән (агликон) тора. Гадәттә йөрәк гликозидлары, сапониннар, әче **флавоноид** гликозидлары кулланыла. Югары күләмдә токсик матдәләр булганга алар агулы санала, төзелешләре буенча гормоннарга бик якын тора. Антрагликозид дип аталучы (кошкунмас, кассия, йөзьяшәр, рәваҗ һәм башка шундый үсемлекләрдә була), эчне йомшарта торган гликозидлар аеруча киң файдаланыла. Антрагликозидларда агу матдәсе бик аз, яхшы саклана. Ачы гликозид дип атала торган кайбер үсемлекләр ашыйсы килү теләген көчәйтү, ашказаны перистальтикасын ныгыту, ашкайнату согын бүлеп чыгаруны арттыру өчен файдаланыла, ризыкны яхшырак үзләштерергә булыша. Болар – әрем, бабасыр уты, тузганак, кызылчатыр кебек үсемлекләр. Гликозидларның тагын бер төре – сапониннар бик күп төрле үсемлекләрдә бар. Сапониннар канәферчәләр, нәүрүзгөлчәләр семьялыгында аеруча күп. Болар – гамбәр, синюха, нәүрүз гөле тамырлары – какыруны, ортисифон – сидек кууны, сары мәтрүшкә, үлмәсгөл – үт согы бүлеп чыгаруны яхшырту өчен файдаланыла. Кайбер сапониннар артериядәге кан басымын акрынайту, тир чыгару, костыру үзлегенә ия.

Соңгы вакытта флавоноид гликозидлар төркеменең әһәмияте бик нык артты. Әлеге матдәләрнең атамасы сары төскә ишарәли, болар феноль кушылмаларга карый. Флавоноид гликозидларның бер төре Р-витамины активлыгына ия, үт кууга, бактерияләрне бетерүгә, организмнан радиоактив матдәләрне чыгаруга булыша.

**Кумариннар** һәм **фурокумариннар** үсемлекләрдә чиста килеш тә, гликозидлардагы шикәр катнашында да булырга мөмкин. Кумариннар күпчелек очракларда кузаклылар, чатырсыманнар, сәдәпутычалар семьялыгына караучы үсемлекләрдә була, бигрәк тә тамырларында, җимешләрендә туплана. Кумаринсыман катнашмалардан фотокумариннар аеруча мөһим. Болар – кислородлы гетрициклик катнашмалар. Аларның берише кан тамырларын киңәйтүче, эчке әгъзаларның шома мускуллары кыскаруын бетерүче, берише шешне кайтаручы һәм тиренең ультрашәмәхә нурланыш йогынтысына сизгерлеген һәм анда меланин ясалуын арттыручы буларак кулланыла.

**Эфир майлары** – хуш исле, тиз парга әйләнүчән матдәләр, күпчелек очракларда үсемлекләрнең төрле органнарында, бигрәк тә чәчәкләрендә, яфракларында, җимешләрендә була. Эфир майлары үсемлекләрдән кайнар су яки пар ярдәмендә чыгарыла. Карап торышка бу катнашмалар майлы тапка охшаса да, химик табигате буенча майларга карамый. Чөнки алар төрле терпеноид һәм терпенсыман матдәләрнең, алардан ясалган эшләнмәләрнең канашмалары булып тора. Мәсәлән, борыч бөтнек, уыл уты (мелисса), чебен кунмас (шалфей), мәтрүшкә, әрем, турак уты (укроп) кебек үләннәрдә әлеге майлар 2–20 процентка җитәргә мөмкин. Эфир майларын ялкынсынуга, микробларга, вирусларга, суалчаннарга актив каршы торучы буларак кулланалар. Кайбер эфир майлары йөрәккан тамырлары һәм үзәк нерв системасы эшчәнлегенә тәэсир итә, авыртуны баса, артериаль кан басымын киметә, баш мие һәм йөрәктәге кан тамырларын киңәйтә.

Эфир майлары шулай ук какырыкны йомшарту, стимуллаштыру, ютәлләүне тынычландыру үзлегенә ия. Ашказаны-эчәк тракты эшчәнлеген яхшырталар.

**Сумалалар**. Химик төзелеше ягыннан сумалалар эфир майларына якын. Гадәттә алар бергә булып, хуш исле куе сыеклык тәшкил итә. Озак кипми торган сумалаларны бальзам дип атыйлар. Алар ылыслы агачларда, каен бөресендә, рәваҗ тамырында күп була. Мәсәлән, тупыл бөресе бактерияләргә һәм суалчаннарга каршы тору үзлегенә ия.

**Ашлау матдәләре** мәгълүм булган барлык үсемлекләрдә дә бар. Алар гадәттә агачларның һәм куакларның каерысында, үзагачында күп була (әйтик, имән, каен, төчечия, гөлбадран, чагыр һәм башкалар). Аларда

агулы матдәләр бик аз. Танидка бай булган әлеге үсемлекләр ашказаны-эчәк тракты өчен камаштыручы һәм бактерияләргә каршы торучы, авызны чайкау өчен кирәкле чара буларак кулланыла.

Ашлау матдәләренең ялкынсынуга каршы тору сәләте аксым матдәләренең танидлар белән бергәләшеп эш итүенә нигезләнә. Лайлалы ярыларда ялкынсынуның көчәюенә каршы торучы, саклаучы элпә хасил була. Пешкән, бәрелгән, киселгән урыннарны дәвалау өчен кулланылучы танидлар саклаучы элпә булдырганга, аларны кан агуны туктатучы һәм ялкынсынуга каршы торучы чара буларак та файдаланалар. Моннан тыш, танидлар алкалоидлар һәм авыр металл тозлары белән агуланган очракларда да кулланыла.

Ашлау матдәләре һавадагы кислород белән реакциягә кергәндә әчи. Алма, бәрәңгене һәм башка әйберләрне кискәндә бу хәл бик ачык күзәтелә (аларның төсе үзгәрә). Әлеге матдәләр суда эреми.

Кешенең витаминга ихтыяҗы тормыш шартларына, сәламәтлегенә, ел фасылына һ.б.га бәйле. Болар, нигездә, A, B1 (тиамин), B2 (рибофлавин), B6 (пиридоксин), B12, B15, D. E, F, K, P, (рутин), PP (никотин кислотасы), аскорбин кислотасы, холин, биотин һәм башка витаминнар. Тере организм гадәттә читтән егермеләп витамин кертелүгә мохтаҗ. Аларның кайберләре эчке әгъзаларда оеша.

Үсемлекләрнең дәвалау үзлеге әле тагын аларда органик кислоталар, лайлалар, куерган сут-сәмихлар, майлы майлар, фитонцидлар, пигментлар, ферментлар, минераль тозлар, микроэлементлар һ.б.лар булуга бәйле.

Күп очракта үсемлекләрнең дәвалау үзлеге аларда бер төркем шифалы матдәләр туплануга бәйле.

**Үсемлек чималыннан дәвалау чаралары әзерләү**

Моның иң гади ысулы – үсемлекләрнең бик нык вакланган, изелгән кисәкчәләреннән (яфрак, сабак, җимеш, тамыр, тамырча) ясалган онча (порошок) ясау. Киптерелгән чималны кәһва тегермәнендә яки бер савытта бик нык ваклыйлар, ончага әверелдерәләр дә эчкә кабул итәләр яки яра, җәрәхәт урыннарына сибәләр. Әмма бу ысул сирәк кулланыла. Шифалы үсемлек чималын нигездә төнәтмә, сыек дару, эрен-үлекне суырту чарасы буларак кулланалар. Төнәтмәләрне – яфрак, чәчәк, сабаклардан, суырту чарасын тамыр, тамырчалардан әзерлиләр. Үсемлек чималын: яфрак, чәчәкләрне – 5 мм.га кадәр, сабак, кайры, тамыр, тамырчаларны – 3 мм.га кадәр, җимеш, орлыкларны 0,5 мм.га кадәр ваклыйлар. Вакланган чималны эмаль, фарфор, пыяла савытка салып, өстенә су коеп, капкач ябып, кайнап торган сулы савыт өстенә утырталар, ягъни пар өстендә тоталар. Төнәтмәне еш болгатып – 15 минут дәвамында, сыеклыкны 30

минут җылыталар. Җылынганнан соң савытны бүлмә температурасында суыталар, аннан сөзеп, калган чималны сыгалар. Әзер сыгынтыны кайнар су салып кирәкле күләмгә җиткерәләр. Күпчелек үсемлекләрдән төнәтмә һәм сыекчаларны 1:10 һәм 1:20 нисбәтендә ясыйлар, ягъни вакланган чималның үлчәүле бер өлешеннән ун-егерме өлеш төнәтмә яки сыекча эшләнелә.

Эчү өчен кулланылучы кайбер үсемлек төнәтмәләрен әлләни куертмыйча, әйтик, 1:30, 1:40 нисбәтендә яисә моннан да сыеграк ясыйлар. Тышкы куллану, тәнгә сөртү өчен кирәкле төнәтмәләрне, киресенчә, куерак итеп әзерлиләр.

Өй шартларында төнәтмә, сыекчаларны гади генә, кайнап чыккан су салып әзерлиләр. Капкачын ныклап ябып, өстенә чүпрәк каплап, 4–6 сәгать дәвамында төнәтәләр. Аннан соң чималны сөзәләр, калганын сыгып, яхшырак өлешен калдыралар. Үсемлекләрнең кайбер төрләрен кабат кап-кайнар су салып сөзәргә мөмкин. Әйтик, калган тамырын кимендә өч мәртәбә кайнар су коеп файдаланырга була, чөнки аның тамыры таш кебек каты. Шул сәбәпле сыгынтысы әкренләп алына. Әлеге төнәтмә, сыеклыклар җылы бинада, җәен тиз бозыла. Шуңа күрә көн саен әзерләвең, яки салкынча җирдә, суыткычта 2–3 тәүлек саклавың хәерле.

Дару үләннәреннән 70 процентлы спиртта төнәтмәләр әзерлиләр. Вакланган үсемлекне шешәгә салып өстенә спирт салалар да, бөкесен, капкачын ябып бүлмә температурасында атна буе тоталар. Бер атнадан соң төнәтмәне бушатып, калган үсемлекне сыгалар һәм яхшырак өлешен калдыралар. Күпчелек үсемлекләрдән төнәтмәләрне 1:10 нисбәтендә ясыйлар. Спирт салып ясалган төнәтмәләрне озак сакларга мөмкин. Дару чималын аракыда да төнәтергә ярый. Ул чагында 1:5 нисбәте була. Бу ысул халык медицинасында еш кулланыла. Шушы рәвешле төнәтелгән чималны эчкә кабул итәргә, тәнгә сөртергә дә була.

Халкыбыз яшәешендә киптерелгән һәм вакланган дару үсемлекләре катнашмалары белән бергә медицина чәйләре дә киң кулланыла. Үлән җыелмаларыннан төнәтмә, сыеклык, кайнар компресслар әзерлиләр. Гадәттә үсемлек тамырларыннан ягым-мазь ясыйлар. Аларны әзерләү өчен нигез итеп вазелин, ланолин, тозланмаган дуңгыз салосы, бурсык мае, ак май яки көнбагыш мае алына. Сало яки май нигезендә ясалган ягымнар тән тиресенә ансат үтеп керә. Вазелин нигезендә ясалаган ягымнарга караганда алар ныграк тәэсир итә.

Дәвалау максатында үсемлекләрнең яңа гына сыгылган суын аеруча еш кулланалар. Аны эчәргә дә, сыларга да мөмкин.

Шулай ук халык медицинасында үсемлекләрдән, җимешләрдән, төшләрдән алынган сүлдә ясалган әчеткеләр киң файдаланыла. Әчет-

келәр еш кына канлут, ат кәстәнәсе чикләвеге кебек кайбер агулы үсемлекләрнең агу кимәлен нык киметә. Шулай эчәклекнең торышына зыян салмый.

Дару үләннәре тупланмалары аерым урын били. Алардан төнәтмәләрне түбәндәгечә әзерләргә була: 10 г (1–2 аш кашыгы) чималны эмаль, пыяла, фарфор савытка салалар да, шуңа 200 мл (1 стакан) кап-кайнар су коеп, капкачын ябалар һәм кайнап торган су өстендә, парда 15 минут җылыталар. Аннан бүлмә тепературасында 45 минут суыталар, калган чималны сыгалар. Алынган төнәтмәнең күләмен кайнаган су кушып 200 мл.га җиткерәләр.

Сыеклык: 10 г (1–2 аш кашыгы) чималны эмаль, пыяла савытка салалар да, өстенә 200 мл (1 стакан) кап-кайнар кайнаган су коеп, капкач белән ябалар. Аннан кайнап торган суда (су мунчасында) 30 минут җылыталар, 10 минут бүлмә температурасында суыткач, калган чималны сыгалар. Кайнаган су салып алынган сыеклыкның күләмен 200 мл.га җиткерәләр.

Эчкә сулау катнашмалары да кулланыла. Аларны әзер төнәтмәләр яки сыеклыклар нигезендә, соңрак кайнар су кушып тиешле кимәлгә җиткерү шарты белән 1:2 яки 1:3 нисбәтендә әзерлиләр.

Сыек даруларны, сиптереп юу, дәвалау һәм гигиена процедуралары өчен измәләрне дә шулай әзерлиләр. Кайчагында, зарурлык булганда, тагын да куерак су сыгынтылары кирәк булганда төнәтмә һәм сыгынтыларны 1:5 яки 1:3 исәбеннән әзерләү һәм шул табигый хәлендә куллану кирәк.

Дәвалау ванналары әзерләү өчен төнәтмә һәм дару сыеклыкларын бер ваннага 1–2 литр исәбеннән кулланырга кирәк.

Күпчелек хроник авыруларны гален препаратлары белән дәвалау курсы 25–40 көнгә сузыла. 10–15 көнлек тәнәфестән соң, курсны 2–3 мәртәбә кабатлыйлар. Нәтиҗәлелеге кимемәсен һәм ияләшмәс өчен дәвалау курсларын кабатлаганда дару сыеклыкларын составын алыштырып, шушылай тәэсир итә торган башка шифалы үләннәрне билгелиләр. Гален чараларының бер тапкыр куллана торганнарын һәм тәүлек дәвамында куллану санын катгый билгеләп кую дөрес булмас. Зарурлык туганда авыруның ни рәвешле узуына, яшь, җенес, шәхси үзенчәлекләргә карап аларны алыштырырга да була.

*(Дәвамы бар)*

*Рәшит Минһаҗ тәрҗемәсе*

## ЮБИЛЯРЛАР ТУРЫНДА СҮЗ

## СЛОВО О ЮБИЛЯРАХ

*Расуль Гареев*

### К 125-ЛЕТИЮ Г.З. ЯГУДИНА



Фото: belizv-tat.ru

В июле месяце 2023 г. исполняется 125 лет со дня рождения Гимада Зигангировича Ягудина – уроженца деревни Тузлукуш Белебевского района, выдающегося государственного деятеля Республики Башкортостан, крупного хозяйственника, писателя-публициста, репрессированного и растрелянного в 1938 г.

Историческая значимость творческой личности Ягудина Г.З. ярко проявилась в годы его работы на посту наркома (министра) промышленности Башкортостана, важнейшей отрасли экономики в период индустриализации страны. По сути он руководил индустриализацией Башкортостана.

Его имя по достоинству вошла в список первооткрывателей башкирской нефти. Он руководил строительством Уфимского моторостроительного завода, первых электростанций и энергетических объектов Уфы, а также крупнейшей в России спичечной фабрики и т.д. При его непосредственном участии создавалась инфрастуктура строительства жилья, объектов образования и здравоохранения.

В 2022 г. в честь 90-летия башкирской нефти его фамилия была высечена золотыми буквами на стелле Первооткрывателей на центральной площади г. Ишимбая.

Общественные организации, ветераны нефтяной отрасли Белебея и поселка Приютово вносят предложение торжественно и на республиканском уровне отметить 125-летие со дня рождения Г.З. Ягудина в городе и в с. Тузлукуш.

В первую очередь предлагаем провести в городе научно-практическую конференцию с приглашением руководства Министерства промышленности нашей республики, «Башнефти», представителей науки, журналистов, творческой интеллигенции, ветеранов нефтяной отрасли, башкирского телевидения.

В рамках проведения юбилейных мероприятий рекомендуем предусмотреть посещение музея Ягудина в с. Тузлукуш, с возложением цветов к его памятнику.

Предлагаем наградить грамотами от имени Главы Республики Башкортостан, и ценными подарками тех творческих личностей, принявших активное участие в деле увековечивания памяти Г.З. Ягудина, в том числе писателя-публициста Зайнетдинова Энгеля Ахметовича, писателя и поэта Камиля Фазлый (Фазлутдинова); директора музея в селе Тузлукуш, заслуженного учителя РФ Исхакову Римму Миргасимовну; авторов памятника Р.Т. Давлетшина, Ю.Ф. Солдатова.

Предлагаем также установить мемориальные доски памяти Ягудина Г.З. на стене дома в Белебее на ул. Советская, где он семьей жил в 1920–1929 гг., а также на стене дома, в с. Тузлукуш, в котором он родился и вырос.

В целях оживления социальной ситуации в селе Тузлукуш предлагаем: возобновить работу местной библиотеки, восстановить деятельность ФАП, открыть торговую точку по продаже продуктов и товаров первой необходимости; продумать возможность использования пустующей школы (как базу юнармейцев, и как спортивную базу) и т.д.

Общественники города и района выражают надежду и уверенность в всемерной поддержке. Считаем, что данное мероприятие явится особым вкладом в деле патриотического воспитания молодого поколения на примере исторической памяти знаменитых личностей и героев страны.

## АВТОРЛАР БУЕНЧА БЕЛЕШМӘ

**Ахунов Айдар Габделислам улы**, төбәк тарихын өйрәнүче.

**Бакиева Рәшидә Корман кызы**, төбәк тарихын өйрәнүче, РФнең атказанган укытучысы.

**Бәйрәмова Фәүзия Әүхади кызы**, тарих фәннәре кандидаты, язучы, җәмәгать эшлеклесе.

**Бекенин Сөнгатулла Хәкимҗан улы**, укытучы, шагыйрь, музыкант, «Яшьлеккә сәяхәт» ансамбле әгъзасы.

**Гәрәев Рәсүл Корбан улы**, БР Татар конгрессының Бәләбәйдәге бүлекчә җитәкчесе.

**Закирова Илсөяр Гамил кызы**, филология фәннәре докторы, ТФАнең Г. Ибраһимов исемендәге ТӘСИның халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре, гыйльми совет әгъзасы.

**Закорюкина Асия Альберт кызы**, рәссам, Тубыл шәһәре «А.А. Алябьев ис. өстәмә белем бирү сәнгать мәктәбе» МАУ укытучысы.

**Захарова Фирая Хәмзә кызы**, үләнче, үләннәр белән дәвалаучы.

**Зиннәтуллина Фәнисә Мәксүт кызы**, РФнең атказанган укытучысы.

**Исхаков Дамир Мәүләви улы**, тарих фәннәре докторы, РТФА академигы, БТК Милли Шура әгъзасы, «Туган җир. Родной край» журналының баш мөхәррире.

**Йосыпов Фәрит Йосыф улы**, тел галиме, филология фәннәре докторы, профессор, ТРның атказанган фән эшлеклесе, Төрек лингвистика халыкара җәмгыяте мөһбир әгъзасы.

**Койлакаев Алибек Байморат улы**, рәссам.

**Котомова Рәүилә Сибгатулла кызы**, өстәмә белем бирү педагогы, Төмән өлкәсе Тубыл шәһәренең 15 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе музее мөдире.

**Минһаҗев Рәшит Рәкыйп улы**, журналист.

**Наил хәзрәт Җамалетдинов**, Чуашстан Республикасындагы Комсомол районының Тукай авылы мәчете имам-хатыйбы.

**Рәхимов Ришат Халит улы**, «Музей-Студия» музей технологияләре һәм фәнни экспертизалары үзәге директоры.

**Садыйков Клим Солтан улы**, педагогика фәннәре кандидаты, доцент.

**Сажина Альмира Азат кызы**, туган як тарихын өйрәнүче, «Халыкара иминият төркеме» ҖЧҖнең башкарма директоры.

**Сәйдуллина Зөлхәйда Солтанбай кызы**, Вагай районы Тугыз авылы мәдәният йорты белгече, себер татарлары фольклорын җыючы.

**Тычинских Зәйтүнә Әптрәшит кызы**, тарих фәннәре кандидаты, РФА УрБнең Тубыл комплекслы фәнни станциясе өлкән фәнни хезмәткәре.

**Фазылова Зөлфирә Искәндәр кызы**, төбәкче, МАУ «Тубыл районы үзәкләштерелгән система» МАУ китапханәчесе.

**Фәйзуллина Гүзәл Чахвар кызы**, филология фәннәре докторы, доцент. «Башлангыч һәм мәктәпкәчә белем бирү теорияләре һәм методлары» кафедрасы профессоры, РФА УрБнең Тубыл комплекслы фәнни станциясе өлкән фәнни хезмәткәре.

**Фәткуллин Фәрит Миңнулла улы**, «Кызыл таң» гәзитенең әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире, Башкортостанның һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.

**Фәттахов Илһам Фаил улы**, филология фәннәре кандидаты.

**Шәрипова Земфира Таштимер кызы**, фольклор буенча белгеч, «Тубыл төбәк мәдәният үзәге»нең МАУ өстәмә белем бирү педагогы.

# СВЕДЕНИЯ ОБ АВТОРАХ

**Ахунов Айдар Габделисламович**, краевед.

**Байрамова Фаузия Аухадиевна**, кандидат исторических наук, писатель, общественный деятель.

**Бакиева Рашида Кормановна**, краевед, заслуженный учитель РФ.

**Бекенин Сунгатулла Хакимзянович**, заслуженный педагог, поэт, музыкант, участник ансамбля «Яшьлеккә сәяхәт».

**Гареев Расуль Курбанович**, Руководитель Белебеевского отделения Конгресса татар РБ.

**Закирова Илсеяр Гамиловна**, доктор филологических наук, главный научный сотрудник отдела народного творчества ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ.

**Закорюкина Асия Альбертовна**, художник, преподаватель МАУ ДОД «ДШИ им. А.А. Алябьева» Тобольска.

**Захарова Фирая Хамзиновна**, травник-целитель.

**Зиннатуллина Фаниса Максудовна**, Заслуженный учитель РФ.

**Исхаков Дамир Мавлявеевич**, доктор исторических наук, академик РАЕН, член Национального Совета Всемирного конгресса татар, главный редактор журнала «Туган җир. Родной край».

**Койлакаев Алибек Баймуратович**, художник.

**Кутумова Равиля Сибгатулловна**, педагог дополнительного образования, зав. музеем школы МАОУ СОШ № 15 Тобольска Тюменской области.

**Мингазов Рашит Ракипович**, журналист.

**Наиль хазрат Джамалетдинов**, имам-хатыб мечети села Тукай Комсомольского района Республики Чувашия.

**Рахимов Ришат Халитович**, директор «Центра музейных технологий и научных экспертиз «Музеум-Студия».

**Садыков Клим Султанович**, кандидат педагогических наук, доцент.

**Сажина Альмира Азатовна**, краевед, исполнительный директор ООО «Международная Страховая группа».

**Сайдуллина Зульхайда Султанбаевна**, собиратель фольклора сибирских татар, специалист Тукузского Дома культуры Вагайского района.

**Тычинских Зайтуна Аптрашитовна**, кандидат исторических наук, старший научный сотрудник Тобольской комплексной научной станции УрО РАН.

**Фазылова Зульфира Искандаровна**, краевед, библиотекарь МАУ «Тобольская районная централизованная система».

**Файзуллина Гузель Чахваровна**, доктор филологических наук, доцент. Профессор кафедры «Теории и методики начального и дошкольного обучения», с.н.с. Тобольской комплексной научной станции УрО РАН.

**Фаткуллин Фарит Миннуллович**, заведующий отделом литературы и искусства газеты «Кызыл таң», заслуженный работник культуры Башкортостана и Татарстана.

**Фаттахов Ильгам Фаилевич**, кандидат филологических наук.

**Шарипова Земфира Таштимировна**, специалист по фольклору, педагог дополнительного образования МАУ «Тобольский районный Центр культуры».

**Юсупов Фарит Юсупович**, языковед, доктор филологических наук, профессор, заслуженный деятель науки РТ, член-корреспондент Международного турецкого лингвистического общества.

# ИНФОРМАЦИЯ ДЛЯ АВТОРОВ

Редакционный совет журнала «Туган җир/Родной край» сообщает что к публикации принимаются статьи и материалы как на татарском, так и на русском языках. В этой связи обращаемся ко всем заинтересованным в развитии указанного журнала авторам с предложением принимать участие в его издании. Для этого необходимо подготовить и направить соответствующие статьи в наш адрес.

Рекомендуемая тематика публикаций:

- *методика и методология историко-краеведческих исследований;*
- *история краеведения и историко-краеведческое наследие;*
- *проблемы региональной истории;*
- *новые археологические, нумизматические, фольклорные и эпиграфические находки;*
- *публикация источников;*
- *история конкретных сел и деревень;*
- *история музеев и публикация музейных коллекций;*
- *жизнь и деятельность выдающихся краеведов и земляков;*
- *использование краеведческих материалов и музейных коллекций в школе;*
- *популярные статьи по краеведению;*
- *краеведческая хроника (конференции, встречи и т. д.);*
- *рецензии, обзоры книг на краеведческую тематику.*

*Статьи оформляются согласно указываемым ниже требованиям:*

***Технические требования к оформлению статей***

*1. Внутри публикаций ссылки оформляются следующим образом* [Аминов: 2017. С. 82.]; [Денисов: 2012. С. 25; Черкас: 2005. С. 16.]; [ГАОО. Ф. 476. Оп. 3. Ед. хр. 609. Л. 6.]

*2.* Список использованной литературы оформляются согласно ГОСТу и приводятся в алфавитном порядке в конце статьи в виде нумерованного списка:

***Источники и литература***

1. Аминов Р.Р. Татары-казаки в составе Оренбургского казачьего войска (1748–1917 гг.). Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2017. – 348 с.
2. Государственный архив Оренбургской области (ГАОО). Ф. 98. Оп. 2. Ед. 25.
3. ГАОО. Ф. 98. Оп. 2. Ед. 26.
4. Денисов Д.Н. Очерки по истории мусульманских общин Оренбургского края (XVIII – начало XX в.). М. – Н. Новгород: Издательский дом «Медина», 2012. – 410 с.
5. Черкас Т.Г. Хронограф города. Орск: [Б.и.], 2005. – 67 с.

***Редакционные требования к оформлению****:*

Инициалы и фамилия автора указываются справа, далее по центру публикации идет название статьи.

1. Текстовый редактор – Microsoft Word, в формате .doc или .docx;
2. А4;
3. Поля: слева – 3 см., справа – 1,5 см. сверху и снизу – 2 см. Нумерация страниц снизу справа;
4. Шрифт – Times New Roman;
5. Размер шрифта – 14;
6. Межстрочный интервал – 1,5;
7. Абзацный отступ – 1,0.

***Требования к иллюстративным материалам***:

Фотоматериалы и рисунки (сканкопии) принимаются только качественные (в формате JPEG, объемом не менее 3,50 МБ).

Объем публикаций в пределах от 0,5 до 1,0 п. л. (20 000–40 000 знаков с пробелами). К публикациям прилагаются аннотации из 5–6 предложений, а также выделяются ключевые слова (4–5).

***Сведения об авторе:***

1. Фамилия, имя, отчество ____________________
2. Ученая степень ____________________
3. Ученое звание ____________________
4. Занимаемая должность ____________________
6. Почтовый адрес с индексом ____________________
7. Адрес электронной почты (e-mail) ____________________
8. Контактный телефон ____________________

Редакция отмечает, что после получения статьи от автора и детального его изучения членами редколлегии, она, в случае соответствия всем требованиям, передается в печать. Если материалы не соответствуют техническим и научным требованиям, статья возвращается автору с замечаниями для устранения недостатков. В связи с большим объемом поступающих материалов редколлегия может ограничиться пересылкой автору, в случае необходимости, соответствующих правил оформления для приведения ее в соответствие с требованиями.

Редколлегия оставляет за собой право размещения публикаций в журнале согласно рубрикаций и наличия мест в выпускаемых номерах. После выхода журнала авторы статей могут получить по одному экземпляру издания.

Авторам выплачивается гонорар. Для этого необходимо вместе с материалом прислать сканкопии паспорта, ИНН, СНИЛС, счет со всеми банковскими реквизитами.

Электронная версия журнала размещается на сайтах Всемирного конгресса татар и «Всетатарского общества краеведов».

Материалы следует присылать по эл.адресу: monitoring_vkt@mail.ru с указанием темы: «Для журнала «Туган җир/Родной край». Допускается и прямая передача публикаций в редакцию, но лишь в электронных версиях. Для этого указываем адрес нашего журнала: Казань, ул. А. Пушкина, 52, офис 303, редакция журнала «Туган җир/Родной край»

**Туган җир**

*Төбәк тарихы буенча журнал*

**Родной край**

*Краеведческий журнал*
3’2023

Подписано в печать 17.05.2023 г. Формат 70×100 1/16
Усл. печ. л. 19,5 Тираж 999 экз.
Отпечатано с готового оригинал-макета.
в типографии ООО «Грумант»
В данном номере журнала использованы фотографии из личных архивов авторов



*Ш.Ш. Кадыров һәм И.Г. Закирова авторлыгында чыгарылган «Татар халкының музыкаль-эпик иҗаты: себер ареалы» хезмәте презентациясендә.*



*Посещение Тюмени в рамках фестиваля «Сузге-тора». 21 мая 2023 г.*



*VII Международная научно-практическая конференция «Занкиевские чтения»*



*На юбилее Сунгатуллы Бекенина.*





*Работы юных художников конкурса рисунков «Легендарная царица Сузге»*
*(«Ханбикә Сүзге»)*
*Февраль 2023 г.*






*Организаторы и жюри фестиваля «Язгы моңнар». Июнь 2023.*



*Посещение комплекса Искерского городища. 2023 г.*

2023
ГОД НАЦИОНАЛЬНЫХ
КУЛЬТУР И ТРАДИЦИЙ
МИЛЛИ МӘДӘНИЯТЛӘР
һӘМ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР ЕЛЫ

МИЛЛИ
ДАСТАННАРЫБЫЗ
ЕЛЫ
2023
ГОД
НАЦИОНАЛЬНЫХ
ДАСТАНОВ

# ПЕРТӘМ ПУЛАЙЫК!

*Дәлийә*

Татарларым, себерлеләр,
Парығыска та энтәшәм,
Аңнан, үсем өцөн түгел,
Телем өцөн көрәшәм.

Үс йағын ҡына маҡтайты,
Тийеп, әйтәсес ийән,
Үс йағым – пөтөн Себерем!
Йалғышмаң, алай тимәң.

Ҡайсы йаҡның кәпләшеүе,
Пырас айырмалыраҡ,
Абу итәрсес, шиғерләрем
Пулмаса йағымныраҡ.

Ҡасанца пелән себерле
Телне полғап та китәм,
Икәүен тә ҡәтерләйем,
Икәүен тә үс итәм.

Икәүе тә миңә туған,
Икәүе тә йағымны,
Ата-пабам ике йаҡтан
Себер, Ҡасан тоғомно.

Төмән-Йалутор пуйларын...
Тигес сөйәм, йаратам,
Татарлар, сескә пағышлап,
Йорәк йырны йаңкыратам.

Аллам пиргән ҡалыкларға
Төрлө ыспай телләрне,
Ницек телең йарайтмайсың!
Телгә салған көйләрне.

Үс телен аңнай алмаған
Йат телләрне аңнар ма?
Инте аны кем тийәрсес,
Ағыллы ма, арсар ма?

Төрлө йернең үсенеңке
Йола-әтәтләре пар,
Мин пелмәгәннәре тә кән,
Сес пелмәгәннәр тә пар.

Пер аймаҡ ҡуй пес – татарлар,
Пабаларыбыс – туған,
Пер-перен татар сатмаған,
Пертәм пулған, тус пулған.

«Үс йағымны» йаса алсам,
Пәғетле пулыр итем,
Телне йаҡлап йаскан пулған
Сүсләрем йелгә китте.

«Үс йағы» тип, песнең йаҡ тип
Пүлешеп утырмайыҡ,
Алай та пуш мейәләрне,
Цүп-цап пән тултырмайыҡ.

Ницек пулсаң та кешегә
Иц пер йарап пулмас, тим,
Татар татарын цуғыса...
Ҡотай ҡылмас мийән ким?

Пертәм пулайык, татарлар,
Пабаларыбыс тайын,
Телебесне йаҡлағалы
Табайыҡ та пер шайын!